# ШУРА

№ 47
2025



2007114583106

ДИНИ АЛЬМАНАХ

1908 елдан бирле нәшер ителә

# ШУРА

№ 47

2025



2007114583106

Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте

ДИНИ АЛЬМАНАХ

1908 елдан бирле нәшер ителә

# ЭЧТӘЛЕК


Җомга хотбәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 4
Җомга хотбәсенең тәрҗемәсе . . . . . . . . . . . . . . . . 9

ВӘГАЗЬЛӘР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13
Һәр мөселманга фарыз булган гыйлем . . . . . . . . . 14
Фәрештәләр дөньясы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 20
Исра вә Мигъраҗ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 26
Шәгъбан аеның фазыйләтләре . . . . . . . . . . . . . . 34
Бәраәт кичәсе. Тәүбәнең әһәмияте . . . . . . . . . . 39
Дога кылуның әһәмияте . . . . . . . . . . . . . . . . . . 45
Ватанны ярату . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 52
Изге Рамазан ае башлана . . . . . . . . . . . . . . . . . . 57
Рамазан – Коръән ае . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 63
Рамазан – җәһәннәм утыннан котылу . . . . . . . . . 67
Кадер кичәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 73
Гает – иң зур бәйрәм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 78
Ураза гаете хотбәсенең гарәпчә укылышы . . . . . . 85
Ураза гаете хотбәсенең кириллицага транслитерациясе . . . 87
Ураза гаете хотбәсенең татарчага тәрҗемәсе . . . . 89
Ураза гаете вәгазе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 91
Үлемнән соң безне нәрсә көтә? . . . . . . . . . . . . . 98

«НӘРСӘ? КАЙДА? КАЙЧАН?» . . . . . . . . . . . . . . . 103
СЕНТЯБРЬ – ДЕКАБРЬ . . . . . . . . . . . . . . . . . . 104

ТАРИХ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 123
Дөнья тарихында мөселман университетлары . . . . 124

**ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:**

Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте
420021, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38 нче йорт

Бушлай таратыла.
2013 елның июленнән чыга.
Басма кварталга бер тапкыр чыга.

**БАШ РЕДАКТОР:**
Хамматов Л. Г.

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Хәмидуллин Р. Ә.
Мөбарәков Б. Р.
Фәизов И. Ә.

**ҖАВАПЛЫ СӘРКАТИП**
Телефон: +7 (843) 598-09-42

**МӨХӘРРИР:**
Маннанова Р. Р.

**ДИЗАЙНЕР:**
Хәйретдинов И. Р.

**БИТКӘ САЛУЧЫ:**
Гарифуллин И. Ф.

**ТЫШЛЫКТАГЫ РӘСЕМ:**
Тышлыкның 1 нче битендә фотода Рамазан Кәрим дип язылган.
Рәсемнең авторы: abu_zeina / shutterstock.com/ru/image-vector/ramadan-kareem-greeting-card-arabic-calligraphy-1705341931

**«ШУРА» дини альманах, № 47** **12+**

гынвар–март 2025
раҗәб–шәүвәл 1446

Альманах Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан республикасы буенча идарәсендә 2013 елның 17 нче июлендә ПИ № ТУ16-01077 номеры белән теркәлде.

**РЕДАКЦИЯ**

Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:
«Хозур» – «Тынычлык» нәшрият йорты» шәхси оешмасы
420111, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27 нче йорт
Тел.: +7 (843) 598-09-42
Электрон почта: izdat@huzur.ru
Сайт: huzur.ru

*Типографиянең адресы:*
*«Карти» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте типографиясендә бирелгән электрон-макетның тулы сыйфатына тәңгәлләштереп бастырылды.*
*Адрес: 420095, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Химград территориясы, 201 нче йорт, 1006 нчы бина.*

Тираж – 2000 данә
Басарга кул куелды: 09.12.2024
Чыгу көне: 24.12.2024

*Редакциягә килгән язмалар кире кайтарылмый.*

*Журналда тәрҗемә итеп бастырылган материалларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.*

*Журнал битләрендә Коръәни Кәримдәге аятьсүрәләр урын алганлыктан, басмага игътибарлы булуыгыз сорала.*

**«СОВЕТ»**

Ежеквартальное печатное издание
на татарском языке

## Җомга хотбәсе

Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән карап утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый.

اَلْحَمْدُ لِلَّهِ اَلْحَمْدُ لِلَّهِ اَلْحَمْدُ لِلَّهِ الَّذِي هَدَانَا لِهَذَا وَمَا كُنَّا لِنَهْتَدِيَ لَوْ لَا أَنْ هَدَانَا اللّٰهُ. وَمَا تَوْفِيقِي وَاعْتِصَامِي إِلَّا بِاللّٰهِ۞ فَسُبْحَانَ الَّذِي قَالَ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللّٰهِ: وَمَا تَشَاؤُونَ إِلَّا أَنْ يَشَاءَ اللّٰهُ۞ نَشْهَدُ أَنْ لَا إِلَهَ إِلَّا اللّٰهُ وَحْدَهُ لَا شَرِيكَ لَهُ۞ شَهَادَةً مُنْجِيَةً مِنْ عَذَابِ اللّٰهِ۞ وَنَشْهَدُ أَنَّ سَيِّدَنَا مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ۞ دَاعِيًا إِلَى اللّٰهِ۞ صَلَّى اللّٰهُ تَعَالَى عَلَيْهِ وَعَلَى أَوْلَادِهِ وَأَزْوَاجِهِ وَعَلَى خُلَفَائِهِ الرَّاشِدِينَ الْمُرْشِدِينَ الْمَهْدِيِّينَ مِنْ بَعْدِهِ۞ وَوُزَرَائِهِ الْكَامِلِينَ فِي عَهْدِهِ۞ خُصُوصًا مِنْهُمْ عَلَى الْأَئِمَّةِ بِالْحَقِّ أُمَرَاءِ الْمُؤْمِنِينَ أَبِي بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَعُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ۞ وَعَلَى بَقِيَّةِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ۞ رِضْوَانُ اللّٰهِ تَعَالَى عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ أَمَّا بَعْدُ فَيَا عِبَادَ اللّٰهِ! ۞ اِتَّقُوا اللّٰهَ وَ أَطِيعُوهُ۞ إِنَّ اللّٰهَ مَعَ الَّذِينَ اتَّقَوْا وَالَّذِينَ هُمْ مُحْسِنُونَ۞

Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:

قَالَ اللّٰهُ عَزَّ وَ جَلَّ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللّٰهِ:

______________________________۞

Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:

وَ قَالَ النَّبِيُّ صَلَّي اللّٰهُ عَلَيْهِ وَ سَلَّمْ:

______________________________________۞

Вәгазьнең эчтәлегенә багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәге сүзләрне укый:

أَلا إِنَّ أَحْسَنَ الْكَلامِ وَأَبْلَغَ النِّظَامِ۞ كَلامُ اللهِ الْمَلِكِ الْعَزِيزِ الْعَلَّامِ كَمَا قَالَ اللهُ تَبارَكَ وَ تَعالَى فِي الْكَلامِ: وَإِذَا قُرِئَ الْقُرْآنُ فَاسْتَمِعُوا لَهُ وَ أَنْصِتُوا لَعَلَّكُمْ تُرْحَمُونَ۞ أَسْتَعِيذُ بِاللهِ: إِنَّ الدِّينَ عِنْدَ اللهِ الْإِسلَامُ۞

Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.

Гомумән, утырган вакытта һәртөрле дога кылына ала.

بَارَكَ اللهُ لَنَا وَ لَكُمْ۞ وَ لِسَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَ الْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَ الْمُسْلِمَاتِ۞ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَ الْأَمْوَاتِ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعوَاتِ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ۞

Соңыннан басып, икенче хотбә буларак, түбәндәгеләрне укый:

اَلْحَمدُ لِلّه حَمْدَ الْكَامِلِينَ وَالصَّلَوةُ وَ السَّلَامُ عَلَى سَيِّدِ الْأَوَّلِينَ وَ الْآخِرِينَ۞ مُحَمَّدٍ وَآلِهِ وَ صَحْبِهِ أَجْمَعِينَ۞ تَعْظِيماً لِنَبِيِّهِ وَتَكْرِيماً لِفَخَامَةِ شَانِ شَرَفِ صَفِيِّهِ۞ فَقَالَ عَزَّ وَجَلَّ مِنْ قَائِلٍ مُخْبِراً وَآمِراً:

إِنَّ اللهَ وَمَلَائِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيماً۞ اَللَّهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ۞ كَمَا صَلَّيْتَ عَلَى إِبْراهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْراهِيمَ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ۞ اَللَّهُمَّ بَارِكْ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ۞ كَمَا بَارَكْتَ عَلَى إِبْراهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْراهِيمَ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ۞

اَللَّهُمَّ وَارْضَ عَنِ الْخُلَفَاءِ الْأَرْبَعَةِ ذَوِى الْقَدْرِ الْجَلِيِّ وَالشَّرَفِ الْعَلِيِّ ۞ سَيِّدِنَا أَبِى بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَ عُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُمْ ۞ وَعَنِ السِّتَّةِ الْبَاقِيَةِ مِنَ الْعَشَرَةِ الْمُبَشَّرَةِ ۞ وَعَنِ الْعَمَّيْنِ الْمُكَرَّمَيْنِ عِنْدَ اللّٰهِ اَلْمُحْتَرَمَيْنِ عِنْدَ النَّاسِ ۞ سَيِّدِنَا الْحَمْزَةَ وَالْعَبَّاسِ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُما ۞ وَ عَنِ السِّبْطَيْنِ الْجَلِيلَيْنِ السَّعِيدَيْنِ الشَّهِيدَيْنِ ۞ سَيِّدِنَا الْحَسَنِ وَ سَيِّدِنَا الْحُسَيْنِ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُما ۞ وَعَنْ سَائِرِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ رِضْوَانُ اللّٰهِ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ ۞ وَ عَنْ سَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَالْمُسْلِمَاتِ ۞ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَالْأَمْوَاتِ ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ ۞

اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ، اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ، اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ[1] ۞ وَاخْذُلْ مَنْ خَذَلَ الْمُسْلِمِينَ ۞ وَاكْتُبِ الصِّحَّةَ وَالسَّلَامَةَ عَلَيْنَا وَعَلَى الْحُجَّاجِ وَالْغُزَاةِ وَالْمُسَافِرِينَ وَالْمُقِيمِينَ وَالْحَاضِرِينَ وَالْغَائِبِينَ ۞ فِي بَرِّكَ وَبَحْرِكَ وهَوَائِكَ مِنْ أُمَّةِ مُحَمَّدٍ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ ۞

Иң соңыннан «Әгуузү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:

إِنَّ اللّٰهَ يَأْمُرُ بِالْعَدْلِ وَالْإِحْسَانِ وَ إِيتَاءِ ذِي الْقُرْبَى وَيَنْهَى عَنِ الْفَحْشَاءِ وَ الْمُنْكَرِ وَالْبَغْيِ يَعِظُكُمْ لَعَلَّكُمْ تَذَكَّرُونَ ۞ وَلَذِكْرُ اللّٰهِ أَكْبَرُ وَاللّٰهِ يَعْلَمُ مَا تَصْنَعُونَ ۞

**Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый:**

---

1 Бу вакытта җәмәгать күңелдән «Әмин» дип әйтә.

Әлхәмдүлилләәһи, әлхәмдүлилләәһи, әлхәмдүлилләәһил-ләзии һәдәәнә лиһәәзәә вә мәә күннәә линәһтәдийә ләү ләә ән һәдәәнәллаһ. Вә мәә тәүфиикый вәгътисаамий илләә билләәһ. Фә сүбхәәнәл-ләзии каалә фии китәәбиһил-кәриими әстәгыйзү билләәһи: «Вә мәә тәшәә-үүнә илләә ән йәшәә-әллаһ». Нәшһәдү ән ләә иләәһә илләллаһу. Вәхдәһү ләә шәриикә ләһү. Шәһәәдәтән мүнҗийәтән мин газәбилләһи. Вә нәшһәдү әннә сәййидәнә Мүхәммәдән габдүһү вә расүүлүһү. Дәәгыыйнәә иләл-лаһи. Салләллаһу тәгаалә галәйһи вә галәә әүләәдиһи вә әзвәәҗиһи вә галәә хуләфәә-иһир-раашидиинәл мүршидиинәл мәһдиййинә мин бәгъдиһи. Вә үзәраа-иһил кәәмилиинә фии гаһдиһи. Хусуусан минһүм галәәл ә-иммәти бил-хәккый үмәраа-ил мү’миниинә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гусмәәнә вә Галиййин. Вә галәә бәкыййәтис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәнин иләә йәүмид-дини. Ридъвәәнуллаһи тәгаалә галәйһим әҗмәгыйнә.

Әмма бәгъде: фә йәә гыйбәдәллаһ! Иттәкуллаһә вә әтыыйгууһу. Иннәллаһә мәгал-ләзиинәт-тәкау, вәл-ләзиинә һүм мухсинүүн.

**Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:**

Каалә-ллаһу газзә вә җәллә фии китәәбиһил кәриими әстәгыыйзү билләһи: ______________________________

**Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:**

Вә каалән нәбиййү салләллаһу галәйһи вә сәлләм: ______________

**Вәгазьнең темасына багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәгеләрне укый:**

Әләә иннә әхсәнәл кәләәми вә әбләган низаами. Кәләәмуллаһил мәликил газиизил галләәми, кәмәә каалаллаһу тәбәәракә вә тәгаалә фил-кәләәми. Вә изәә куриәл-куръәәну фәстәмигуу ләһү вә әнсыйтү ләгалләкүм түрхәмүүнә. Әстәгыыйзү билләһи: «Иннәд-диинә гыйндәллаһил Исләәм».

**Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.**

**Гомумән, утырган вакытта Ахирәт өчен һәртөрле дога кылына ала.**

Бәәракәллаһу ләнәә вә ләкүм. Вә лисәә-ирил мүʼминиинә вәл мүʼминәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиинә. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә, вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмин.

**Соңыннан, басып, икенче хотбә буларак, киләсе сүзләрне укый:**

Әлхәмдүлилләәһи, хәмдәл кәәмилиинә вәссаләәтү вәссәләәмү галәә сәййидил әүвәлиинә вәл әхыйринә Мүхәммәдин вә әәлиһи вә сахбиһи әҗмәгыйн. Тәгъзыймән линәбиййиһи вә тәкриимән лифәхаамәти шәәни шәрафи сафиййиһи. Фәкаалә газзә вә җәллә мин каа-илин мүхбиран вә әәмиран:

«Иннәллаһә вә мәләә-икәтәһү йүсаллүнә галән нәбиййи. Йәә әййүһәлләẓиинә әәмәнүү саллүү галәйһи вә сәллимүү тәслиимән». Аллаһуммә салли галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә салләйтә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибрааһиимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид. Аллаһуммә бәәрик галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә бәәрактә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибрааһиимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид.

Аллаһуммә вәрда ганил хуләфәә-ил әрбәгати ẓәвил кадрил җәлиййи вәш-шәрафил галиййи сәййидинәә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гуҫмәәнә вә Галиййин радыяллаһу ганһүм. Вә ганис-ситтәтил бәәкыйәти минәл гашәратил мүбәшшәрати. Вә ганил гаммәйнил мүкәррамәйни гыйндәллаһи әл-мүхтәрамәйни гыйндән-нәәси сәййидинәл Хәмзәтә вәл Габбәәси радыяллаһу ганһүмәә. Вә ганис сибтайнил җәлииләйнис сәгыыйдәйни әш-шәһиидәйни сәййидинәл Хәсәни вә сәййидинәл Хүсәйни радыяллаһу ганһүмәә. Вә ган сәә-ирис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәни иләә йәүмид-диин. Ридъвәәнуллаһи галәйһим әҗмәгыйн. Вә ган сәә-ирил мүʼминиинә вәл мүʼминәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл

әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр раахимин.

Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин. Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин. Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин[1]. Вәхҙүл мән хәҙәләл мүслимиин. Вәктүбис-сыйххәтә вәс-сәләәмәтә галәйнәә вә галәәл хүҗҗәәҗи вәл гузәәти вәл мүсәәфириинә вәл мүкыыймиинә вәл хәәдыйриинә вәл гаа-ибиинә. Фии бәррикә вә бәхрикә вә һәвәә-икә мин үммәти Мүхәммәдин галәйһим әҗмәгыйн. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә. Вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмиин.

**Иң соңыннан «Әгууҙү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:**

«Иннәллаһә йә’мүру бил гадли вәл ихсәәни вә иитәә-и ҙил курбәә вә йәнһәә ганил фәхшәә-и вәл мүнкәри вәл бәгъ-ии, йәгыйзукүм ләгалләкүм тәҙәккәрүун. Вәләҙикруллаһи әкбәр, вәллааһи йәгъләмү мәә тәсънәгуун».

## Җомга хотбәсенең тәрҗемәсе

Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән карап утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый:

Безне туры юлга күндергән Аллаһыга мактау булсын.[2] Аннан башка безне берәү дә (туры юлга) күндерә алмый.

Коръәни Кәримдә: **«Әмма Аллаһы теләми торып, сез тели алмассыз. Һичшиксез, Аллаһы – Белүче, Хикмәт иясе»**, – дип әйтүче Аллаһы – барлык кимчелекләрдән дә Пакь.

Без бердәнбер булган Аллаһыдан башка илаһның юклыгына һәм Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Аның Расүле һәм колы булуына шаһитлык итәбез. Без Пәйгамбәребез, аның балалары, хатыннары,

[1] Бу вакытта җәмәгать күңелдән «Әәмин» дип әйтә.

[2] 3 тапкыр әйтелә.

элек яшәп киткән изгеләребез һәм һидаять юлында булган һәркем өчен, Аллаһының рәхмәтен сорыйбыз.

Һәм аның турыдан-туры хәлифәләре – мөэминнәрнең хакимнәренә: Әбү Бәкер, Гомәр бине Хаттаб, Госман бине Гаффан, Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһүмәдән Аллаһы риза булсын. Кыямәт көнендә барлык пәйгамбәрләргә һәм табигыйннәргә Аллаһының ризалыгы һәм рәхмәте булсын.

Моннан соң Аллаһыга гыйбадәт кылучылар Аңа итагать итсен.

**«Һичшиксез, Аллаһы –** [гөнаһлардан] **курыккан һәм** [Раббыларының ризалыгын гына өмет итеп] **игелекле гамәлләр кылган кешеләр белән».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:128

**Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:**

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә: ____________________

**Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:**

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: ______________________________________________________________

**Вәгазьнең эчтәлегенә багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәге сүзләрне укый:**

Дөреслектә, иң дөрес һәм төзек сөйләм – ул Аллаһының Сөйләме. Коръәндә Аллаһы Тәгалә әйтүенчә:

**«Коръән укылган чакта, аны тыңлагыз һәм дәшми торыгыз, – бәлки, сез** [Аллаһы тарафыннан] **рәхмәт ителерсез»;**

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:204

**«Һичшиксез, Аллаһы хозурында** [хакыйкый һәм кабул ителгән] **дин – Ислам** [дине генә]**».**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:19

**Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.**

**Гомумән, утырган вакытта һәртөрле дога кылына ала.**

Без Аллаһыдан барыбыз өчен дә рәхмәтен иңдерүен сорыйбыз. Мөэмин-мөселманнар өчен ярдәм ике дөньяда да булачак. Син – Ишетүче, Якын һәм догаларыбызга җавап бирәсең. Синең рәхмәтең белән, йә, Рәхимле һәм Шәфкатьле Аллаһы. Пәйгамбәрләргә сәламнәр һәм Аллаһының рәхмәте булсын. Галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһыга мактаулар булсын.

**Соңыннан басып, икенче хотбә буларак, түбәндәгеләрне укый:**

Аллаһыга мактаулар, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның гаиләсенә, сәхабәләренә һәм аңа иярүчеләргә сәламнәребез һәм Аллаһының рәхмәте булсын.

Аллаһы Тәгалә Изге Китабыбызда әйткәнчә:

> **«Һичшиксез, Аллаһы һәм фәрештәләре Нәби салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават әйтәләр. Ий иман китерүчеләр! Сез аңа салават әйтегез һәм** [«Ий, Нәби, сиңа сәлам булсын», – дип] **сәламләү белән сәлам бирегез».**

«Әл-Әхзәб / Гаскәрләр», 33:56

Йә, Аллаһы, тугры хәлифәләр: Әбү Бәкер, Гомәр бине Хаттаб, Госман бине Гаффан, Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһүмәгә һәм җәннәт белән шатландырылган алты сәхабәгә, Расүлебезнең югары дәрәҗәдә булган абыйлары – Хәмзә бине Габделмотталиб һәм Габбас бине Габделмотталибка, шәһит булып киткән сөекле оныклары Хәсән белән Хөсәенгә рәхмәтеңне иңдер. Сәхабәләр һәм табигыйннәр өчен Кыямәт көнендә Аллаһының рәхмәтен, ризалыгын ирештер.

Мөэмин-мөселманнар өчен ярдәмең ике дөньяда да булачак. Дөреслектә, Син – догаларыбызны Ишетүче һәм догаларыбызга җавап бирәсең. Синең рәхмәтең белән, йә, Рәхимле һәм Шәфкатьле Аллаһы!

Йә, Аллаһы, динебез Исламга ярдәм итүчеләргә Син дә ярдәм ит (өч тапкыр әйтелә). Мөэминнәрне җәберләүчеләрне көчсезләндер. Безгә, галимнәргә, юлчыларга, исәннәргә һәм үлеләргә – пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең өммәтенә тынычлык һәм тәртип билгелә.

**Иң соңыннан, «Әгуузү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:**

> **«Һичшиксез, Аллаһы** [һәрнәрсәне аңлатыр өчен, иңдергән китабында] **гадел булырга, изгелек кылырга һәм** [бигрәк тә] **якын туганнарга** [мохтаҗ булган нәрсәләрен] **бирергә** [һәм туганлык җепләрен ныгытуны] **әмер итә.** [Зина кебек] **Фәхешлектән,** [көферлек, ширек һәм шуның кебек дин кабул итмәгән] **тыелганнан һәм** [кешеләргә] **җәберзолым кылудан тыя. Сез акылга килерсез дип, сезне үгетли».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:90

Аллаһыны зикер итегез. Хакыйкатьтә, Ул сезнең ни кылганнарыгызны белә.

# Вәгазьләр

*10 нчы гыйнвар вәгазе,*

*раҗәб аеның 10 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1446 ел*

# Һәр мөселманга фарыз булган гыйлем

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсхәәбиһи әҗмәгыйн.

Ислам динендә гыйлем алуга зур әһәмият бирелә. Изге Коръәннең беренче булып иңдерелгән аяте дә гыйлем алу турында була. Сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә изге Рамазан аеның Кадер кичәсендә Җәбраил фәрештә аркылы Аллаһы Тәгалә Коръәннең беренче аятен иңдерә. Анда Аллаһы Тәгалә: «[Һәрнәрсәне юктан бар итеп] **Яратучы Раббың исеме белән** [башлап, Коръәнне] **укы**!» – дип әмер итә, ягъни белем ал, өйрән, уйлан, фикерлә! («Әл-Галәк» сүрәсе, 1 нче аять). Бу аять иң беренче чиратта Коръәнне һәм башка дини белемнәрне өйрәнергә куша. Шулай ук әлеге әмергә файдалы дөньяви гыйлемнәрне өйрәнү дә керә. Шуңа күрә һәр кеше гыйлемгә омтылырга тиешле.

Шәригать буенча кешеләрнең гамәлләре сигез төргә бүленә: фарыз, вәҗиб, сөннәт, мөстәхәб, мөбах, мәкруһ, харам һәм мөстәкраһ. Шуларны карап китик.

**Фарыз** – ул катгый дәлилләргә (Коръәннең ачык формадагы аятьләренә һәм мөтәватир хәдисләргә) нигезләнгән гамәл. Фарыз гамәлне кылган кеше саваплы, кылмаганы – гөнаһлы, ә аның фарызлыгына (тиешле булганына) ышанмаган кеше имансыз була.

Фарыз үзе ике төргә бүленә: фарыз гайн (һәр кеше үтәргә тиеш булган гамәлләр) һәм фарыз кифәя (бер җәмәгатьнең төркеме үтәргә тиеш булган гамәл). Фарыз гайн (һәр кеше үтәргә тиешле) гамәлләр: Ислам диненең хаклыгына ышану, Аллаһы Тәгаләнең сыйфатларын һәм иманның башка шартларын белү, көн саен биш вакыт намаз уку, Рамазан аенда ураза тоту, ел саен малның зәкятен бирү, мөмкинлеге булган кешегә гомерендә бер мәртәбә Мәккә-и Мөкәррәмә шәһәренә барып хаҗ кылу һ. б. Димәк, шушы гамәлләрне үтәмәгән кеше гөнаһлы була, ә үтәргә кирәклегенә ышанмаучы, боларны эшләргә кирәкми диюче инде имансыз була.

**Вәҗиб** – ул занни дәлилләргә (Коръәннең ачык формада булмаган аятьләренә һәм әхәд хәдисләргә) нигезләнгән гамәл. Вәҗиб гамәлне кылган кеше саваплы, кылмаганы – гөнаһлы, ә аның вәҗиблегенә (тиешле булганына) ышанмаган кеше зур гөнаһ кылган була. Вәҗиб гамәлләр: витр һәм гает (Ураза һәм Корбан бәйрәме) намазларын уку, фитр садакасын бирү, корбан чалу, Коръәндәге һәрбер сәҗдә аятьләрен укуга яисә ишетүгә тиләвәт сәҗдәсен кылу һ. б.

**Сөннәт** гамәлне кылган кеше саваплы була, әмма кылмаганы, гөнаһлы булмаса да, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең шәфәгатенә (яклавына) ирешми. Сөннәт гамәлләр: яхшы эшләрне «Бисмилләһ» сүзе белән башлау, Коръән укыр алдыннан – «Әгуузү»не, ә төчкергәч «әлхәмдүлилләһ» дип әйтү, иманлы кешеләргә сәлам бирү һ. б.

**Мөстәхәб** гамәлне кылган кеше саваплы була, ә кылмаганы гөнаһлы булмый һәм Кыямәт көнендә дә моның өчен шелтә алмый. Мөстәхәб гамәлләр: нәфел (өстәмә) намазлар уку, нәфел уразалар тоту, нәфел садакалар бирү, буш вакытта Коръән уку һ. б.

**Мөбах** гамәлне кылган яки кылмаган кеше – саваплы да, гөнаһлы да булмый. Мөбах гамәлләр: хәләл ризыкларны туйганчы ашау яки эчү, утыру, басып тору, зарарсыз сүзләр сөйләү һ. б.

**Харам** гамәлне кылучы зур гөнаһлы, ә мондый гамәлләрне эшләргә ярый (хәләл) дигән кеше имансыз була. Харам гамәлләр: кешене яисә хайванны җәберләү, гайбәт сөйләү, урлау, исерткеч эчемлекләр эчү, зина кылу һ. б.

**Мәкруһ** гамәлне кылган яки аны дөрес дигән кеше гөнаһлы була. Мәкруһ гамәлләр: ямьсез җырлар җырлау, кеше алдында әдәпсез кылану һ. б.

**Мөстәкраһ** гамәлне кылган кеше гөнаһлы булмаса да, әдәпсезлек кылган була. Мөстәкраһ гамәлләр: базарда яисә урамда ашау, авызны капламыйча иснәү, кычкырып кикерү һ. б.

Дөрес булмаган, гөнаһлы гамәлләрдән саклану өчен, без бу нәрсәләрне өйрәнергә, белергә тиеш.

Хәдис-шәрифтә болай дип әйтелгән: «Белем алу – һәр мөселман ир һәм мөселман хатын-кызның бурычы»[1]. Бу хәдистә әйтелгәнчә, һәр мөселман өйрәнергә тиеш (фарыз гайн) булган гыйлем бар. Мондый гыйлемгә ышану (иман), Ислам һәм әхлак (ихсан) нигезләре турындагы белемнәр керә. Иман нигезләре фәне – гакыйдә, Ислам нигезләре (гыйбадәт кагыйдәләре) фәне – фикһ, ә әхлаклылыкны өйрәнә торган фән – тәсаввуф дип атала.

Гакыйдә фәне Аллаһы Тәгалә һәм Аның исем-сыйфатлары, шулай ук иманның калган өлешләре (Аның фәрештәләре, китаплары, пәйгамбәрләре, Кыямәт көне, тәкъдирнең яхшысы да, яманы да Аллаһыдан икәнлеге һәм үлгәннән соң янә терелү булачагы) турында белем бирә.

Фикһ фәненнән һәр мөселман фарыз булган намаз, зәкят, ураза һәм хаҗ турында кирәкле мәгълүматны алырга, аларның шартларын өйрәнергә тиеш. Моннан тыш, һәркемгә әле үзенең тормышында тоткан эш-гамәлләренә карата булган шарт һәм таләпләрне өстәмә рәвештә өйрәнергә кирәк. Мәсәлән, әгәр кеше сәүдә белән шөгыльләнә икән, ул динебез буенча сәүдә тәртипләрен өйрәнергә, әгәр ул табиб яки башка белгеч булса, шушы һөнәрдә үтәргә тиешле вазифаларын, аңа тыелган бөтен нәрсәне белергә бурычлы.

---

[1] Имам әт-Табарани.

Тәсаввуф фәненнән һәр мөселман, Аллаһы Тәгаләнең ризалыгына ирешү һәм җәһәннәм җәзасыннан котылу өчен, рухи-әхлакый чистарыну гамәлләренең кирәкле минимумын белергә тиеш.

Калган Ислам фәннәрен (тәфсир, үсүл әл-хәдис, үсүл әл-фикһ һ. б.) өйрәнү һәр мөселман өчен фарыз булып тормый. Ул фәннәрне дин галимнәре белергә тиеш. Алар бу фәннәрне фәтвалар чыгарганда, төрле дини сорауларга җаваплар биргәндә, халыкка шәригать кануннарын аңлатканда кулланалар. Ул фәннәрне өйрәнү фарыз кифәя булып тора, ягъни өммәтебезнең бер өлеше генә бу фәннәрне өйрәнсә, белсә, шул җитә.

Шулай итеп, фарыз гайн булып торган иң кирәкле гыйлем – ул Аллаһы Тәгаләнең исем-сыйфатларын белү һәм дөрес аңлау. Аллаһы Тәгаләгә ышанган, Аның сыйфатларын дөрес итеп кабул иткән кешенең гамәл-гыйбадәтләре кабул була. Ә Аллаһыга ышанмаган, я Аллаһыдан кала башка затларны илаһилаштырган, я Аллаһы Тәгаләнең сыйфатларын дөрес итеп кабул итмәгән кешенең гамәл-гыйбадәтләре кабул булмый. Шуңа күрә, Ислам галимнәре әйтүенчә, дини фәннәр арасында иң мөһим фән булып гакыйдә фәне санала.

Һәрбер пәйгамбәр, халыкка динне җиткергәндә, башта гакыйдәне, аннары шәригатьне (гыйбадәт мәсьәләләрен) тиешенчә аңлаткан. Барлык пәйгамбәрләрнең гакыйдәсе бер, ә шәригатьләре исә төрле булган. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Миңа кадәр булган бөтен пәйгамбәрләр һәм мин әйткән иң фазыйләтле сүзләр: «Ләә иләәһә илләллаһу вәхдәһу ләә шәриикә ләһу» (Аллаһыдан башка илаһ юк, Ул бердәнбер һәм Аның тиңдәше юк)»[1].

Гакыйдә – динебезнең нигезе, шуңа күрә аны башкача «үсүл әд-дин» («диннең нигезләре») дип атыйлар. Гакыйдәбез дөрес, нык булса, иншәАллаһ, гамәлләребезнең дә уңай нәтиҗәсе булачак. Гакыйдәне өйрәнергә тырышыйк һәм балаларыбызга, оныкларыбызга өйрәтик.

---

[1] Имам Мәлик, «Әл-Муватта».

Фарыз гайн булып торган икенче кирәкле белем – гыйбадәт кагыйдәләрен белү, ягъни тәһарәт, госел алу, намаз уку, ураза тоту тәртибен белү. Бу гыйбадәтләрне башкармыйча, без чын мөэмин дәрәҗәсенә, Аллаһының ризалыгына ирешә алмыйбыз. Бу кагыйдәләрне мәчет-мәдрәсәләрдә тәҗрибәле мөгаллимнәрдән алырга тырышсак иде.

Фарыз гайн булып торган өченче кирәкле белем – нәфесне тәрбияләү ысулларын белү, ягъни күңелне тискәре сыйфатлардан пакьләү, ихласлык, тәвәккәллек, тәкъвалык, мәрхәмәтлелек кебек күркәм сыйфатлар белән бизәкләү. Бу ысулларга да битараф булмыйча, рухи остазлардан дәрес алырга тырышыйк.

Дөрес гыйлемгә һәм күркәм әхлакка ия булучылар мәңге бәхетле булачаклар, Аллаһы ризалыгына ирешәчәкләр. Алар турында Коръәндә болай дип әйтелгән:

قُلْ هَلْ يَسْتَوِي الَّذِينَ يَعْلَمُونَ وَالَّذِينَ لَا يَعْلَمُونَ ۗ إِنَّمَا يَتَذَكَّرُ أُولُو الْأَلْبَابِ ﴿٩﴾

**«Әйт: «**[Исламны] **Белгән** [һәм белгәне белән яшәгән] **кешеләр белән** [хакны] **белмәгән** [шул сәбәпле, наданнарча эш йөрткән һәм адашу эчендә югалып калган] **кешеләр тиң була аламы?» Аек акылларга ия кешеләр генә үгетләнә».**

«Әз-Зүмәр / Төркемнәр», 39:9

يَرْفَعِ اللَّهُ الَّذِينَ آمَنُوا مِنكُمْ وَالَّذِينَ أُوتُوا الْعِلْمَ دَرَجَاتٍ ۚ

**«... Аллаһы да арагыздан иман китергәннәрне һәм гыйлем бирелгән кешеләрне дәрәҗә ягыннан күтәрер».**

«Әл-Мүҗәдәлә / Бәхәсләшү», 58:11

فَاسْأَلُوا أَهْلَ الذِّكْرِ إِن كُنتُمْ لَا تَعْلَمُونَ

**«Әгәр сез белмәсәгез, зикер ияләренән сорагыз».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:43

إِنَّمَا يَخْشَى اللَّهَ مِنْ عِبَادِهِ الْعُلَمَاءُ

**«Коллары арасыннан галимнәр генә Аллаһыдан курка».**

«Фатыйр / Бар кылучы», 35:28

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Нияз хәзрәт Сабиров,*

*Казанның Апанай мәчете имам-хатыйбы*

*17 нче гыйнвар вәгазе,*

*раҗәб аеның 17 нче көне, һиҗри исәп буенча 1446 ел*

# Фәрештәләр дөньясы

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Галәмнәрне юктан бар кылып, бөтен җанлы вә җансыз затларны тәрбияләүче Аллаһыга олуг мактаулар булсын. Шушы дөнья мәдрәсәсенең ахыргы рухи укытучысы, нәсыйхәт бирүчесе, кешеләрнең иң хәерлесе булган Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән чыккан салават-шәрифләребез булса иде.

Аллаһы Раббыбыз барлыкка китергән затлар арасында төрлеләре бар. Ул аларның кайсыларын – балчыктан, кайсыларын – уттан, ә кайсыларындыр нурдан бар кылган. Хайваннарга нәфес биреп, акыл бирми яраткан; кеше вә җенгә акыл һәм нәфес биргән; ә инде фәрештәләргә Раббыбыз фәкать акыл биреп, нәфес йөгеннән азат иткән.

Бүгенге вәгазь дә нәкъ фәрештәләр хакында булыр. Аларны Раббыбыз төрле итеп яраткан. Фәрештәләр нурдан яратылу сәбәпле, без аларны күрмибез, әмма алар безне күрәләр һәм алар һәрвакыт безнең янәшәдә, тормышыбыз алар белән тыгыз бәйле. Алар арасыннан иң бөекләре исә дүртәү: Җәбраил, Микаил, Исрафил, Газраил галәйһимүссәлам. Бу бөек фәрештәләрнең һәрберсенең үз вазифасы бар. Җәбраил фәрештә галәйһиссәлам – пәйгамбәрләргә Аллаһыдан хәбәр алып килүче. Микаил фәрештә галәйһиссәлам – адәм балаларының ризыклары белән идарә итүче, һәм табигать күренешләре аның кулында. Исрафил фәрештә галәйһиссәлам

сурга өрү белән Кыямәт көне башланачак. Газраил фәрештә галәйһиссәламгә әҗәлләре җиткән бәндәләрнең җаннарын алу вазифасы йөкләнгән. Газраил галәйһиссәламнең ике ярдәмчесе бар. Бу рәхмәт һәм газап фәрештәләре. Кеше нинди тормыш кичерсә, шундый хәлдә аның җаны чыга, аны шул фәрештә каршы ала. Изге юлда йөрүчене – рәхмәт фәрештәсе, ә инде гөнаһ әһелен газап фәрештәсе каршы ала.

Коръәни Кәримдә бу фәрештәләр хакында болай дип әйтелә:

نَزَلَ بِهِ الرُّوحُ الْأَمِينُ ﴿١٩٣﴾ عَلَىٰ قَلْبِكَ لِتَكُونَ مِنَ الْمُنذِرِينَ ﴿١٩٤﴾

«[Дин мәсьәләсендә кешеләрне терелткән вәхи ышанычлы бер юл белән китергәне сәбәпле] **Рух әл-Әмин** [дигән исеме дә булган Җәбраил] **аны иңдерде. Синең күңелеңә, син** [дә элек вәхи алган пәйгамбәрләр кебек, өммәтеңне хәвеф-хәтәрләрдән] **кисәтүчеләрдән булырсың дип».**

«Әш-Шүгәра / Шагыйрьләр», 26:193–194

مَن كَانَ عَدُوًّا لِّلَّهِ وَمَلَائِكَتِهِ وَرُسُلِهِ وَجِبْرِيلَ وَمِيكَالَ فَإِنَّ اللَّهَ عَدُوٌّ لِّلْكَافِرِينَ ﴿٩٨﴾

**«Кем Аллаһыга, Аның фәрештәләренә, пәйгамбәрләренә,** [бигрәк тә фәрештәләрнең иң олуглары булган] **Җәбраилгә һәм Микаилгә дошман?** [Шул яхшы белсен:] **Һичшиксез, Аллаһы да** [бит] **– кяферләргә дошман».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:98

وَاسْتَمِعْ يَوْمَ يُنَادِ الْمُنَادِ مِن مَّكَانٍ قَرِيبٍ ﴿٤١﴾ يَوْمَ يَسْمَعُونَ الصَّيْحَةَ بِالْحَقِّ ۚ ذَٰلِكَ يَوْمُ الْخُرُوجِ ﴿٤٢﴾

«**Тыңла!** [Сурга өреп] **Мөрәҗәгать итүче** [Исрафил фәрештә һәркем бертигез дәрәҗәдә ишетерлек] **якын бер урыннан чакырган көнне** [бөтен җан ияләре каберләреннән чыгарылачаклар]**.** [Икенче кат сурга өрелгәч кубачак] **Көчле тавышны хак белән** [бөтен барлыклары белән] **ишетәселәре көн. Бу –** [каберләрдән] **чыгу көне».**

«Каф», 50:41–42

قُلْ يَتَوَفَّاكُم مَّلَكُ الْمَوْتِ الَّذِي وُكِّلَ بِكُمْ ثُمَّ إِلَىٰ رَبِّكُمْ تُرْجَعُونَ ﴿١١﴾

«[Расүлем! Аларның бу сүзләрен кире кагар өчен] **Әйт: «Сезнең** [рухларыгызны тотып алу] **белән җаваплы кылынган үлем фәрештәсе сезне** [җаннарыгызны алып] **вафат иттерәчәк. Шуннан соң** [терелтелеп] **Раббыгызга кайтарылачаксыз.** [Раббыгызга ничек җавап бирәчәгегезне яхшы уйлагыз!]»

«Әс-Сәҗдә», 32:11

Бу фәрештәләрдән тыш, безнең ике ягыбызда гамәлләребезне язып торучы, кабердә сорау алучы, саклаучы, йортларыбызда булучы, таулар, җилләр фәрештәләре һәм бүтән башкалары бар. Ә иң кызыклысы: шундый фәрештәләр бар, алар барлыкка китерелгәннәреннән бирле гел тәсбих әйтеп, сәҗдә, рөкугъ кылып, дога кылып торучы фәрештәләр. Һәм алар инде ничә мең еллар дәвамында шушы халәтләрендә торалар.

Фәрештәләр нәфестән азат булу сәбәпле, алар гөнаһка кермиләр, бозык-фәсәд кылмыйлар, ялган һәм башка начарлыкка бармыйлар. Алар һәрвакытта Аллаһы Тәгалә кушканны үтиләр. Фәрештәләр калебенә Аллаһы Тәгаләгә карата буйсыну хисе салынган. Фәрештәләр Аллаһы Тәгалә әмере белән кешеләргә төрле-төрле нигъмәт алып киләләр. Фәрештәләрне күрү – пәйгамбәрләргә хас сыйфат, әмма аерым очракларда фәрештәләр кеше кыяфәтенә кереп, гади кешеләргә дә күренә алалар.

Шулай ук гади кешеләр, фәрештәләрне күрмәсәләр дә, аларны тоя алалар. Әйтик, Коръән, намаз укыгач яки дога кылгач йортыбызда тынычлык, күңелгә рәхәтлек сизәбез икән, бу йортыбызга фәрештәләр кергәнне аңлата. Имам вазифасын башкарганда төрле өйләргә, төрле мәҗлесләргә барырга туры килә. Кайбер йортларга керүгә шундый тынычлык, рәхәтлек һәм нур сизелә, ә кайбер йортларда – караңгылык, шомлы һәм нурсыз бер халәт туа.

Кайсы йортларда фәрештәләр күп җыела? Әгәр йортларда Коръән укылса, намаз укылса, изге эштә йөрүче кешеләр торса, шушы йортта фәрештәләр булыр, Аллаһы теләсә.

Тик фәрештәләр керми торган йортлар һәм урыннар да бар. Бу эт тора торган, әхлаксыз җырлар яңгырый торган, хәмер эчелә, тавыш-гауга була торган, төрле сурәтләр эленеп куелган йортлар; шулай ук фәрештәләр бәдрәф, мунчага керми. Сихер белән шөгыльләнүче кешеләр йорты да шушы рәткә керә. Бик игътибарлы булырга кирәк, чөнки кайвакыт өшкерүче һәм дәвалау белән шөгыльләнүче кеше кыяфәтендә чынлыкта сихер белән шөгыльләнүчеләр була. Алар кешеләрне фәрештәләр белән сөйләшүләренә ышандырырга тырышалар, әмма фәрештәләр пәйгамбәрләрдән кала бүтән бер затка да Аллаһыдан ачык аятьләр алып килмәделәр.

Сихер тарихында ике фәрештә – Һарут вә Марут фәрештәләр – вакыйгасы да бар. Бу ике фәрештәне Аллаһы Тәгалә Сөләйман пәйгамбәр галәйһиссәлам яшәгән чорда кешеләрне сынар өчен җиргә җибәрә. Һарут вә Марут сихер турында белемнәрен таратканда: **«Без сезгә фетнә** [һәм сынау] **бит, сез** [бу сихерне өйрәнеп, хәләл булмаган нәрсәләргә ышанып] **кяфер булмагыз!»** – дип кисәтеп тора. Әмма кешеләр һәм шайтаннар алардан шушы ысулларны, гыйлемне алып, Коръәндә әйтелгәнчә **«зарар китергән, бер дә файда китермәгән нәрсәне өйрәнәләр иде»**. Һәм бу хакта Раббыбыз болай ди: **«Шиксез, алар моны** [тыелган сихерне] **сатып алган кешегә ахирәттә бернинди өлеш юклыгын яхшы беләләр иде. Җаннары хисабына сатып алган нәрсәләре** [никадәр] **яман!»**

Сүз уңаеннан шуны да әйтеп китәргә кирәк, кайбер китапларда һәм китап әһелләрендә Иблиснең дә фәрештә булганлыгы хакында языла һәм әйтелә. Әмма бу алай түгел, Иблис мәлгуньнең фәрештәләргә бернинди катнашы да юк. Ул җеннәр таифәсеннән була, һәм иманлы булуы сәбәпле, Аллаһы Тәгалә аны дүрт фәрештәдән дә бөегрәк кыла, әмма ул үзенең тәкәбберлеге сәбәпле бар дәрәҗәсен югалта.

Адәм баласы да шулай ук, әгәр ул тәкъва һәм ихлас булып, изгелекләр кыла икән, Аллаһы Тәгалә аны фәрештәләрдән өстен кыла. Әгәр инде ул имансызлык һәм гөнаһта хирыслык күрсәтсә, аны Раббыбыз хайваннан да түбән кыла. Аллаһы Тәгалә хак юлдан тайпылудан Үзе сакласын!

Фәрештәләр дөньясы – бер могҗиза һәм гаҗәп дөнья. Алар һәрвакыт гыйбадәттә булып, Аллаһыга безнең өчен хәерле догалар кылып торалар.

Фәрештәләр мәчетләрдә җәмәгать намазларында да катнашалар, без мөэмин кардәшләргә дога кылганда, алар безгә шуны ук теләп торалар. Хәзрәти Әбү әд-Дәрдә радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең шундый хәдисен тапшырган: «Әгәр бер мөселман үзенең дин кардәшенә дога кылса, аның баш очына билгеләнгән махсус фәрештә шушы догага: «Әмин! Сиңа да!» – дип әйтә»[1].

Фәрештәләр акыл ягыннан да бик яхшы дәрәҗәдә, алар һәрнәрсәне хәтерли, аңлый һәм алдан фаразлый ала. Фәрештәләр җир йөзенә төрле олуг көннәрдә төшәләр, мәсәлән, Кадер кичәсе төнендә. Бу хакта Раббыбыз Коръәни Кәримнең 97 нче сүрәсендә хәбәр итә:

تَنَزَّلُ الْمَلَائِكَةُ وَالرُّوحُ فِيهَا بِإِذْنِ رَبِّهِم مِّن كُلِّ أَمْرٍ ﴿٤﴾

**«Ул кичәдә, Раббыларының рөхсәте белән, фәрештәләр һәм Рух** [дип тә аталган Җәбраил [галәйһиссәлам] **һәртөрле эш өчен иңәләр».**

«Әл-Кадр / Кадер киче», 97:4

[1] Имам Мөслим җыентыгыннан.

Ягъни шушы төндә фәрештәләр җиргә бәрәкәт алып төшәләр һәм бәндәләрнең кылган гыйбадәтләрен Аллаһы Тәгаләгә тапшыралар.

Фәрештәләргә ышану – ул иман нигезләренең берсе. Аларның барлыгын инкарь итү кешене имансызлыкка чыгара, кешене имансыз итә. Бу очракта кешегә тәүбә кылып, иман кәлимәсен кабатлау зарур. Фәрештәләр – мөэминнәрнең дуслары, ә инде көферлек юлында йөрүчеләрнең дошманнары. Әгәр без туры юлдан баручылар булсак, Аллаһы Тәгалә безне фәкать рәхмәт фәрештәләре белән очраштырыр. Раббыбыз хак юлдан һәм ахирәттә җәннәтеннән аермасын!

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Алмаз хәзрәт Галимҗанов,*

*Саба районы Сатыш авылы мәчете имам-хатыйбы*

*24 нче гыйнвар вәгазе,*

*раҗәб аеның 24 нче көне, һиҗри исәп буенча 1446 ел*

# Исра вә Мигъраҗ

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Барча мактауларыбыз галәмнәрне юктан бар кылучы, барчабызны да һәрдаим нигъмәтләндереп торучы, һәр гамәлебезне белүче Аллаһы Тәгаләгә. Һәм Аның хәбибе Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават-шәрифләребез булса иде!

Мөхтәрәм дин кардәшләрем, без сезнең белән фазыйләтләргә бай булган раҗәб аенда яшибез. Билгеле, раҗәб, шәгъбан һәм Рамазан айлары изге айлардан санала. Алдагы икесе – раҗәб һәм шәгъбан – Рамазан аена әзерләнү, үз-үзеңне рухи һәм физик яктан чыныгуга, чистарынуга, үзгәрүгә әзерлек айлары булып тора.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Коръәни Кәрим кеше сүзеннән ничек өстен булса, раҗәб ае башка айлардан шулай аерылып тора. Мин башка пәйгамбәрләрдән ничек өстен булсам, шәгъбан ае башка айлардан шулай аерылып тора. Һәм Аллаһы Тәгалә Үз мәхлукларыннан ничек бөек, өстен булса, Рамазан ае башка айлардан шулай өстен булып тора».

Ислам тарихы сәхифәләрен барласак, раҗәб ае нинди вакыйгаларга бай икән соң? Раҗәб аеның 26 нчы киченнән 27 нче көнгә каршы булган төн – Исра һәм Мигъраҗ кичәсе. Исра вә Мигъраҗ Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә Аллаһы тарафыннан бүләк ителгән могҗизаларның

берсе булып тора. Ислам тарихында гаҗәеп зур урын алган әлеге вакыйгалар, ягъни пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең төнге сәяхәте һәм аның күккә ашуы, быел гыйнвар аеның 26 нан 27 нә туры килә.

Исра – ул пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Мәккә шәһәреннән Әл-Кудс (Иерусалим) шәһәренә күчүе, ә Мигъраҗ – аның Раббыбыз хозурына ашуы, күкләргә күтәрелүе.

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең күккә ашуы турында Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримендә болай дип әйтә:

سُبْحَانَ الَّذِي أَسْرَىٰ بِعَبْدِهِ لَيْلًا مِّنَ الْمَسْجِدِ الْحَرَامِ إِلَى الْمَسْجِدِ الْأَقْصَى الَّذِي بَارَكْنَا حَوْلَهُ لِنُرِيَهُ مِنْ آيَاتِنَا ۚ إِنَّهُ هُوَ السَّمِيعُ الْبَصِيرُ ﴿١﴾

**«**[Бер айлык юлны бер төн эчендә үтү, Бәйт Әл-Мәкъдисне зиярәт кылу, бөтен пәйгамбәрләрне тере килеш күрү, җиде кат күктә аларның урыннарында булу һәм Җәмалыбызны күрү кебек] **Аятьләребездән кайберләрен күрсәтик дип, бер төнне** [бик кыска бер вакытта Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм] **колын Харам мәчетеннән** [алып] **Без тирә-ягын бәрәкәтле иткән Әл-Әкъса мәчетенә күчерүче** [булган Аллаһы ниндидер бер урында булудан һәм бөек Затына килешми торган төрле түбән сыйфатлардан ерак һәм бөтен] **кимчелекләрдән пакь. Һичшиксез, Ул –** [һәрнәрсәне] **Ишетүче, Күрүче».**

«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:1

Пәйгамбәрлекнең 10 нчы елы Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм өчен бик авыр булган, ул каты югалтулар кичергән: абыйсы Әбү Талиб һәм хатыны Хәдичә радыяллаһу ганһә вафат булган.

Бу вакыйгалардан соң Аллаһы Раббыбыз аңа зур бүләк ясый. Бер төнне Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм кичен Кәгъбә янында булган вакытта, Җәбраил фәрештә галәйһиссәлам килгән. Ул үзе белән Бурак дигән хайванны алып килгән. Һәм Пәйгамбәребез галәйһиссәлам шушы

Буракка атланып, күз ачып йомганчы, яшен тизлегендә изге Мәккәдән Әл-Кудс шәһәрендәге Әл-Әкъса мәчетенә килеп җитә.

Әл-Әкъсага җыелган барлык пәйгамбәрләр Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә оеп намаз укыган. Шуннан соң күктән яктылык баскычы төшерелгән, һәм бу баскычтан Мөхәммәд галәйһиссәлам Җәбраил фәрештә белән күккә күтәрелгән. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм җиде кат күк ишеге аша үткәндә, һәр күктә үзенә кадәр килеп киткән пәйгамбәрләр белән очрашкан.

Җәбраил фәрештә күкнең иң өске катына җиткәч: «Миңа куелган чик шушында бетте, алга таба барырга рөхсәт юк», – дип әйткән. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм сәфәрне үзе генә дәвам иткән. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм җәннәт белән җәһәннәм галәмәтләрен күргән һәм Аллаһы Тәгалә белән сөйләшү бәхетенә ирешкән.

Мигъраҗ вакыйгасы белән Аллаһы Тәгалә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне бик олылады. Хәдистә болай дип әйтелә: «Шуннан соң Аллаһы Тәгалә болай дип әйтте: «Ий Мөхәммәд, Мин сине Үземә дус иттем, Ибраһимны хәлилем иттем. Синең белән, Муса белән сөйләштем, ләкин сиңа өстенлек бирдем, синең өммәтеңне изге өммәт иттем. Ий Мөхәммәд, ий хәбибем, Мин сиңа биргән бүләгемне сакла, шөкер кылучылардан бул».

Раббыбыз Коръәндә:

لَقَدْ رَأَىٰ مِنْ آيَاتِ رَبِّهِ الْكُبْرَىٰ ﴿١٨﴾

**«Ул Раббысының иң бөек аятьләреннән иң әһәмиятле бер өлешен** [Мигъраҗ кичәсендә] **күрде»,** – дип әйтә.

«Ән-Нәҗм / Йолдыз», 53:18

Әйткәнебезчә, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу төнге сәфәрендә җәннәт вә җәһәннәмне үз күзләре белән, җаны, тәне вә гакылы белән күргән. Ул җәннәттә булачак мөэмин-мөселманнарның кабатланмас

җәннәт бакчаларында торуларын һәм җәһәннәмдә гөнаһлы бәндәләрнең коточкыч газаплар алуын күргән.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм өммәте өчен Аллаһыдан гафу үтенеп: «Йә Раббым, миңа өммәтемне җәннәтле итә торган бер гыйбадәт бирче», – дип сораган. Аллаһы Тәгалә: «Тәүлеккә 50 вакыт намаз укысалар, өммәтең җәннәтле булыр», – дип әйткән. Пәйгамбәребез бу хәбәрне ишеткәч, бик сөенгән. Кайткан юлында Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә Муса пәйгамбәр галәйһиссәлам очраган һәм мондый киңәшен биргән: «Син Аллаһы Тәгалә хозурына кабат бар. Синең өммәтең бит кәсеп итә, эшли, гаиләләренең тормышын алып барасылары бар, җирдә яшиселәре бар, алар 50 вакыт намазны үти алмасалар, җәннәткә керә алмаслар. Аллаһы Тәгалә хозурына барып, киметүен сора», – дип әйткән. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Аллаһы хозурына кабат-кабат барып, намазны киметүен сораган. Шул рәвешле, ул тугыз мәртәбә барып сораганнан соң, намаз бишкә калдырылган.

Бу хакта хәзрәти Әнәс бине Мәлик радыяллаһу ганһе болай дигән: «Мигъраҗ төнендә Аллаһының Расүленә илле тапкыр намаз укырга йөкләнелде. Соңыннан аңа: «Әй Мөхәммәд! Шиксез, Безнең сүзебез үзгәрмәс. Синең өммәтеңә йөкләнгән биш тапкыр кылыначак намаз савабы буенча илле тапкыр укылган намазга тиң булыр», – дип әйтелде»[1].

Биш вакыт намаз фарыз кылынганчы, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Ибраһим галәйһиссәлам кебек иртән-кичен ике рәкәгать намаз укый торган булган. Исра вә Мигъраҗдан соң иртә белән Җәбраил галәйһиссәлам килеп, Пәйгамбәребезне намаз уку тәртибенә өйрәткән. Һәм алар көн дәвамында, вакыты керү белән, бергәләп биш вакыт намаз укыганнар.

Гомумән Мигъраҗ вакытында Аллаһы Тәгалә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә өч олуг бүләк тапшыра:

---

[1] Имам әл-Бохари, Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

1. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә Кыямәт көнендә үз өммәте өчен шәфәгать хокукы бирелә.

2. «Әл-Бәкара» сүрәсенең ахыргы ике аяте иңдерелә.

3. Биш вакыт намаз фарыз кылына.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, бу вакыйгадан без бик күп гыйбрәтләр һәм дәресләр ала алабыз. Шуларның берсе – ул Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең башка расүлләрдән булган өстенлеге. Әлбәттә, Аллаһы Тәгалә һәр расүленә, һәр пәйгамбәргә бер өстенлек биргән. Нух галәйһиссәламне көймәдә коткарган, Ибраһим галәйһиссәламне уттан исән-имин килеш чыгарган, Муса галәйһиссәлам белән Аллаһы Раббыбыз сөйләшкән, Гайсә галәйһиссәламне коткарып, Үз хозурына күтәргән. Ә Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмне Аллаһы Тәгалә иң соңгы пәйгамбәр иткән, аны бөтен дөнья халкына расүл кылган һәм аңа моңарчы бер кешегә дә күрсәтелмәгән күкләрнең серләрен ачкан, аның белән турыдан-туры сөйләшкән. Моңарчы беркем дә әле мондый өстенлекләргә ия булмаган.

Исра вә Мигъраҗның икенче олуг бүләгенә – «Әл-Бәкара» сүрәсенең соңгы аятьләренә – тукталып китик. Аның 285 нче аятендә Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

كُلٌّ آمَنَ بِاللَّهِ وَمَلَائِكَتِهِ وَكُتُبِهِ وَرُسُلِهِ لَا نُفَرِّقُ بَيْنَ أَحَدٍ مِّن رُّسُلِهِ ۚ

**«...Барысы да Аллаһыга, фәрештәләренә, китапларына, пәйгамбәрләренә иман китерделәр. «Аның пәйгамбәрләреннән берсен дә башкаларыннан аермыйбыз»** [диделәр]**».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:285

Барлык иман китерүчеләр дә Аллаһының барлыгына һәм Аның бер булуына ышана. Аннан башка бүтән илаһ юк, һәм Аннан башка Раббыбыз юк. Шулай ук мөселманнар барлык пәйгамбәрләргә вә расүлләргә һәм аларга Аллаһы тарафыннан җибәрелгән изге китапларга ышаналар.

Аллаһы Раббыбыз һәр халыкка туры юлга чакыручы, гөнаһлардан саклаучы пәйгамбәрләр җибәргән. Бу пәйгамбәрләр – шушы халык, кешеләр арасыннан ук сайлап алынган иң камил әхлаклы, иң гадел, гөнаһсыз, бер Аллаһыга гына гыйбадәт кылучы кешеләр булган. Раббыбыз Җәбраил фәрештә аша аларга әмерләрен, изге китапларны иңдереп торган.

Аллаһы Тәгалә пәйгамбәрләрне төрле вакытта һәм төрле халыкларга җибәргән. Әмма җир йөзендә яшәгән бар пәйгамбәрләрнең дә бурычлары бер булган – кешеләрне бер Аллаһыга гына гыйбадәт кылырга һәм Ул кушканнарны үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәргә чакыру; Кыямәт көне булачагын һәм барлык кылган гамәлләр өчен ахирәттә җавап бирергә кирәк булачагын аңлату; халыкның әхлагын камилләштерү. Әмма төрле пәйгамбәрләрнең гыйбадәтләре, шәригатьләре төрле булып, аерылып торган. Беләбез, мәсәлән, төрле пәйгамбәрләр ураза тоткан, әмма Рамазан аенда фарыз ураза Мөхәммәд галәйһиссәлам килгәч кенә әмер ителгән. Шулай ук хаҗ, намаз һәм тәһарәт тәртипләре дә төрле пәйгамбәрләрдә төрле булган.

Беренче пәйгамбәр – беренче кеше – атабыз Адәм гәләйһиссәлам була, ә соңгысы – Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм. Һәм Мөхәммәд галәйһиссәламнән соң җир йөзендә башка пәйгамбәрләр булмаячак, аның шәригате, ягъни Ислам шәригате, ул өйрәтеп калдырган кануннар, ул халыкка җиткергән Изге Китап (Коръәни Кәрим) – Кыямәт җиткәнчегә кадәр соңгылары.

Пәйгамбәрләргә һәм расүлләргә ышану – динебездә иман нигезләренең берсе һәм һәр мөселманның бурычы. Шуңа күрә, дин кардәшләрем, без Коръәндә искә алынган пәйгамбәрләргә ышанып, аларны хөрмәт итәргә тиешле. Кайберәүләр, гыйлемсезлектән, Муса – ул яһүдиләрнең генә пәйгамбәре, ә Гайсәгә христианнар гына ышана, дип уйлый. Бу зур хата, мөселманнар да, әлбәттә, бу һәм башка пәйгамбәрләрне таный, алар җир йөзендә яшәгән, Аллаһы тарафыннан сайлап алынган, аларның да үз

могҗизалары булган, алар да кешеләрне бер генә Аллаһыга ышанырга өндәгән, ширек, гөнаһ кылудан кисәткән.

Галимнәребез Коръәндә телгә алынган егерме биш кешене пәйгамбәр дип таный. Әмма, Коръәндә хәбәр ителә: пәйгамбәрләр егерме биш кенә булмаган, Аллаһы Тәгалә бик күп пәйгамбәр җибәргән. Мәсәлән:

وَلَقَدْ أَرْسَلْنَا رُسُلًا مِّن قَبْلِكَ مِنْهُم مَّن قَصَصْنَا عَلَيْكَ وَمِنْهُم مَّن لَّمْ نَقْصُصْ عَلَيْكَ ۗ

**«Синнән алда да Без расүлләр җибәргән идек. Алар арасыннан Без** [кыйссаларын] **сиңа сөйләгәннәре дә бар, шулай ук алардан Без сиңа сөйләмәгәннәре дә бар».**

«Гафир / Гафу итүче», 40:78

وَلِكُلِّ أُمَّةٍ رَّسُولٌ ۖ

**«Һәрбер өммәтнең** [дөньяда хаклыкка өндәү, ахирәттә шаһитлык кылу өчен билгеләнгән] **расүле бар».**

«Юныс», 10:47

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең үзенә кадәр килгән пәйгамбәрләрдән төп аермасы – элекке пәйгамбәрләр үз халкына гына җибәрелгән була, ә Мөхәммәд галәйһиссәлам бөтен кешелек өчен җибәрелгән. Үзенең бер хәдисендә ул болай дип әйтә: «[Минем алдымда] Пәйгамбәр үз халкына гына җибәрелде, ләкин мин барлык кешеләргә җибәрелдем».

Шулай ук Аллаһы Тәгалә аңа Кыямәт көнендә кешеләр өчен берничә тапкыр шәфәгать итү мөмкинлеген бирде.

Раббыбыз барчабызга да гыйбадәтләребезне тиешенчә үтәп, Ул кушканча һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм өйрәтеп калдырганча

яшәргә һәм Кыямәт көнендә Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең шәфәгатенә ирешергә насыйп итсен! Әмин!

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Илдар хәзрәт Шагалиев*

*Питрәч районы Званка авылы мәчете имамы*

*31 нче гыйнвар вәгазе,*

*шәгъбан аеның 1 нче көне, һиҗри исәп буенча 1446 ел*

# Шәгъбан аеның фазыйләтләре

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Газиз дин кардәшләрем, дөньялыкта безнең һәрберебез дә мөһим эш алдыннан, шушы эш уңышлы килеп чыксын өчен, аңа алдан ук хәстәрләнә, әзерләнә. Мәсәлән, берәребез зур сәфәргә җыена икән, сәфәре уңышлы булсынга, ул алдан машинасын карап, кирәк-яракларын алып куя. Имтихан бирәсе кешенең дә имтиханга кадәр тырышып укуын, ятлавын беләбез.

Без дөньяви эшләрдә бик тырышабыз, җиң сызганып эшлибез. Әлбәттә, сүз дә юк, дөньялыкны да кайгыртырга, кәсеп кылырга тиешбез, чөнки Раббыбыз «Касас» сүрәсенең 77 нче аятендә: **«Дөньяңнан да насыйбыңны онытма»,** – ди. Ләкин без, беренче чиратта, ахирәтебез турында борчылырга, аны хәстәрләргә тиешбез. «Касас» сүрәсенең ошбу аяте алдыннан Раббыбыз Коръәндә түбәндәге аятьне китерә:

قَالَ لَهُ قَوْمُهُ لَا تَفْرَحْ ۖ إِنَّ اللَّهَ لَا يُحِبُّ الْفَرِحِينَ ﴿٧٦﴾ وَابْتَغِ فِيمَا آتَاكَ اللَّهُ الدَّارَ الْآخِرَةَ ۖ وَلَا تَنسَ نَصِيبَكَ مِنَ الدُّنْيَا ۖ

**«Менә каveме аңа әйткән иде: «**[Малыңның күплеге белән мактанып] **Сөенмә! Һичшиксез, Аллаһы** [тәкәбберләнеп] **сөенүчеләрне сөйми** [һәм аларның мондый гамәлләреннән разый булмый]**.**

**Аллаһы сиңа биргән** [хәзинәләр һәм киң мөмкинлекләр тулы] **нәрсәләрдә соңгы йортны** [аның савапларын] **эзлә. Дөньяңнан да насыйбыңны онытма!»**

«Әл-Касас / Кыйсса», 28:76–77

Ахирәтебез – безнең мәңгелегебез, аның хакында уйланырга, борчылырга тиешбез. Раббыбыз:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا اللَّهَ وَلْتَنظُرْ نَفْسٌ مَّا قَدَّمَتْ لِغَدٍ ۖ

**«Ий иман китерүчеләр! Аллаһыдан куркыгыз һәм** [кешеләрнең күбесе гафләт эчендә булса да, һичьюгы бер генә] **җан** [булса да, үзе яшәгән көннән] **иртәгәлек** [кебек якын булган Кыямәт көне] **өчен элегрәк ни әзерләгәнен карасын!»** – дип әйтә.

«Әл-Хәшр / Җыен», 59:18

Син ахирәтең өчен нәрсә әзерләп куйдың – шуны кара, шуны уйла, шуның турында фикерлә.

Ахирәт өчен кәсеп кыла торган иң бәрәкәтле ай булган Рамазан да якынлашып килә. Без хәзер шәгъбан аенда. Шәгъбан – ул Рамазанга әзерлек ае. Шуңа Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм шәгъбан аеның күп көннәрендә ураза тота торган булган.

Гайшә радыяллаһу ганһә тапшырган хәдистә болай диелә: «Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм шәгъбан аенда тоткан кебек күп итеп башка айларда ураза тотмады». Биредә сүз нәфел ураза турында бара, әлбәттә, Рамазан ае монда керми. Шулай ук Пәйгамбәребез галәйһиссәлам кайчагында шәгъбанның берничә көненнән кала бөтен көнендә дә ураза тота торган булган. Ягъни ул бу айның күпчелек көнедә уразага кергән.

Бервакыт хәзрәти Үсәмә бине Зәйд радыяллаһу ганһе Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән бу айда ураза тотуының сәбәбен сорагач, Расүлебез: «Шәгъбан – кешеләр гафил булган ай, раҗәб белән

Рамазан арасында урнашкан ай. Шушы айда гамәлләр Аллаһы Тәгаләгә күтәрелә, һәм мин гамәлләремнең мин ураза тоткан халәттә күтәрелүен телим», – дип әйткән[1].

Башка хәдисләрдән күренгәнчә, Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм шәгъбан аеның икенче яртысында ураза тотарга киңәш итмәгән. Әмма кеше гадәттә ел дәвамында дүшәмбе, пәнҗешәмбе, ай уртасындагы өч көндә өстәмә уразалар яки Давыд пәйгамбәр уразасын тотса, ул бу сөннәтен шәгъбанның ахырында да дәвам иттерә ала. Андый кешегә шәгъбан аеның икенче яртысында да ураза тоту саваплы булыр. Димәк, Рамазан алдыннан кеше арып китмәсен өчен, нигездә аңа шәгъбан аеның соңгы көннәрендә ураза тотарга киңәш ителмәгән.

Шәгъбан аенда ураза тоту турындагы хәдисләрне җыйганнан соң, галимнәр айның беренче яртысында, әйтик, беренче 15 көнендә ураза тотуның сөннәт булуын әйтә. Кем дә кем ураза тота ала икән, моны башкарырга тырышсын. Көн саенмы, көн аралашмы – ничек булдыра ала, уразага шулай керсен. Әгәр мөселман кешесе: «Рамазан аенда ураза тотарга көчем кала», – дип уйлый икән, аңа шәгъбан аеның икенче яртысында да ураза тотарга ярый. Яисә, әйткәнемчә, кемдер һәрвакыт ниндидер нәфел уразалар тота икән, андый кешегә дә шәгъбан ахырында ураза тоту дөрес. Әгәр кеше: «Шәгъбан аеның икенче яртысында ураза тоту сәбәпле, Рамазанга көчем калмый», – дип уйласа, ул очракта аңа бу көннәрдә ураза тоту хәерле түгел.

Рамазан аена ниндидер бер әзерлек белән керер өчен, булдыра алган кеше, шәгъбан аенда уразасын тырышып тотсын. Рамазанга башка төр гыйбадәтләр кылуны гадәткә кертеп тә әзерләнергә була. Әйтик, тәравих намазларында торыр өчен, шәгъбанда төнге намазлар укуны гадәткә кертергә була.

Аллаһы Тәгаләне зикер итү, Коръәни Кәримне укуга да алдан ук әзерләнү мөһим. Коръән уку – ул Рамазан аеның үзенчәлеге. Рамазан ае – Коръән ае. Шуңа без Рамазан аенда тиешенчә, яхшы итеп, сыйфатлы, күп

[1] Имам ән-Нәсаи.

итеп Коръән укырга телибез икән, без аңа алдан ук әзерләнеп куйсак, бер дә комачау итмәс. Һәрберебез Рамазанда бер тапкыр булса да хатем кылырга ниятләсен. Кем дә кем Коръәни Кәримне авырлык белән укый икән, аны көн саен укырга дигән максат куйсын.

Кайбер сәхабәләребез, Коръәнне Рамазанда күбрәк укый алыр өчен, шәгъбан аенда ук аны хатем кыла торган булган. Арабызда бик күпләрнең, ничә ел диндә булса да, ничә ел намаз укыса да, гомерендә бер тапкыр да Коръәнне тулысынча укып чыкканы юк. Аллаһы Тәгаләнең бәрәкәтенә омтылабыз икән, без бу мәсьәләдә гафиллек, игътибарсызлык күрсәтергә тиеш түгелбез. Галимнәребез: «Коръән укыган саен, Аллаһы Тәгалә вакытыма һәм байлыгыма бәрәкәт бирде», – дип әйтә торган булганнар. Шуңа алар Коръән укуларын елдан-ел арттырып килгәннәр.

Рамазан аена без гыйлем алып та әзерләнергә тиеш. Бу айда булган хөкемнәрне белеп, кемгә ураза тиешле, Рамазанда нәрсә эшләргә ярый һәм нәрсә ярамый, уразаны ни боза, ни бозмый – боларны без алдан ук өйрәнергә, укырга тиеш. Әлхәмдүлилләһ, бүген моңа мөмкинлекләр бар.

Шулай ук Рамазан – ул догалар кылу ае. Шушы айдан ук догаларыбызны күбәйтеп, Рамазанга әзерләник. Раббыбыздан фазыйләтле Рамазанга ирешүне һәм дә ураза тотарга, башка изгелекләрне кылырга мөмкинлек, саулык-сәламәтлек сорыйк.

Шулай ук Рамазан – тәравих намазлары ае. Шәгъбан аенда ястү намазыннан соң өстәмә ике рәкәгать булса да яки күбрәк рәкәгатьләр белән төнге намазларыбызны укып, әзерләнсәк иде, изге айга лаек булуыбызны күрсәтсәк иде.

Галимнәребез шундый матур чагыштыру китерәләр: «Рамазан аенда җәннәт ишекләре ачыла һәм ай буе ябылмый» дигән хәдискә карасаң, әйтерсең лә без шәгъбан аенда шул капкалар төбендә басып торабыз һәм шул капкаларны төрле изгелекләр белән шакып торабыз. Ураза, өстәмә намазлар, Аллаһыны зикер итү, садака, Коръән уку, дога кылу, ярдәмләшү һәм башка

изгелекләр кылып шакыйбыз, Рамазанга лаеклы булуыбызны күрсәтергә тырышабыз.

Шуңа күрә, мөхтәрәм, газиз дин кардәшләрем, шәгъбан аен заяга уздырмыйк, Рамазанга әзерлекле килеш керик. Шул вакытта безнең Рамазан аебыз узган елгысына караганда яхшырак булачак. Раббыбыз барчабызга да саулык биреп, Рамазан аена исән-имин, әзерлекле килеш ирешергә насыйп итсен. Инде Рамазанны Аллаһы Тәгаләнең ризалыгына һәм мәгъфирәтенә ирешерлек итеп үткәрергә язсын иде. Әмин!

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җиткәнче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Сәид хәзрәт Хаков,*
*Сарман районы имам-мөхтәсибе*

*7 нче февраль вәгазе,*

*шәгъбан аеның 8 нче көне, һиҗри исәп буенча 1446 ел*

# Бәраәт кичәсе. Тәүбәнең әһәмияте

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Барча галәмнәрне юктан бар кылучы һәм барча мәхлукларын иксез-чиксез нигъмәтләре белән нигъмәтләндереп торучы бердәнбер Раббыбыз, Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгәләгә чиксез рәхмәтләребез һәм шөкраналарыбыз булсын. Галәмнәргә бары тик рәхмәт өчен генә җибәрелгән, безгә Ислам дине буенча яшәп күрсәткән сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән чыккан хәер-догаларыбыз, салават-шәрифләребез барып ирешсә иде. Ерак һәм якын җирләрдән изге җомга көнне Раббыбыз Аллаһы Тәгаләнең әмерен үтәр өчен мәчетебезгә җыелган мөхтәрәм дин кардәшләрем, барлык көннәрнең солтаны булган җомга көне мөбарәк һәм хәерле булсын! Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә ил-көннәребезгә, җаннарыбызга тынычлык, тәннәребезгә исәнлек-саулык, күңелләребезгә тәүфыйк-һидаять биреп, һәркайсыбызга хәерле һәм бәрәкәтле тормыш насыйп итсен. Мөкатдәс җомга көнне ихлас күңелдән хәерле гамәл-гыйбадәтләр кылып, Аллаһы Тәгаләнең иксез-чиксез рәхмәтләренә барчабызга да ирешергә насыйп булса иде!

Мөхтәрәм кардәшләребез, без Аллаһы Тәгаләдән безгә бүләк рәвешендә җиткерелгән айда, фазыйләтле шәгъбан аенда яшибез. Ул – изге Рамазан аена әзерләнү ае. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә шәгъбан аеның башка айлардан өстен булуын үзенең җир өстенә килеп

киткән барлык пәйгамбәрләрдән өстен булуына тиңләгән. Димәк, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм башка пәйгамбәрләргә караганда өстен булган кебек, шәгъбан ае да башка айларга караганда өстенрәк, фазыйләтлерәк. Ни өчен? Моның бер сәбәбе – бу айда Бәраәт кичәсе бар. Ә ул кичәдә Аллаһы Тәгаләнең фәрештәләре мөселманнарның хисаплары белән Аллаһы хозурына күтәреләләр. Шулай ук шәгъбан аен изге Рамазан алдыннан килгән бер баскыч дияргә була. Шәгъбанда өстәмә уразалар тоту – ул Рамазан аен әзерлекле рәвештә каршылау өчен Раббыбыздан безгә бирелгән бер форсат.

Шәгъбан аеның 14 нче көненнән 15 нче көнгә каршы киче (быел 13–14 февраль) «Бәраәт кичәсе» дип атала. Бу кичтә һәм көндә җир йөзенә Аллаһы Тәгаләнең рәхмәт вә мәгъфирәте таралыр. Гарәп теленнән «бәраәт» сүзе сафлык, гыйффәтлек, пакьлек дип тәрҗемә ителә, һәм бу кичәнең атамасы ук гөнаһлардан чистарынуга ишарәли. Шулай ук бу кичәнең мондый матур атамалары бар: «ләйлә әд-дүга» – «дога кылу кичәсе», «ләйлә әл-иҗәәбә» – «җавап бирелү кичәсе», «ләйлә әл-мүбәракә» – «мөбарәк булган кичә», «ләйлә әш-шәфәәга» – «шәфәгать кичәсе» һәм «ләйлә әл-гуфран» – «гафу ителү кичәсе». СөбханАллаһ, бу исемнәр үзләре үк күпне сөйләп тора.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хатыны Гайшә анабызга Бәраәт кичәсе турында шулай дигән: «Бу кичәдә Аллаһы Тәгалә Бәни Кәлб кабиләсе сарыкларының йон төкләре санынча кешеләрне җәһәннәмнән азат итәр». Ягъни мондый чагыштыру никадәр күп кешеләрнең тәүбәләре кабул булып, аларның җәһәннәм газапларыннан азат ителүен күрсәтү өчен китерелгән, чөнки без бер сарыкта гына никадәр төк барлыгын саный алмас идек, ә монда зур кабиләнең көтүләре искә алына. Башка бер хәдисендә дә Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм шундый хәбәр-нәсыйхәт биргән: «Бәраәт – сезнең өчен зур форсаттыр, бик күп мөмкинлекләр бирә торган изге кичтер. Кадер кичәсе, Бәраәт кичәсеннән бөегрәк булса да, аның кайчан булганы төгәл билгеле түгел. Шуңа күрә Бәраәт кичендә күбрәк гыйбадәт кылыгыз». Хәдисләрдән күренгәнчә, Бәраәт кичәсендә кешеләрнең бер еллык

гамәлләренә нәтиҗә ясалып, шул гамәлләр «архивка» тапшырылыр. Кем дә кем бу кичтә тәүбә-истигъфарлар кылып, кылган гөнаһлары өчен гафу үтенсә, иншәАллаһ, шушы ел дәвамында кылынган гөнаһлары кешенең гамәл дәфтәреннән сызылыр. Шулай итеп, мөселманнарга тәүбәгә килеп, гөнаһлардан арынып һәм дә инде гафиллектән уянып, Рамазан аена хәзерләнү кирәк.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, Аллаһы Тәгаләдән белеп һәм белмичә эшләгән гөнаһларыбыз өчен гафу-истигъфар сорап, Аңа якынаерга тырышсак иде. Мөселман кешесе бу файдалы эшне – тәүбә-истигъфарны кичектерергә (яисә иң куркынычы – бөтенләй дә калдырырга) тиеш түгел, чөнки адәм баласының тормышы өч көннән тора: беренчесе – узган, гыйбрәт алыначак көн; икенчесе – бүгенге көн, ганимәт көне; өченчесе – иртәгә яки киләчәк. Әмма без ул көнне күрә алырбызмы? Анысы Аллаһы Тәгаләгә генә мәгълүм. Без изге Рамазанга керә алабызмы, юкмы – моны безгә кем әйтә ала? Билгеле, беркем дә хәбәр бирә алмый. Раҗәб ае узып китте, киредән кайтмый, Рамазан ае – киләчәктә, аны күрү-күрмәвебез билгесез, ә шәгъбан ае исә бу ике ай арасында бер күпер булып тора. Шуңа күрә дә бу айда гыйбадәттә булу, киләчәк Рамазан аена әзерләнү, ихлас күңелдән Раббыбызга ялварып, гөнаһларыбыздан тәүбә кылу адәм баласы өчен иң мөһим эшләрдән булып тора.

Газиз дин кардәшләрем, без кайсы гына вакытта ихлас тәүбә кылсак, Раббыбыз аны кабул итә. Әмма шул ук вакытта Аллаһы Тәгалә безгә өстәп, Бәраәт кичәсен дә биргән, бу безне тагын да ныграк илһамландырырга, өметебезне арттырырга тиеш. Ә нәрсә соң ул тәүбә? Бу сүз гарәп телендә тәүбә итү белән беррәттән, нәрсәнедер эшләүдән туктауны һәм төзәлүне белдерә. Нинди генә гөнаһ кылсак та, ул зур яки кечкенә, башкалар күреп торган яки яшерен кылынган гөнаһ булсын, тәүбә кылу вәҗиб, тиешле булып тора.

Галимнәребез тәүбә кылуның 3 шартын китергән:

– беренчедән, тәүбә кылучы шушы мизгелдә үк гөнаһын калдырырга, аны кылуны туктатырга тиеш;

– икенче шарт – кылган гөнаһлы гамәлең өчен үкенү, Раббыңнан оялу;

– өченчедән, башка беркайчан да бу гөнаһны кылмаячакмын дип ниятләү, катгый карар кылу.

Димәк, күңелләребездә шушы өч шарт булмаганда, мәсәлән, без бүген тәүбә кылам да, иртәгә тагын шул гөнаһны кабатлыйм дисәк, бу инде тәүбә итү булмый. Газиз дин кардәшләрем, шунысы да мөһим: әгәр гөнаһ башка кешеләрнең хакларын үтәмәүгә яки бозуга бәйле икән, монда тәүбә итүнең тагын бер шарты өстәлә – ул хакларын бозган кешенең хакын үтәү яки аннан гафу үтенү. Мәсәлән, әгәр кеше күршесенең бер әйберен урлаган икән, Аллаһыдан гына гафу үтенү җитми, чөнки монда башка кешенең хакы бозылды. Башта урлаган кеше әйберне хуҗасына кайтарырга тиеш. Ә кайтара алмаса, гафу үтенеп, ничек тә бу эшне төзәтергә тырышырга тиеш: аңа башка әйбер алып бирәме ул, ниндидер бурычын үтиме – күршесенең ризалыгын алырга тиеш була.

Бәраәт кичендә тәүбә-истигъфарны арттырырга, күбрәк изгелекләр кылырга кызыктыра торган тагын бер хәдисене искә төшерик: «Шәгъбан аеның 15 нче кичен (Бәраәт кичәсен) гыйбадәт белән уздырыгыз. Көндез ураза тотыгыз, чөнки ул кичне Аллаһы Тәгалә кояшның чыгуына кадәр дөнья галәменә рәхмәт күзе белән карар вә шулай боерыр: «Гафу сораучы юкмы? Аны гафу итәм. Ризык сораучы юкмы? Аны ризыкландырам. Кайгылы вә авыру кеше юкмы? Шифасын бирәм. Моннан башка нинди теләкләре булса, сорасыннар – бирермен», – дияр. Вә бу хәл кояш чыкканчы дәвам итәр», – дип әйтелгән.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

قُلْ يَا عِبَادِيَ الَّذِينَ أَسْرَفُوا عَلَىٰ أَنفُسِهِمْ لَا تَقْنَطُوا مِن رَّحْمَةِ اللَّهِ ۚ
إِنَّ اللَّهَ يَغْفِرُ الذُّنُوبَ جَمِيعًا ۚ إِنَّهُ هُوَ الْغَفُورُ الرَّحِيمُ ﴿٥٣﴾

**«Әйт: «Ий үз-үзләренә каршы зрарда булган колларым! Аллаһының рәхмәтеннән өметегезне өзмәгез, чөнки Аллаһы** [ширектән тыш] **барлык гөнаһларны да ярлыкый!» Һичшиксез, Ул –** [гөнаһларны күпләп] **Гафу итүче, Рәхимле».**

«Әз-Зүмәр / Төркемнәр», 39:53

Акыллы кешегә һәрвакыт Аллаһыга тәүбә кылу, үзен гөнаһлы гамәлләрдән саклау тиешле. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Гөнаһ кылмый торган кол булмас. Әгәр ул күркәм рәвештә тәһарәт алып, ике рәкәгать намаз укыса, Аллаһыдан ярлыкауны сораса, Аллаһы Тәгалә аны ярлыкар». Моннан соң ул мондый аятьне укыган:

وَالَّذِينَ إِذَا فَعَلُوا فَاحِشَةً أَوْ ظَلَمُوا أَنفُسَهُمْ ذَكَرُوا اللَّهَ فَاسْتَغْفَرُوا لِذُنُوبِهِمْ وَمَن يَغْفِرُ الذُّنُوبَ إِلَّا اللَّهُ وَلَمْ يُصِرُّوا عَلَىٰ مَا فَعَلُوا وَهُمْ يَعْلَمُونَ ﴿١٣٥﴾ أُولَٰئِكَ جَزَاؤُهُم مَّغْفِرَةٌ مِّن رَّبِّهِمْ وَجَنَّاتٌ تَجْرِي مِن تَحْتِهَا الْأَنْهَارُ خَالِدِينَ فِيهَا ۚ وَنِعْمَ أَجْرُ الْعَامِلِينَ ﴿١٣٦﴾

**«Янә алар** [тәкъвалык ияләре, зур гөнаһлар кылып] **бик кабахәт бер нәрсә эшләсә яки** [кечерәк гөнаһ кылып] **үзләренә золым китерсә, Аллаһыны искә төшерәләр дә,** [шунда ук үкенә-үкенә тәүбә итеп] **гөнаһлары өчен ярлыкау сорыйлар. Гөнаһларны исә Аллаһыдан башка кем гафу итә? Һәм алар белә торып гөнаһларын кабатлауда үҗәтлек күрсәтмиләр.** [Расүлем!] **Әнә шуларның әҗерләре – Раббыларыннан** [киләчәк] **мәгъфирәт һәм алар мәңге калачак** [сарайлары вә агачлары] **асларыннан елгалар аккан җәннәтләр** [булыр]. [Болай] **Гамәл кылучыларның савабы нинди яхшы!»**

«Әл Гыйман / Гыймран гаиләсе», 3:135–136

Аллаһы Раббыбыз бер-беребезгә хөрмәт күрсәтеп, дус-тату булып яшәүләребезне насыйплардан әйләсә иде. Ислам динен дөрес итеп аңларлык гыйлем-зиһен бирсә иде. Төрле фетнәләрдән, ызгыш-талашлардан, сугыш афәтләреннән имин кылса иде. Раббыбыз кылган изгелекләребезне, тәүбәләребезне кабул итсен! Якынлашып килгән Рамазан айларына тиешенчә әзерләнеп, шушы мөбарәк айда хәерле гамәлләр кылып, калган гомеребезне иманлы булып үтеп, Аллаһы хозурына да иманлы җаннарыбыз белән ирешеп, Аның җәннәтләрендә әти-әниләребез, гаилә әһелләребез, якын дусларыбыз белән күрешеп, анда мәңгелеккә калырга насыйп булсын. Әмин!

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Илнур хәзрәт Фәрхетдинов,*

*Тукай районы Күзкәй авылы мәчете имам-хатыйбы*

*14 нче февраль вәгазе,*

*шәгъбан аеның 15 нче көне, һиҗри исәп буенча 1446 ел*

# Дога кылуның әһәмияте

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Без, мөселманнар, үзебез, ата-аналарыбыз, балаларыбыз, якыннарыбыз һәм барлык мөселманнар өчен догалар кылабыз һәм кылырга тиешлебез дә. Шулай ук без үзебезнең әрвахларыбызны да догадан калдырырга тиеш түгелбез. Алар да бездән дога көтә. Без, кемгәдер кушмыйча, үзебез, үзебезнең кулларыбызны күтәреп, үзебезнең телләребез белән үзебезгә дә, әрвахларыбызга да дога кылырга бурычлыбыз. Әлбәттә, башка берәүгә дә әйтеп дога кылдырырга була, әмма кешенең үзенең дога кылуы бик мөһим. Кеше үзе дога кылганда, Раббысыннан ихлас рәвештә, берни турында да уйламыйча, ярдәм сорый. Аллаһы Тәгалә безнең йөрәгебездә менә шушы ихласлылыкны, Аңа булган омтылышны, өметне күрергә тели. Кешенең ихлас догасы аны Раббысы Аллаһыга якынайта. Әгәр дә ул әлегә намазда булмаса, дога кылулары аны берзаман намазга китерәчәк, иншәАллаһ.

Аллаһы Раббыбыз Коръәндә болай дип әйтә:

وَمَا خَلَقْتُ الْجِنَّ وَالْإِنسَ إِلَّا لِيَعْبُدُونِ ﴿٥٦﴾

**«Мин җеннәрне һәм кешеләрне Миңа гыйбадәт кылсыннар дип яраттым».**

«Әз-Зарият / Таратучылар», 51:56

Ягъни, Миңа табынып, Миңа хезмәт кылып, Мине зурлап, Миңа буйсынып яшәсеннәр өчен дигән сүз бу.

Гыйбадәт фикһ фәнендә намаз, зәкят, ураза, хаҗ кебек гамәлләрне үз эченә ала һәм аларны өйрәнә. Әмма гомумән Исламда гыйбадәт – ул иман һәм ният белән, Аллаһыдан әҗер-савап өмет итеп, Ул кушкан яки Ул разый булган эшне эшләү яки сүзне сөйләү. Әгәр күңелдә иман, ихласлылык булмаса, эшләнгән эш гыйбадәт булмас һәм кабул ителмәс.

Шушы гыйбадәтләр арасында зур, мөһим урынны дога кылу алып тора. Хәзрәти Ногман бине Бәшир радыяллаһу ганһе сөйләгән хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Дөреслектә, дога – ул гыйбадәтнең үзе», – дигән һәм аннан соң әлеге аятьне укып күрсәткән[1]:

وَقَالَ رَبُّكُمُ ادْعُونِي أَسْتَجِبْ لَكُمْ ۚ إِنَّ الَّذِينَ يَسْتَكْبِرُونَ عَنْ عِبَادَتِي سَيَدْخُلُونَ جَهَنَّمَ دَاخِرِينَ ﴿٦٠﴾

«[Ий кешеләр!] **Раббыгыз әйтте: «**[Бертуктаусыз ялварсагыз да, сезгә бер генә җавап та бирмәячәк потлардан ярдәм өмет итүне туктатыгыз да] **Миңа дога** [һәм гыйбадәт] **кылыгыз,** [сораганнарыгызны үтәп] **сезгә җавап** [һәм савап] **бирим. Һичшиксез, Миңа коллык итүдән тәкәбберләнгән кешеләр җәһәннәмгә китәчәкләр».**

«Гафир / Гафу итүче», 40:60

Башка бер хәдисендә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Дога – ул гыйбадәтнең җелеге», – дип әйткән[2]. Ягъни дога – ул гыйбадәтнең җелеге, аның асылы, нигезе, мөһим өлеше дигән сүз. Чөнки дога кылучы аңа Аллаһыдан башка беркем дә ярдәм итә, коткара һәм сораганын бирә алмасын белеп, ихлас дога кыла.

1 Хәдисне имам Әхмәд, әл-Бохари һ. б. китерә.

2 Имам әт-Тирмизи.

Кеше – ул көчсез зат. Аңа гел нидер кирәк, нидер җитми. Ул һәрвакыт Аллаһының рәхмәтенә, ярлыкавына мохтаҗ. Дөрес юнәлешне, дөрес фикерне, хәерлелекнең кайда икәнен белми ул. Шуңа күрә кеше ихлас дога кылып Раббысына ялвара һәм ялварырга тиешле. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Раббысыннан берни дә сорамаган кешегә Аллаһы Тәгалә ачулы булыр», – дигән[1]. Ә Аллаһыдан сорыйсы нәрсәләр бик күп бездә. Раббыбыз Үзе безгә Коръәндә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисләрендә бик күп дога сүзләрен, дога үрнәкләрен өйрәткән. Ятла да, кыл шул догаларны. Булмаса, бөтен догаларны үз эченә алган, Аллаһы Тәгалә «Әл-Бәкара» сүрәсенең 201 нче аятендә өйрәткән доганы кыл:

رَبَّنَا آتِنَا فِي الدُّنْيَا حَسَنَةً وَفِي الْآخِرَةِ حَسَنَةً وَقِنَا عَذَابَ النَّارِ

Мәгънәсе: **«Ий Раббыбыз! Безгә дөньяда да** [нигъмәт, җитәрлек һәм хәләл ризык, изге тормыш иптәше, сәламәтлек, дошманнарны җиңү, Коръәнне аңлау, игелекле бәндәләр белән бергә булу, гыйлем һәм гыйбадәт кебек] **яхшы нәрсәләр бир, ахирәттә дә** [кабердән сөенеч белән калку, начар хисаптан котылу, мәхшәрнең дәһшәтеннән иминлек, җәннәткә газапсыз керү һәм Аллаһы Тәгаләнең җәмалын күрү ләззәте кебек] **яхшы нәрсәләр бир һәм безне** [гафу итеп] **Утның газабыннан** [һәм ул газапка илтә торган гөнаһлардан] **сакла!»**

Тик дога кылудан туктама гына. Шулвакыт Аллаһы безгә сораганыбызны бирер. Яки, сораганыбызны бирмичә, башкасын, яхшырагын насыйп итәр, яки берәр бәладән саклар, яки доганың җавабын ахирәткә калдырыр. Әмма Аллаһы безнең колларыбызны буш кайтармас.

Без догаларыбызны гадәттә Аллаһы белән бергә-бер калып, яшерен рәвештә кылабыз. Әмма шулай ук без догаларыбызны күмәкләшеп, җәмәгать белән дә кыла алабыз. Берәү кычкырып дога кыла, ә калганнар кулларын

[1] Имам Әхмәд.

күтәреп «әәмиин» дип шушы догага кушылалар. Шуның белән алар да шушы доганы кылучылардан булып санала. Без доганы җәмәгать белән намазлардан соң яки башка берәр мәҗлесләрдә кылабыз. Әмма кайбер кардәшләр, ашларда, җыен-мәҗлесләрдә җәмәгать белән дога кылырга ярамый дип, бу эштән тыелалар. Ифтар яки корбан ашларында барлык халык дога кылганда, алар башларын иеп, догага кушылмыйлар һәм шуның белән үзләрен җәмәгатьтән аералар. Барлык халык Аллаһыдан хәерлелек сорый, әмма алар моңа кушылмыйлар. Үзем бу хәлне күрмәсәм, моны язмас идем. Читтән караганда бик күңелсез күренеш, әйтерсең лә алар – башка дин әһелләре, Аллаһы сакласын. Аллаһы Тәгалә Коръәндә безгә Муса белән Һарунның галәйһимәссәлам җәмәгать белән дога кылганнарын китерә:

وَقَالَ مُوسَىٰ رَبَّنَا إِنَّكَ آتَيْتَ فِرْعَوْنَ وَمَلَأَهُ زِينَةً وَأَمْوَالًا فِي الْحَيَاةِ الدُّنْيَا رَبَّنَا لِيُضِلُّوا عَن سَبِيلِكَ ۖ رَبَّنَا اطْمِسْ عَلَىٰ أَمْوَالِهِمْ وَاشْدُدْ عَلَىٰ قُلُوبِهِمْ فَلَا يُؤْمِنُوا حَتَّىٰ يَرَوُا الْعَذَابَ الْأَلِيمَ ﴿٨٨﴾ قَالَ قَدْ أُجِيبَت دَّعْوَتُكُمَا فَاسْتَقِيمَا وَلَا تَتَّبِعَانِّ سَبِيلَ الَّذِينَ لَا يَعْلَمُونَ ﴿٨٩﴾

«**Муса** [галәйһиссәлам], моның кадәр могҗизалар күрсәтеп тә, өммәтенең көферлектә калырга теләвен күргәч, аларны ләгънәт кылу һәм моның хаклы сәбәбен Аллаһы Тәгаләгә аңлату өчен]**: «Ий Раббыбыз! Фиргавенгә һәм аның олуг кешеләренә дөнья тормышында** [бер сынау буларак] **зиннәтләр һәм маллар бирдең. Ий Раббыбыз! Нәтиҗәдә, алар** [фәкыйрь кешеләрне] **Синең юлыңнан яздырдылар. Ий Раббыбыз! Аларның малларын һәлак ит! Тилмерткеч бер газапны күргәнчегә кадәр иман китермәсеннәр өчен, Син аларның йөрәкләрен** [нык бер мөһер салып] **бәйләп куй».** [Аллаһы Тәгалә Муса һәм Һарунның [галәйһимәссәлам] бу догаларына:] **«Икегезнең дә догасы кабул ителде. Сез** [әмерләребезне үтәүне дәвам итеп] **туры**

**юлны тотыгыз һәм** [Аллаһы Тәгаләнең хөкемнәрендәге хикмәтләрне] **белмәгән** [җаһил] **кешеләр юлына төшмәгез», – диде»**.

«Юныс», 10:88–89

Муса галәйһиссәлам Фиргавенне һәм аның янындагы түрәләрне күп еллар Исламга чакырган. Әмма бу чакырулар, Мусаның тырышлыгы һичбер файда бирмәгән, аларның әшәкелекләре тагы да арткан. Шунда Муса пәйгамбәр инде өметен өзеп, аларга каршы шушы доганы кылган. Аять башында Муса галәйһиссәламнең дога кылуы әйтелә, ә икенче аятьтә: **«Икегезнең дә догасы кабул ителде»**, – диелә. Имам әт-Табари, Ибне Кәсир һәм башка мәшһүр тәфсир галимнәре аңлатуынча, Муса пәйгамбәр дога кылган, ә янында Һарун пәйгамбәр «әәмиин» дип әйтеп, шушы догага кушылган. Һәм нәтиҗәдә алар бу доганы икесе дә кылган булып саналалар. «Әәмиин» (آمين) дигән сүз «Раббым, кабул, шулай ит» дип тәрҗемә ителә. Әйткәндә беренче иҗек тә, икенче иҗек тә сузыла.

Хәзрәти Әнәс бине Мәлик радыяллаһу ганһе сөйләгәнчә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә минем өммәтемә аларга кадәр яшәгән халыкларга бирелмәгән өч нәрсәне бирде: 1) «әс-сәламү галәйкүм» дип сәлам бирү – бу җәннәт әһелләренең сәламе дә булыр; 2) намазда фәрештәләрнеке кебек сафларны тигез кылу; 3) дога кылганда «әәмиин» дип әйтү – моны бары тик Муса һәм Һарун пәйгамбәрләр генә әйттеләр»[1].

Җәмәгать белән намаз укыганда да, имам «Фатиха» сүрәсен укыгач, аңа ияреп намаз кылучылар Сөннәт буенча эчтән «әәмиин» дип әйтеп куялар. Бу да үзенә күрә җәмәгать белән дога кылу булып санала. «Фатиха» сүрәсенең беренче яртысы Аллаһыны мактау булса, икенче яртысы дога булып тора. Ягъни имам намазда: «[Ий Раббыбыз!] **Сиңа гына гыйбадәт кылабыз һәм Синнән генә ярдәм сорыйбыз! Безне туры юлга күндер.** [Синең тарафтан]

1 Имам әт-Тирмизи, әл-Хәким.

**Нигъмәтләндерелгәннәрнең юлына. Ачуың төшкән һәм** [туры юлдан] **адашканнарның [юлына] түгел!»** – дигәч, арттагылар «әәмиин» дип әйтеп, шушы догага кушылалар.

Доганың әдәпләреннән, Сөннәт буенча, дога кылганда учлар өскә каратып куллар күтәрелә, ә дога беткәч, шушы учлар белән бит сыпырыла. Кайбер кардәшләр бу эшкә дә каршы килеп, догадан соң битне сыпыру дөрес түгел диләр. Моңарчы – яраган һәм хупланган, ә хәзер бу эшнең, янәсе, дөрес түгеллеге ачыкланган.

Пәйгамбәребезнең сәхабәсе Гомәр радыяллаһу ганһе сөйләгәнчә: «Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм догада кулларын күтәрсә, алар белән битләрен сыпырмыйча кулларын төшерми иде»[1].

Яки икенче бер хәдистә тапшырылганча, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Ибне Габбәс радыяллаһу ганһегә болай дип әйтә: «Догадан бушагач, кулларың белән битеңне сыпыр»[2]. Шулай ук имам әл-Бохари үзенең «Әдәбүл-Муфрад» китабында сәхабәләрнең (хәзрәти Ибне Гомәрнең һәм Ибне Зөбәернең) дога кылганда битләрен сыпырганнары хакындагы хәдисне китерә. Шушы мәгънә белән башка күп кенә хәдисләр китерелә.

Шуңа күрә интернеттагы теләсә кемнең, шикле кешеләрнең сүзләренә иярмик. Аллаһы Тәгалә Муса һәм Һарун пәйгамбәрләргә әйтте бит: **«Сез туры юлны тотыгыз һәм** [Аллаһы Тәгаләнең хөкемнәрендәге хикмәтләрне] белмәгән [җаһил] **кешеләр юлына төшмәгез»**.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, хәзер бик тә фазыйләтле шәгъбан ае бара, тиздән изге Рамазан аена да керербез, иншәАллаһ. Доганың әһәмиятен онытмый, шушы изге айга исән-сау ирешеп, бар фарызларны тиешенчә үтәргә насыйп булсын дип күп-күп догалар кылыйк. Барчабызга да Аллаһы Тәгаләнең ризалыгына, ике дөнья бәхетенә ирешергә насыйп булсын!

---

[1] Имам әт-Тирмизи, әл-Хәким.

[2] Әбү Давыд, Ибне Мәҗә.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Марат хәзрәт Сәйфетдинов,*

*Балтачның Үзәк мәчетенең имамы*

*21 нче февраль вәгазе,*

*шәгъбан аеның 22 нче көне, һиҗри исәп буенча 1446 ел*

# Ватанны ярату

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Галәмнәрне юктан бар кылып, тәрбияләп торучы Раббыбызга, дөнья вә ахирәтебез, һәр мизгелебез Аның кулында булган Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә барча мактауларыбыз булса иде. Һәм дә галәмнәргә рәхмәт өчен җибәрелгән, барыбыз өчен дә сөекле булган, безләр өчен «өммәтем» дип догалар кылган һәм без аның шәфәгатенә ашкынган пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелләребез түреннән чыккан салават-шәрифләребез булса иде.

Ике гаеттән өстен булган җомга намазына килгән кардәшләрем, Аллаһы Раббыбыз кылган гөнаһларыбызны кичереп, изге гамәлләребезне арттырып кабул кылса иде!

Кечкенәдән таныш булган сүз, Ватан дигән төшенчә бүгенге көндә сирәк кулланылса да, һәр кешенең тормышында зур гына урын тота. Туган-үскән җире һәм гомумән тормышының төрле мизгелләре узган урын кайсыбызның йөрәгендә ярату хисе белән бәйләнмәгән микән? Хәтта галәмнәргә үрнәк буларак җибәрелгән сөекле Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә Мәккәне ничек матур итеп тасвирлап, туып-үскән шәһәре турында үзенең күркәм сүзләрен әйтә:

«Син нинди күркәм шәһәрсең! Һәм син миңа сөеклесең. Әгәр халкым мине синнән куып чыгармаса, синнән башкасында яшәмәс идем»[1].

Бу сүзләрне ул кешегә түгел, ә шәһәргә мөрәҗәгать итеп әйтә, аңа үзенең мәхәббәтен белдерә. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам Мәдинә шәһәренә килеп урнашыр алдыннан кылган догасын да искә төшерик: «Аллаһым, безгә Мәккәне сөекле кылган кебек, Мәдинәне дә сөекле кыл, бәлки аннан да күбрәк», – дигән ул. Димәк, Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Ватанын яраткан, моны яшермәгән. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Мәккә турындагы әйтелгән сүзләренә игътибар итик әле. Кайсы вакытта әйтте ул аны? Шәһәреннән куылган вакытта.

«Ярату» сүзен кулланган вакытта, гел бер сорауны бирәсе килә: «Ничек итеп берәр нәрсәне «ярат» дигән сүз белән генә яраттырып булсын?» Ярату яки яратмау кешедә ничек барлыкка килә? Әлбәттә, бу хакта гыйлем булганда гына. Ватаныбыз, бигрәк тә Татарстан җирлеге безгә ничек таныш? Ул – туган җиребез дисәк, бу бер төрле ярату. Ләкин Татарстаныбыз тирән, дини, гыйльми тарихка бай. Монда без исемнәрен дә белмәгән меңләгән татар галимнәре яшәгән. Ат арбаларына төяп, яндырылган, суга агызылган, җиргә күмелгән, кызганыч, күбесе сакланмаган меңләгән китаплар язылып, авыл саен мәдрәсәләр булып, ул мәдрәсәләрдә шул авылда ук туып-үскән галимнәрнең китаплары буенча дәресләр бирелгән. Шул гади авыл егетләре, үз мәдрәсәләрендә тирән гыйлем алып, чит илләргә, хәтта Мәдинә, Мәккә җирлекләренә кадәр ирешеп, гыйлем биргән. Менә шундый бай мираслы безнең Ватаныбыз. Бүген дә әле кайвакыт Татарстаныбыздан гарәп җирләренә сорау белән чыккан вакытта, шул гарәпләрнең безгә: «Сезнең бит үзегезнең зур галимнәрегез бар, нигә бездән сорыйсыз?» – дип җавап бирүләре – үзе бер горурлык.

Доктор Ибраһим бине әш-шәех Рәшид әл-Мүрәйхи татар галимнәренең тарихын өйрәнер өчен, Бәхрәйн дәүләтеннән безнең Татарстаныбызга

[1] Имам әт-Тирмизи.

килә. Татар галимнәренең яшәгән, гыйлем биргән урыннарында булып, кайберләренең каберләрен зиярәт кыла. Доктор Ибраһим өч томнан торган «Татарстан дин галимнәренең кайбер чылбырларын торгызу» дип аталган китап яза. Бу китап Болгар ислам академиясе тарафыннан 2022 елда бастырыла. Китап гарәп телендә язылган. 3 том, барлыгы 1888 биттән тора. Бу хезмәтендә автор Галимҗан Баруди, Мөхәммәд Морат бине Габдулла әл-Казани, Шиһабетдин Мәрҗани, Габденнасыйр әл-Курсави, Габделхалик әл-Курсави, Габдрәшит Ибраһимов һәм башка галимнәребез, мәгърифәтчеләребез турында яза. Бу бит әле ахыргы йөз-ике йөз еллыктагы галимнәрнең бер өлеше генә. Әгәр Казан ханлыгы чорларына һәм аннан да тирәнрәк вакытларга, Алтын Урда вакытларына игътибар итеп карасак, мәсәлән, 1357–1358 елларда Мәхмүд әл-Болгари тарафыннан язылган «Нәһҗел Фәрадис» китабын бүген дә кулыбызга алып укый алабыз. Кыскасы, Ватаныбыз алтыннан кыйммәтлерәк булган тирән гыйлем мирасына бай. Бу Ватанны, бу мирасны, бу гыйлемне саклау безнең өстә түгелме? Дин тыелган вакытларда, татар галимнәре, имамнары куылган, үтерелгән чорларда, татарның асыл ир-егетләре ни эшләде? Алар авылларга таралып, мәдрәсәләр ачып гыйлем бирделәр.

Бүген, дин иреге булган чорда, безнең яңа, яшь Барудилар, Курсавилар, яңа татар галимнәребез үсеп чыгарга тиеш. Ватаныбызны яклау, саклау һәм дин гыйлеме ягыннан үстерү, динебез төшенчәләре белән тулган телебезне саклау – без, ир-атларның җаваплылыгы түгелме? «Ватан» дигәндә күз алдына әйләнә-тирәдә яшәүче кайбер гөнаһлы, сәрхуш кешеләрне күз алдына китерсәк, әлбәттә, саклыйсы килмәс. Ләкин бит ул кешеләрне дә, алар шул ялгышларыннан арынсыннар өчен, колларыннан тотып калу, кеше булып яшәргә өйрәтү дә нәкъ без, мөселманнарның, вазифасы булып тора.

Ә «Ватан нәрсәдән башлана», – дисәк? Ул гаиләбездән башлана. Гаиләбез инде Ватаныбызның бер өлеше булып тора.

Сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Һәрберегез – көтүче, вә һәрберегез үз көтүе өчен җаваплы булачак. Имам

(ягъни җитәкче) – көтүче, ул үзенең халкы өчен җавап бирер. Ир-ат – үз гаиләсе өчен көтүче, шул хакта җавап бирер. Хатын – иренең өендә көтүче, шул хакта җавап бирер. Хезмәткә алынган кеше – хуҗа малын көтүче, шул хакта җавап бирер. Һәрберегез – көтүче, вә һәрберегез үз көтүе хакында җавап бирәчәк»[1].

Раббыбыз ир кешене хатын-кыздан күп яктан аермалы итеп яраткан. Хатын-кыз ире артына сыенып, аңа буйсынуы белән бәхетле булса, ир кеше, киресенчә, идарә итә алуы, яклый алуы, гадел була алуы белән бәхет таба.

Мөэминнәрнең анасы Гайшә радыяллаһу ганһә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мондый хәдисен тапшырган: «Дөреслектә, хатын-кызлар – ирләрнең кучерелмәседер»[2]. Ягъни алар холыклары белән ирләрен кабатлыйлар, ирләреннән өзелеп төшкән бер өлеш кебекләр. Димәк, хатыннарыбызның тәрбияле булуы да безнең үзебездән тора икән. Яраткан ата-аналарыбызга, сөекле хәләл җефетләребезгә, йөрәк җимешләребез булган сабый балаларыбызга, ягъни үзебезнең кечкенә дәүләтебезгә, Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үрнәгендә мөрәҗәгать итеп, аларның эчке вә тышкы дөньяларын яклый, саклый алсак, дәүләтебез нык булыр, иншәАллаһ.

Ә менә бүгенге көндә егетләребез, яраткан кешеләрен калдырып, махсус хәрби операциягә юнәлде. Аларны догаларыбыздан калдырмыйк!

Йә Раббым! Үзләрен корбан итеп, шул СВО җирлегенә киткән егетләребезгә иман байлыгы, тән сәламәтлеге, җан тынычлыгы бир. Сау-сәламәт килеш туган якларына кайта алуларын насыйп ит! Көннәрен вә төннәрен аларны уйларыннан чыгармаган, күз яшьләре белән дога кылган ата-аналарының, хәләл җефетләренең, балаларының сагыш күз яшьләрен шатлык яшьләренә алмаштыр! Дөньяларга, һаваларга тынычлык бир! Шулай ук Фәләстыйн җирлегендә һәм башка урыннарда авыр хәлдә калган дин кардәшләребезгә шул сынауларыннан котыла алуларын насыйп ит! Әмин.

---

[1] Имам әл-Бохари, имам Мөслим.

[2] Имам Әбү Давыд.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Илназ хәзрәт Яхин,*

*Тукай районы Әҗмәкәй авылы мәчете имамы*

*28 нче февраль вәгазе,*

*шәгъбан аеның 29 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1446 ел*

# Изге Рамазан ае башлана

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Бөтен галәмнәрне юктан бар кылып, тәрбияләп торучы, чиксез нигъмәтләр белән нигъмәтләндереп торучы, безләргә йөрергә аяклар, күрергә күзләр бирүче Раббыбыз Аллаһыга барча мактауларыбыз, шөкерләребез булсын! Аллаһы Тәгалә бар, Аллаһы Тәгалә бер, без бары тик Аллаһы Тәгаләгә генә гыйбадәт кылабыз, Аллаһыдан башка гыйбадәт кылырга лаеклы зат юк.

Барча галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрелгән, дөньяда яшәгән һәм яшәячәк иң яхшы кеше – пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә – күңел түрләребездән чыккан салават-шәрифләребез, сәламнәребез, изге догаларыбыз булсын.

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا كُتِبَ عَلَيْكُمُ الصِّيَامُ كَمَا كُتِبَ عَلَى الَّذِينَ مِن قَبْلِكُمْ لَعَلَّكُمْ تَتَّقُونَ ﴿١٨٣﴾

**«Ий иман китерүчеләр! Сездән алда килеп киткәннәргә** [фарыз булып] **язылган кебек, сезгә дә** [Рамазан аендагы] **ураза** [фарыз булараk] **язылды. Бәлки,** [ачлык ярдәме белән гөнаһлардан сакланып] **тәкъвалык ияләреннән булырсыз!»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:183

Мөхтәрәм газиз дин кардәшләрем! Изге Рамазан ае башланырга күп калмады! Бүгенге көнебез мөбарәк җомга көннәре булса, иртәгә, иншәАллаһ, ел буе сагынып көткән кунагыбыз килеп җитә! Бүген кич без беренче тәравих намазларын укып, иртәгә иртә белән сәхәрләр ашап, уразабызның беренче көнен тотарбыз.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә: «Бер кеше Рамазан аен шатланып каршы алса һәм Рамазан аеның үтеп китүенә ихластан иң яхшы ай үтте дип кайгырса, шул кешегә мәңгелек сәгадәт, рәхәт йорты булган җәннәт вәҗиб булыр», – дигән.

Рамазан ае – мөселман өчен иң изге һәм иң кадерле ай. Ул безнең өчен ураза тоту, физик һәм рухи яктан чистарыну ае һәм үз эченә Кадер кичәсен алган, Коръән аятьләре иңә башлаган изге ай булып тора.

Бер хәдистә болай диелгән: «Әгәр кешеләр Рамазан аеның бар хасиятләрен, савапларын белсәләр, бөтен ел дәвамында Рамазан ае гына булуын теләрләр иде».

Димәк, дин кардәшләрем, безгә бик кадерле кунак килә, һәм ул үзе белән бик күп бүләкләр, күчтәнәчләр алып килә. Без дә үз чиратыбызда аны каршы алырга әзерләнергә тиешбез. Безнең бит һәркайсыбыз, томышында нинди дә булса зур вакыйга көтелсә, аңа бөтен күңеле белән әзерләнә, алдан ук хәстәрләнә, план төзи, зур кунак килсә, тәм-том, ризыклар алып, пешереп куя һ. б.

Елга бер тапкыр гына килә торган изге Рамазан аена да алдан әзерләнә башларга кирәк. Һәм әлеге әзерлек һәм рухи яктан, һәм матди яки физик яктан да булырга тиеш.

Беренчедән, белеп һәм белмичә кылган гөнаһларыбыз өчен Аллаһыдан гафу үтенергә, ихлас тәүбә итәргә, рухи яктан чистарынырга тырышырга кирәк. Бүген әле безнең вакыт бар. Кемнедер авыр сүз белән рәнҗеткәнсең икән, гафу үтен. Яки син үзең кемгәдер үпкә саклап йөрисең икән, аны гафу ит. Туганнарың, якыннарың белән яхшы мөгамәлә корырга тырыш.

Икенчедән, физик якны карасак, без дөньяви эшләрнең авырларын, күп көч таләп итә торганнарын алдан ук кайгыртырга, эшләп куярга мөмкинбез, яки аларны уразадан соңга планлаштырырга кирәк. Күпләр сизәдер, уразаның беренче көннәре гадәттә җиңелрәк бара, аннан соң организм берникадәр арганлык хис итәргә мөмкин. Шуңа күрә эше авыр булган кешеләргә, мәсәлән, төзелеш эшендә эшләгән, авыр йөкләр ташыйсы булган кешегә бәлки ялын Рамазан ае уртасына туры китереп алу хәерле булыр.

Әлбәттә, ай буена план төзеп, ниятләп куярга була, хәтта язып куйсаң яхшы. Мисал өчен, Рамазан дәвамында көнгә күпме Коръән укырга яисә ятларга, тәравих намазларында катнашырга, авыз ачтырырга, зәкят түләргә, фитрны кайда, кайчан тапшырырга, һәм башка төрле изге эшләрне планлаштырып куярга була.

Ә иң мөһиме, дин кардәшләрем, әлбәттә, калебләребезне әзерләү кирәк. Сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Бездә ике калеб юк. Ә бер калебтә яхшылык белән яманлык бергә туры килә алмый», – дигән. Ягъни изге айга без калебләребезне, уй-ниятләребезне чистартып керергә тиешбез.

Озак күрмәгән якын кешеңә сөенгән кебек, изге Рамазан ае җитә дип шатлану кирәк, чөнки Рамазан ае – Аллаһының зур рәхмәте, Рамазан ае – начар гадәтләребез, гөнаһларыбызны калдыру өчен бер форсат, Рамазан ае – Раббыбызга якынаерга бер мөмкинлек, Рамазан ае – ул җәннәткә ирешүнең бер юлы. Шуларны тиешенчә аңласак иде, газиз дин кардәшләрем.

Без, көчсез, зәгыйфь адәм балалары, Аллаһының рәхмәтеннән өметебезне өзмәскә тиешбез! Төшенкелеккә бирелеп, сынаулардан, гыйбадәттән куркып калырга тиеш түгел. Аллаһы Раббыбыз – Гафу итүче, Ярлыкаучы. Ул безнең бар кимчелекләребезне, ихлас теләкләребезне белеп торучы. Безнең соңгы сулышыбызга кадәр Ул безнең өчен Үз рәхмәт ишекләрен япмый, тәүбә итүебезне, иманга килүебезне көтә! Газиз дин кардәшләрем, арабызда кемдер әлегә биш вакыт намаз укымаска мөмкин, кемдер Рамазан

җитә, мин ураза тота алмаячакмын дип куркып тора, кемдер тагын ниндидер хаталар, гөнаһлар кыладыр… Шуңа, кемдер бәлки Аллаһы Тәгалә мине инде гафу итмәс, мин бары җәһәннәмгә эләгәчәкмен дип, төшенкелеккә бирелә, өметен өзә. Әмма бу – зур ялгышу, бу – шайтанга бирешү. Чөнки шайтан төшенкелеккә бирелүне бик ярата, мондый кешене, өметсез кешене, адаштыру, диннән яздыру бик җиңел аңа. Әмма шушы изге Рамазан ае безгә үзгәрер, төзәлер өчен иң яхшы мөмкинлек булып тора. Аллаһы Тәгаләдән зур ярдәм сорап, үзебез булдыра алганча һәрберебездә булган кимчелекләрне төзәтик. Туганнарыбызга, якыннарыбызга да Аллаһы Раббыбызның киң рәхмәте турында сөйлик, аларны куркытып түгел, ә матур итеп чакырып, динебезгә өндик. Рамазан айларында якыннарыгызны мәчетләребезгә, ифтар мәҗлесләренә чакырыгыз. Ул ураза тотмый дип, кемнедер читтә калдырмагыз, аңа да матур нәсыйхәт ясарга тырышыгыз.

Рамазан ае менә-менә башланыр, без ураза турындагы белемнәребезне яңартыйк. Үзебезне борчыган сорауларга алдан җаваплар табып керик. Әйтик, уразаны нәрсәләр бозганын, нәрсә бозмаганын ел саен искә төшерергә кирәк.

Газиз дин кардәшләрем, Рамазан җитү белән шайтаннар богаулана. Безгә гыйбадәтләр җиңелрәк бирелә. Без күбрәк Коръәни Кәримне укыйбыз. Ә кемдер әлегә гарәпчә укый белми икән, бу изге айны әрәм итмәсен, тизрәк гарәп хәрефләрен, тәҗвид кагыйдәләрен өйрәнә башласын, Коръән укырга өйрәнергә тырышсын. Курыкмагыз, Аллаһы Тәгалә бар гыйбадәтләрне җиңеләйтә, тырышлыгыбызны күреп, хәтта шуның өчен генә дә савапларын бирә. Изге Коръәнне Рамазан аенда укып чыгарга тырышыйк. Чөнки, билгеле булганча, бер савап Рамазан аенда ким дигәндә 700 савапка хисапланыр, ди. Мәсәлән, «Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим» дигәндә, гарәпчә 19 хәреф килеп чыга. Коръән укыган өчен гади айда бер хәрефкә 10 савап вәгъдә ителә, димәк, шулай без 190 савап алабыз икән. Бу гади айда. Ә Рамазанда шуны тагы 700 яки аннан да күбрәккә тапкырлый алабыз. Әлхәмдүлилләһ,

динебез – җиңел дин, әҗер-савапларга ирешү мөмкинлекләребез дә бихисап. Өйрәник, тырышыйк, дин кардәшләрем.

Кайбер кешеләр без моны үти алмыйбыз, Рамазан аенда ураза тота алмыйбыз, безнең моңа көчебез җитми, гарәп хәрефләрен өйрәнә алмыйбыз, дип төрле акланулар табалар, аларның күңелләрендә борчу, курку була. Әмма без аларга шушы әйберләрне сөйләп, аңлатып күрсәтсәк, иншәАллаһ, күңелләре ачылыр, ышанычлары артыр иде. Аллаһы Тәгалә кешегә көче җитмәгәнне йөкләми, көче җиткәнне генә йөкли, һәрберебезгә үтеп чыгардай гына сынаулар бирә.

Менә бу кечкенә генә киңәшләрне үтәсәк, ошбу изге айны шатланып, дөрес итеп каршы алырбыз, Аллаһы теләсә.

Вәгазебезнең башында китергән аятьтә Раббыбыз: **«Ий иман китерүчеләр!»** – дип мөрәҗәгать итә. Ул бар кешегә дә дәшми, «кешеләр» генә дими. «Ләә иләәһә илләллааһ Мүхәммәд расүүлүллааһ» дип иман китереп, Аллаһыны танып, чын күңелдән Аңа инанган кешеләр өчен Рамазан уразасы фарыз булып тора. Әгәр кеше Аллаһыны танымаса, иман китермәсә, әлбәттә, аның моңа көче җитмәскә мөмкин. Әмма иманлы кеше өчен ураза тоту – ул бер бәхет, Аллаһының бер бүләге. Хәтта ураза тоту җиңел генә бармаса да, ул Рамазанны сөенеп каршы ала, аның беткәненә кайгырып тора. Аңа ураза тоту да, кич белән мәчеткә килеп, егерме рәкәгать тәравих намазы укуы да бер бәйрәм кебек.

Ураза – иң җиңел гыйбадәтләрнең берсе. Намаз уку өчен әле кеше тәһарәт ала белергә, күпмедер сүрәләр өйрәнергә, намазның хәрәкәтләрен истә тотарга тиеш. Ураза тотар өчен исә кеше билгеле арада ризыктан, яман сүзләрдән, якынлык кылудан тыелып кына торырга тиеш. Монда сүрәләр, аятьләр ятлыйсы да, хәрәкәтләр, тәртипләр өйрәнәсе дә юк. Ләкин, әйткәнемчә, уразаны нәрсәләр бозганын, киңәш ителмәгән гамәлләр турында без белергә тиеш, алдан боларны өйрәнеп куярга кирәк.

Кайчак шундый сораулар бирәләр: «Намаз укый белмәгән, намаз укымаган кешегә ураза тоту ярыймы?» Дин кардәшләрем, намаз – ул үзенә күрә бер фарыз, ураза – үзенә күрә бер фарыз. Намаз укый белмәсәң дә, Рамазан аен сау-сәламәт килеш каршылагансың икән, тәннең зәкятен чыгарырга тиешсең. Димәк, намаз укымаган яисә яулык бәйләмәгән кешеләргә дә ураза тотарга ярый, тиеш. Ураза – ул тәнебезнең зәкяте, сәламәтлегебезнең зәкяте. Авыру кешегә генә ураза тоту мәҗбүри түгел.

Шуны истә тотыйк: һәртөрле фарызлар – кешене Аллаһыга якынайта торган кораллар. Аллаһы Тәгалә шушы изге айны сау-сәламәт килеш каршыларга насыйп итсә иде, аны гафиллек белән үткәрә күрмик! Киләсе Рамазанга кадәр гомеребез бармы, белмибез. Бу Рамазаныбызны Аллаһы риза булырлык итеп үткәрик.

Аллаһы Раббыбыз һәркайсыбызга тәүфыйк-һидаять, хәерле сәламәтлекләр биреп, Рамазан айларыбызны да Үзенә муафыйк булганча, изгелектә үткәрүләребезне насыйп итсә иде! Әмин.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Әхмәд хәзрәт Сафин,*

*Саба районы Лесхоз бистәсенең «Нургали» мәчете имам-хатыйбы*

*7 нче март вәгазе,*

*Рамазан аеның 7 нче көне, һиҗри исәп буенча 1446 ел*

# Рамазан – Коръән ае

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Аллаһы Тәгалә юктан бар иткән мәхлуклар арасында кеше иң югары дәрәҗәдә тора, чөнки кешегә акыл нигъмәте бирелгән. Шушы акыл ярдәмендә кеше Аллаһыны танырга, белем алырга һәм гыйбадәт кылу әһәмиятен аңларга тиеш. Бу – акылның төп асыл-максаты.

Аллаһы Тәгалә әйтә:

شَهْرُ رَمَضَانَ الَّذِي أُنْزِلَ فِيهِ الْقُرْآنُ هُدًى لِلنَّاسِ وَبَيِّنَاتٍ مِنَ الْهُدَىٰ وَالْفُرْقَانِ

**«Рамазан ае – аңарда кешеләр өчен һидаять, туры юлны күрсәткән ачык дәлилләр, хакны ялганнан аерган Коръән иңдерелгән** [ай]**».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:185

Коръән – ул Аллаһының олуг изге Сүзе. Һәм аны иңдерүнең максаты – кешеләргә Аллаһының барлыгы-берлеге, Аның бөеклеге һәм гүзәл исем-сыйфатлары турында мәгълүмат җиткерү. Коръән кешеләрне Аллаһы кушканча яшәргә өйрәтә, Аның әмер-тыюлары белән таныштыра, әҗер-җәза булуы турында хәбәр бирә.

Коръән – Аллаһы Тәгаләнең нык җебе, ачык нур һәм файдалы шифадыр.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Коръәнне укучы бер хәреф өчен ун әҗер-савап ала. Мин «Әлиф. Ләм. Мим» бер хәреф дип әйтмим. Әлиф – бер хәреф, ләм – бер хәреф, мим – бер хәреф»[1]. Шушы 3 хәрефкә генә дә 30 әҗер-савап язылa. Ә Рамазан аенда Коръәнне тулысынча укып чыгу күпме әҗер-савап бирәчәк!

Коръән уку ахирәттә шәфәгать кыла, югары дәрәҗәләргә күтәрә, яхшы гамәлләр кылырга этәрә, ышануны ныгыта, авыруларны дәвалый, күңел тынычлыгын табарга ярдәм итә, борчулардан арындыра.

Хәзрәти Әбү Муса әл-Әшгари радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мондый сүзләрен тапшырган: «Коръәнне укый торган мөэмин хуш исле һәм тәмгә татлы булган цитронга тиң, ә Коръәнне укымый торган мөэмин исе булмаган тәме татлы хөрмәгә тиң. Коръән укый торган монафикъ (икейөзле кеше) хуш искә ия булган, ләкин тәмгә ачы булган рәйханга тиң, ә Коръән укымый торган монафикъ хуш исе булмаган һәм тәмгә дә ачы хәнза җимешенә тиң»[2].

Хатем – ул Коръәнне тулысынча укып чыгу, иң олы гыйбадәтләрнең берсе. Хатем чыгу авыр булса да, аның әҗере зур. Әгәр кешеләр Коръән укыган өчен үзләрен нинди бүләкләр көткәнен белсәләр, алар моңа күбрәк вакыт сарыф итәрләр иде. Гамьсезлек аркасында үзебезгә зыян салабыз, вакытыбызны исраф итәбез. Коръән сүрәләрен уку кешенең рухи дөньясына, шулай ук аның физик һәм психологик сәламәтлегенә уңай йогынты ясый.

Коръәнне хатем кылу ул шулай ук сөннәт гамәл булып тора, чөнки сөекле Пәйгамбәребез галәйһиссәлам һәр Рамазан аенда Җәбраил галәйһиссәлам белән хатем кыла, Коръәнне бергә кабатлап чыга иде.

Хатемне ничек кылырга соң? Иң әүвәл Аллаһы ризалыгы өчен укырга ниятләргә кирәк, аннары «әгузү-бисмилләһ»не әйтеп, беренче «Фатиха» сүрәсеннән башлап, ашыкмыйча гына рәттән бар сүрәләрне укып

1 Имам әт-Тирмизи.

2 Имам әл-Бохари.

барырга кирәк. Укыган вакытта тәҗвид кагыйдәләре буенча дөрес итеп, укыган аятьләр турында фикерләп, күңел аша үткәреп укырга тырышырга кирәк. Соңгы сүрәне укып бетергәч, бик күп итеп дога кылырга киңәш ителә, чөнки бу вакытта догалар кабул була, Коръән хатем чыгылган урында меңләгән фәрештәләр җыела. Рамазан аенда Коръәнне тулысынча укып чыгарга теләгән кеше һәр көнне кимендә бер җүз укыса, бер айда хатем кылыр, иншәАллаһ.

Адәм баласының дөнья тормышында беренче бурычлары иманлы яшәү һәм иман белән дөньядан үтү булса, икенчесе – гаилә корып, балалар үстереп, яхшы нәсел калдыру.

Һәм без, мөселманнар өчен хатын-кызлар һәрвакытта да югары әхлакый сыйфатлар йөртүче, гаилә учагын саклаучы, балаларга зирәклек тапшыручылар булган һәм булачак. Ислам дине һәм аның кануннары мөселман хатын-кызларының иминлеге булып тора. Динебез ир-атларга хатын-кызларны хөрмәт итәргә һәм кадерләргә куша:

وَعَاشِرُوهُنَّ بِالْمَعْرُوفِ

**«Алар белән күркәм** [мөнәсәбәтләрне саклап] **яшәгез** [аларга карата инсафлы булыгыз һәм матур сөйләшегез]**».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:19

Аллаһы Тәгалә һәркайсыбызга хәерле гомерләр биреп, никахлы җәмәгатьләребез белән тигезлектә, татулыкта, саулык-сәламәтлектә, өлфәт мәхәббәт белән, бер-беребезгә терәк-таяныч булып, кайгы-хәсрәт күрмичә гомер итәргә насыйп кылсын. Әмин!

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Габдрәшит хәзрәт Фәизов,*

*Коръән хафизлар әзерләү үзәге җитәкчесе*

*14 нче март вәгазе,*

*Рамазан аеның 14 нче көне, һиҗри исәп буенча 1446 ел*

# Рамазан – җәһәннәм утыннан котылу

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Барлык галәмнәрнең Раббысы булган, безне Үзенең төрле нигъмәтләре белән бүләкләгән Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед һәм сәналәр, барча мактауларыбыз, олуглауларыбыз булса иде. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләнең хәбибе һәм хак расүле, галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрелгән сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәзрәтләренә, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә сәламнәребез һәм салаватларыбыз ирешсен. Изге Рамазан аенда тоткан уразаларыбыз, укыган тәравих намазларыбыз, биргән садака вә зәкятләребез, үткәргән ифтарларыбыз кабул булып, Раббыбыз савапларына ирешергә насыйп кылсын!

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә безгә Коръәни Кәримдә болай ди:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا كُتِبَ عَلَيْكُمُ الصِّيَامُ كَمَا كُتِبَ عَلَى الَّذِينَ مِن قَبْلِكُمْ لَعَلَّكُمْ تَتَّقُونَ ﴿١٨٣﴾

«**Ий иман китерүчеләр! Сездән алда килеп киткәннәргә** [фарыз булып] **язылган кебек, сезгә дә** [Рамазан аендагы] **ураза** [фарыз булarak] **язылды. Бәлки,** [ачлык ярдәме белән гөнаһлардан сакланып] **тәкъвалык ияләреннән булырсыз!**»

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:183

Әйе, безгә кадәр килгән әби-бабаларыбыз да Рамазан аен куанып-шатланып, изге ай килде, саваплар эшли торган, гөнаһлардан котыла торган ай бит бу, дип каршы алып, уразаларын тоталар иде. Алар ачлык чорында да, һәр эштә кул хезмәте кулланган вакытта да, авырсынмый, зарланмый уразаларын тотып, Аллаһы Раббыбызның ризалыгына ирешергә, җәннәтле булырга ашыктылар, тырыштылар.

«Рамазан» сүзе гарәпчәдән «көйдереп яндыру» дигән мәгънәне аңлата, ягъни бу гөнаһлардан арыну, гөнаһларны яндыру, юк итү дигән сүз. Бу айда, Аллаһы насыйп кылса, мөселманның гөнаһлары кимер, «янар». Рамазан аенда җәһәннәм утыннан котылырга тырышырга Аллаһы җиңеллек бирсен.

Имам әл-Бәгави дигән бөек галим: «Дөреслектә, «Рамазан» дигән сүз «рамзаа» дигән сүздән алынган, ягъни «кыздырылган ташлар» мәгънәсендә килә, чөнки алар кызу көннәрдә ураза тотканнар», – дип әйткән. Ул замандагы гарәпләр берәр айга исем бирергә теләгәндә, беренче чиратта вакыйгаларга яки фасылларга карый торган булган. Ә Рамазан ае кызу көннәргә туры килгәч, алар ул айга «Рамазан» дип исем биргәннәр. Икенче бер галим болай дип әйткән: «Ул айда гөнаһлар яндырылганга күрә, аны «Рамазан» дип атадылар», – дигән.

Хәзрәти Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең әлеге сүзләре риваять ителә: «Рамазан ае кергәч, җәннәт ишекләре ачыла, җәһәннәм ишекләре ябыла, шайтаннар богаулана». Шушы хәдистән аңлашылганча, Рамазан аенда Аллаһының рәхмәте иңә, шайтаннар бикләнә, богаулана һәм ураза тотарга комачауламый. Күпләребезнең сизгәне бардыр: башка айлардан аермалы буларак, Рамазан аенда ураза тоту җиңелрәк һәм гөнаһлар да аз кылына, күңел изгелеккә, игелеккә ашкына.

Тагын бер хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Рамазан аеның беренче ун көне – рәхмәт, икенче ун көне –

мәгъфирәт, өченче ун көне – җәһәннәм утыннан котылу көннәре. Кем бу айда үзенең малын сарыф итсә, Аллаһы аны уттан саклар». Боларны өмет итеп тырышучы кешегә «мөхсин» диләр, ягъни ихлас кешедер. Әйе, Аллаһы Тәгаләнең ихлас колы бу айда шушы өч нигъмәтне алып калырга тырыша. Тырышмасак, аебыз бушка, әрәмгә үтеп китәр, бу нигъмәтләрдән, саваплардан мәхрүм булырбыз.

Бу айда дүрт әйберне эшләргә тырышыгыз, аларның икесеннән сез Раббыгызның ризалыгына ирешерсез, ә калган икесенә сез үзегез мохтаҗдыр. Раббыбызның ризалыгына ирештерә торган беренче ике гамәл:

– «Ләә иләәһә илләллааһ» (ягъни «Аллаһыдан башка гыйбадәткә лаек зат, илаһ юк») дип, даими шушы кәлимәне әйтү;

– истигъфар кылу, ягъни Аллаһыдан кылган хата-гөнаһларыбыз өчен гафу үтенү.

Без мохтаҗ булган ике гамәл:

– Аллаһыдан даими җәннәтне өмет итү;

– җәһәннәмнән сыену.

Бер кодси хәдистә болай диелгән: «Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә: «Адәм баласы кылган һәр гамәл үзе өчен, уразадан кала, чөнки ураза – Минеке, һәм әҗерен дә Үзем бирермен». Никадәр саваплы һәм гүзәл гыйбадәт ул ураза! Аллаһы аны «Минеке» дип безне шатландырды, чөнки ураза – риядан ерак булган бердәнбер гамәл. Ураза тотасыңмы, юкмы – Аллаһыдан кала беркем дә белә алмый, гәрчә син үзеңне уразалы дип әйтсәң дә.

«Ураза – җәннәт базары», – дип тә әйтелә. Дөнья базарын яхшы беләбез: ул сату-алу, табыш кертү. Ә җәннәт базары – иң олуг табыш, нигъмәт, дәүләт, савап. «Берәү җәннәт базарын дөнья базарына алыштырса, һәлак була», – ди галимнәр. Уразаны саклау шулдыр, хәтта сине әрләүче, сүгүче булса да, сиңа «мин уразада» дип әйтү җитә.

Бер хәдистә болай дип әйтелгән: «Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм минбәргә күтәрелгәндә өч мәртәбә «әәмиин» дигән. Сәхабәләр моның

сәбәбен сорагач, ул: «Миңа Җәбраил галәйһиссәлам өч әйберне ирештерде. Шуңа мин «әәмиин» дидем. Болар:

– берәү, Пәйгамбәр исемен ишетеп тә, аңа салават-сәлам ирештермәсә, шул кеше Кыямәт көнендә үкенечтә булыр (җәннәтнең исен дә сизмәс);

– берәү, әти-әнисенең картлыгын күреп, аларга игелек күрсәтмәсә, шул Кыямәт көнендә үкенечтә булыр;

– берәү, Рамазан ае килеп тә, Аллаһының ярлыкавын алмаса, шул җәннәттән ерак булыр», – дигән.

Димәк, уразаның олуг максаты – Аллаһы Тәгаләнең ярлыкавына өметләнеп, шуны алырга тырышу.

Мәшһүр галим, фәкыйһ Әбү Ләйс әс-Сәмәрканди хәзрәти Ибне Габбас радыяллаһу ганһедән риваять ителгән шул сүзләрне әйткән: «Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Дөреслектә, Рамазан ае кергәндә, җәннәт зиннәтләнә. Рамазан киче булса, Гареш астында җил исәр (Мәсирә җиле). Шул җилдән җәннәт агачларының яфраклары, ишек бөҗралары селкенер. Һур кызлары җәннәтнең югары баскычыннан карап: «Нинди кунак (яучы) килә?» – дип сорар. Ризван фәрештә: «Әй күркәм изге кызлар! Бу кич – Рамазан аеның беренче кичe», – дияр». Аллаһы Тәгалә җәннәтне һәм җәһәннәмне яратты, җәннәттә алтын сарайлар булдырды. Хуш бакчаларда хуш исле агачларны, татлы елгаларны бар кылды, җәннәттән: «Әй җәннәтем! Ни әйтерсең?» – дип сорады. Җәннәт: «Дөреслектә, мөэминнәр уңышка иреште, ягъни алар җәннәт әһеле булды. Мөэминнәргә шундый матур, гүзәл урын насыйп булачак», – диде. Шуңа Аллаһы Тәгалә Коръәндә: **«Иман китерүчеләр хәзердән уңышка иреште** [һәм өметләре гамәлгә ашты]**»**, – дип әйтә («Әл-Мүэминүн / Мөэминнәр», 23:1)».

Ураза тотучылар да Аллаһы Тәгалә ризалыгын, җәннәтне, җәһәннәм утыннан котылуны өмет итә. Аллаһы Тәгалә бу дөньяны яратты, җанны, нәфесне бар кылды. Раббыбыз җаннан: «Йә җан! Кем синең Раббың?» – дип

сораган. Җан: «Син – минем Раббым», – дип таныган, әмма нәфес Раббысын танымаган. Аллаһы Тәгалә нәфесне 100 ел ач тотканнан соң, кабат сораган, әмма нәфес бу юлы да танымаган. Моннан соң Аллаһы Тәгалә нәфесне тагын 100 ел ач тоткан. 200 ел ач торгач кына, нәфес: «Син – безнең Раббыбыз», – дип, Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләне таныган.

Кешене ялгыш юлга, адашуга ике нәрсә этәрә: шайтан һәм нәфес. Рамазан аенда нәфесне тыю гыйбадәт булып тора. Бу айда шайтанның зурлары богауда, ә нәфес – юк. Нәфесне кеше үзе генә җиңә ала. Кеше нәфесен җиңсә, изге гамәлләр кыла.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең бер хәдисендә болай дип әйтелгән: «Кыямәт көнендә ураза һәм Коръәни Кәрим Аллаһының коллары өчен шәфәгатьче булырлар. Ураза гамәле: «Йә Раббым, мин аңа көндез ашарга да, эчәргә дә бирмәдем. Аның өчен шәфәгатьче булырга рөхсәт ит», – дияр. Коръәни Кәрим: «Йә Раббым, мин аңа төннәрен йокларга бирмәдем. Аның өчен шәфәгатьче булырга рөхсәт ит», – дип әйтер».

Йомгаклап, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең бер гүзәл сүзен әйтәсе килә. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ураза тотучы кешенең ике шатлыгы бар: берсе – авыз ачкан вакытта, ә икенчесе – гөнаһларыбыз гафу ителгән хәлдә Кыямәт көнендә Аллаһы белән очрашканда», – дип әйткән.

Аллаһы Тәгалә күңелләребезгә иман, тәкъвалык салып, бер-беребезгә ярату, берләшүне кире кайтарып, урамда да, өйдә дә, мәчеттә дә, дөньяда да, ахыр дөньяга күчкәч тә мөселман булып калырга насыйп итсен. Аллаһы Тәгалә уразаларыбызны кабул әйләп, гөнаһларыбызны гафу итсен. Әмин!

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Әнсар хәзрәт Мифтяхов,*

*Казанның «Әл-Мәрҗани» мәчете имамы*

*21 нче март вәгазе,*

*Рамазан аеның 21 нче көне, һиҗри исәп буенча 1446 ел*

# Кадер кичәсе

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Аллаһының рәхмәте белән ишек төпләребезгә Рамазан аеның соңгы ун көне килеп басты. Ул көннәрне Рамазан аеның каймагы, Рамазан аеның таҗы дип атасаң да була. Без ул көннәрне ничек каршыларга тиеш соң? Аллаһының Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу соңгы ун көнне башка көннәрне эшләмәгән, аларга гына хас гамәлләр белән каршылаган.

Имам әл-Бохари һәм имам Мөслим Гайшә анабыз радыяллаһу ганһәдән түбәндәге хәдисне риваять кылалар: «Рамазан аеның соңгы ун көне керсә, (Пәйгамбәребез галәйһиссәлам) төнен уяу үткәрә, гаилә әһелләрен уята иде, күбрәк тырышлык куя һәм изарын ныграк бәйли иде».

Имам Мөслимнең риваятендә: «Аллаһының Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм Рамазан аенда башка айларга караганда ныграк тырыша иде, ә Рамазанның соңгы ун көнендә башка вакыттан ныграк тырыша иде», – дип килә.

Һәм шулай ук Гайшә анабыз радыяллаһу ганһә тапшырган башка бер хәдистә болай диелә: «Аллаһының Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм вафат булганчы Рамазан аеның соңгы ун көнендә игътикәф кыла иде».

Рамазан аеның соңгы ун көнендә игътикәф кылуның хөкеме – сөннәт мүәккәдә галә әл-кифәя, ягъни бөтен җәмәгатькә йөкләнгән ныклы сөннәт.

Җәмәгатьтән бер генә кеше булса да әлеге гамәлне кылса, башкаларның өстеннән җаваплылык төшә.

Сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үз мисалында Рамазанның соңгы ун көнендә мөбарәк булган кичәне эзләргә кирәк булуын күрсәтте. Ул кичә, Коръәндә килгәнчә, – мең айдан хәерлерәк булган Кадер кичәсе. Бу кичәдә Коръән иңә башлый.

Хәзрәти Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән риваять кылынган хәдистә Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтә: «Кем Кадер кичәсен Аллаһыга ышанган һәм Аның әҗеренә өметләнгән хәлдә гыйбадәттә үткәрсә, шуның электән кылынган гөнаһлары гафу ителер!»

Аятьтә әйтелгәнчә, бу бер кичә мең айдан хәерлерәк. Мең ай, кеше гомеренә салсаң, 83 елны тәшкил итәчәк. Һәм Аллаһы колы бу кичәне гыйбадәттә үткәрә алса, гомерен гыйбадәттә үткәргән кеше савабын алыр, иншәАллаһ.

Бу кичәдә Аллаһының рәхмәте, бәрәкәте белән фәрештәләр күпләп иңә. Алар Коръән укучылар янына җыелган кебек, зикер түгәрәкләрен камап алган кебек, Аллаһыны бөекләгән колларын уратып алырлар. Бу төн һәрбер начарлыктан имин булыр.

Халык арасында таралган фикер буенча, Кадер кичәсе Рамазан аеның 27 нче киченә туры килә. Быел ул 26–27 нче мартка туры килә. Ләкин гыйлем әһелләре аңлатканча, аның тәгаен билгеләнгән вакыты юк, Кадер кичәсен Рамазан аеның соңгы ун көнендә, бигрәк тә так кичәләрдә эзләргә кирәк. Аллаһы Раббыбыз Үзенең хикмәте белән колларына аның төгәл көнен, төгәл сәгатен әйтмәгән, белдермәгән. Чөнки аның вакыты билгеле булса, мөселманнар ай буе тырышмаслар иде, аларның тырышлыклары фәкать шушы төнгә генә калыр иде.

Кадер кичәсенең кайбер галәмәтләрен искә төшерсәк, алар түбәндәге: ул төн тыныч була, салкын да, эссе дә түгел, Кадер кичәсеннән соң кояш ак булып, тоныграк булып чыгар.

Сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәм аның сәхабәләре, әйтүебезчә, шушы көннәрдә, төннәрдә гыйбадәткә карата хирыслыкларын аеруча арттырганнар.

Шушы гамәлләрнең кайберләре:

1. Төннәрен уяу үткәргәннәр. Алар сәхәр вакытын Аллаһыны зикер итеп, намаз укып үткәргәннәр. Гайшә анабыз радыяллаһу ганһә әйтә торган булган: «Мин Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Рамазан аеннан башка вакытта Коръәнне бер төндә укыганын, ай буе ураза тотканын, таң атканчы намаз укыганын белмим».

2. Аллаһыга тәүбә-истигъфар белән мөрәҗәгать итү. Хәдистә хәбәр ителгәнчә, Гайшә анабыз радыяллаһу ганһә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән сораган: «Ий Расүлуллаһ, Кадер кичәсенә туры килсәм, миңа нәрсә дияргә?» Сөекле Пәйгамбәребез галәйһиссәлам аңа мондый дога өйрәткән:

اللَّهُمَّ إِنَّكَ عَفُوٌّ تُحِبُّ الْعَفْوَ فَاعْفُ عَنِّي

Ягъни: «Ий Аллаһым, Син – Гафу итүче, гафу итәргә яратасың, мине гафу итче!»

3. Вәгазебез башында китерелгән хәдистә Пәйгамбәребез галәйһиссәлам «һәм гаилә әһелләрен уята иде» диелә. Әлеге хәдистән күренгәнчә, мөселман ир-ат өчен үзенең гаилә әһелләрен гыйбадәт кылу өчен уяту бик яхшы гамәл санала. Алар да синең белән беррәттән шушы мөбарәк кичәнең фазыйләтенә ирешсеннәр, саваплы булсыннар өчен тырышлык күрсәтү тиешле. Үзең гыйбадәт кылыр өчен уянып, гаилә әһелләреңне калдыру хата булыр.

4. Шулай ук ул хәдистә «Аллаһының Илчесе изарын ныграк бәйли иде» дигән җөмлә бар. Аның мәгънәсе – сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Рамазан аеның соңгы төннәрендә, хатыннары аңа хәләл булса да, алардан тыелып торган. Шулай бу көннәрдә һәм төннәрдә бөтен игътибарын гыйбадәт кылуга юнәлдергән, шулай итеп ул җанын

шәһвәтләрдән саклаган. Чөнки чиста күңелдән чыккан догаларның кабул булу мөмкинлеге арта.

5. Шулай ук намазлар укыла торган мәчетләрдә игътикәф кылырга тырышырга кирәк. Игътикәф – ул Аллаһыга гыйбадәт кылу нияте белән мәчеттә калу. Хәдистә килгәнчә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Рамазан аеның соңгы ун көнендә игътикәф кыла торган булган, ә вафат буласы елда егерме көн дәвамында игътикәфтә булуы риваять ителә. Бу гыйбадәтне кылып, кеше Кадер кичен эзли, күбрәк дога кыла, зикер-тәсбихләр әйтә, дөнья мәшәкатьләреннән аерыла.

Бөек галим, хәдисләр белгече Ибне Шиһәбтән шундый сүзләр китерелә: «Мөселманнарның игътикәфне калдырулары гаҗәптер! Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәдинәгә кергәннән башлап, Аллаһы аны алганчыга кадәр (ягъни вафат булганчы) һәр ел саен Рамазан аеның соңгы ун көнендә игътикәф кылды, калдырмады».

Игътикәфтә булу сәбәпле, кеше үзен тәрбияләү белән мәшгуль була, йөрәген пакьли. Ә гөнаһлардан, начар сыйфатлардан азат булган сәламәт йөрәк гамәлләрнең ихлас, дөрес булуына сәбәпче була. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Кеше тәнендә бер ит кисәге бар. Ул сәламәт булса, бөтен тән сәламәт булыр, ул бозылса, бөтен тән бозылыр. Ул ит кисәге – йөрәк!» Димәк, ураза кешене саклаган кебек, игътикәф тә кешене артык йокыдан, артык сүздән саклый.

6. Белүебезчә, Рамазан ае – Коръән ае. Җәбраил фәрештә галәйһиссәлам Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән Рамазан аеның һәр көнендә Коръәнне сөйләткән, өйрәткән. Ә вафат буласы елында Мөхәммәд галәйһиссәлам Җәбраил фәрештәгә Коръәнне ике тапкыр тапшырган.

Галимнәребез Коръән укуга аеруча зур игътибар биргәннәр, бу гыйбадәттә бик нык үҗәтлек һәм тырышлык күрсәткәннәр. Ә Рамазан ае җиткәч, аларның тырышлыгы тагын да арткан. Мәсәлән, мәшһүр галим имам әш-Шәфигый гадәттә Коръәнне өч көндә хатем кылса (тулысынча укып

чыкса), Рамазан ае җиткәч, ул һәр төн саен хатем кылган. Ә имам әл-Әгъзам Әбү Хәнифә хәзрәтләре Рамазан аенда ахшамнан ястүгә кадәр арада һәр көнне хатем кылган.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, Рамазан аеның соңгы көннәрен гыйбадәттә үткәрергә, мөбарәк Кадер кичәләрендә үзебез, өммәтебез өчен күп-күп догалар кылырга, барыбызга да шушы изге айда гөнаһ-кимчелекләребездән пакьләнергә насыйп булсын!

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Мөхәммәд хәзрәт Мөхәммәтов,*
*Яр Чаллы шәһәренең «Җәмигъ» мәчете имамы*

*28 нче март вәгазе,*

*Рамазан аеның 28 нче көне, һиҗри исәп буенча 1446 ел*

# Гает – иң зур бәйрәм

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Бөтен галәмнәрнең Раббысы булган, без кешеләрне акыл нигъмәте белән нигъмәтләгән, безне хәлифә кылган, безгә һәрвакыт Үзенең төрле нигъмәтләрен биреп торган Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмде-сәналәребез, олуглауларыбыз булса иде. Барлык галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрелгән иң камил, иң нурлы, иң сөекле Пәйгамбәребезгә – Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә – аның әһле-бәйтенә, барлык сәхабәләренә вә табигыйннәргә сәламнәребез һәм салаватларыбыз булса иде.

Ике гаеттән дә олырак булган җомга көне җитте. Хөрмәтле мөселман кардәшләрем, бу – Рамазан аеның соңгы җомгасы. Ике көннән, ягъни 30 нчы март көнне, шушы мәчетләргә Ураза гаетен укырга җыелырбыз, Аллаһы бирсә. Ике көн уразабыз һәм бер тәравих намазы гына калып бара. Бер ай сизелми дә үтеп китте: күпме ураза, тәравихлар, мәчетләрдә һәм гаилә, туганнар белән җыелышып үткәргән ифтар ашлары, Республикакүләм ифтар, вәгазь кичәләре, зәкят-садакалар – болар барысы да артта калып бара. Чыннан да, Раббыбызның Сүзләре хак:

أَيَّامًا مَّعْدُودَاتٍ

**«Санаулы көннәрдә** [ураза сезгә фарыз кылынды]**».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:184

Раҗәб һәм шәгъбан айларын исегезгә төшерегез: без бит шушы көннәргә, изге Рамазанга әзерләндек. Әле генә башланган кебек иде, ә бүген инде соңгы көннәре дә җитте, һәм һәрберебез үзенә тиешле әҗер-савапларын җыйды. Шуңа күрә, бу ай әле тәмамланганчы, аның фазыйләтләре белән файдаланып калыйк: шушы көннәрдә нинди гыйбадәтләр башкарып була, шуларны тизрәк башкарырга керешик. Бу көннәр китәчәк, ә икенче Рамазан килсә дә, без аны каршы ала алачакбызмы, белмибез! Шушы ике көн безгә бик күп әҗерләр китерә ала. Ә шул көннәр үткәч, Ислам динендә ике зур бәйрәмнең беренчесе җитәчәк – Ураза гаете. Утыз көн буе Аллаһының кушканнарын үтәдек, нәфесләребезне йөгәнли алдык, бер ай буе ураза тота, тәравих укый, садакалар бирә алдык, дип шатланабыз.

Әлбәттә, гает – «корсак бәйрәме» түгел. Киресенчә, бер ай буе үзебезне тәрбияли алдык, Аллаһыга шөкер, фарызларыбызны үти алдык дип, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм кушканча бәйрәм итә алабыз, чөнки без Раббыбыз Коръәндә кушкан әмерне башкара алдык:

وَلِتُكْمِلُواْ الْعِدَّةَ وَلِتُكَبِّرُواْ اللّهَ عَلَى مَا هَدَاكُمْ وَلَعَلَّكُمْ تَشْكُرُونَ

> **«**[Ураза тотарга кирәкле көннәр] **санын тутырырсыз, һәм, сезгә туры юлны күрсәткәне өчен, Аллаһыны олыларсыз** [дип]**. Бәлки,** [Аллаһының хисапсыз нигъмәтләренә, бигрәк тә шушы рөхсәтләренә] **шөкер итүчеләрдән булырсыз!»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:185

Ике көннән инде шушы ук минбәрләрдән гает вәгазьләре сөйләнер, барыбыз бергә җыелып гает намазларын укырбыз. Гает намазы балигълыкка ирешкән мөселман ир-атлар өчен вәҗиб булып тора. Мосафирларга, мөмкинлекләре булмаса, гает намазында катнашмаска була.

Бәйрәм намазыннан соң таралышып, гаиләләребез белән вакыт үткәрербез. Бу көнне Аллаһының рәхмәте турында үзебезгә дә,

балаларыбызга да искә төшерергә кирәк. Шулай ук рухи кыйммәтләр, бер-береңә ярдәм итү турында уйланырга кирәк. Ай буе күңелләребезне пакьләдек, ифтарлар үткәреп, бер-берләребезне сыйладык. Моннан соң да бу халәт күңелләребездән китмәсә иде. Шушы көнне дусларыбызны, туганнарыбызны зиярәт кылырга, бер-берләребезгә бүләкләр бирешергә онытмасак иде. Тәмле сыйлар әзерләп, кунаклар чакыру, яки үзеңнең гаиләң белән вакыт үткәрү – бу көннең матур гадәтләреннән. Ә бу – гаилә кыйммәтләрен саклауга, илебездә, җөмһүриятебездә горефләребезне торгызуга бер адым. Шулай ук бу – берләшү. Күз алдыгызга китерегез, дөньядагы һәр мөселман берсекөнгә Ураза гаетен үткәрәчәк. Барлык мәчетләрдә бу көннең фазыйләтләре турында вәгазьләр сөйләнәчәк.

Әмма гает намаздан, мәчеткә килүдән генә башланмый. Без аңа алдан ук әзерләнә башлыйбыз. Остазыбыз Әхмәтһади Максуди «Гыйбадәте Исламия» китабында: «Гыйд әл-фитр көне (Ураза бәйрәме) – шәүвәл аеның беренче көне. Рамазан уразасы тәмамлангач бәйрәм ителә торган көн. Бу көндә гает (бәйрәм) намазын уку һәр мөселманга – вәҗиб. Бай кешеләргә гает намазына кадәр фәкыйрьләргә фитр садакасы бирү дә вәҗиб… Фитр садакасын Гыйд әл-фитр көнендә таң атканнан соң гает намазы укылганчы бирү саваплырак, чөнки бәйрәмне тояр өчен, акчасы булмаган фәкыйрьләрне бәйрәм башланганчы шатландыру хәерлерәк», – дип яза.

Әйе, Рамазан дәвамында без фитр, фидия турында сөйләшеп килдек, зәкят чыгару турында сөйләштек. Бу көн һәрбер кеше өчен дә бәйрәм булсын өчен, үзебезнең кулыбыздан килгәнне эшләргә тиешбез. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Үзенә теләгәнне (үзе яраткан әйберләрне) калганнарга да булуын теләгәнчегә кадәр, берегез дә камил иманлы булмассыз», – дип әйтеп калдыра. Барлык мәчетләрдә генә түгел, ә һәр өйдә, һәр гаиләдә бәйрәм булуын телик. Аның өчен бүген үк фитр садакаларыбыз турында, мескен-фәкыйрь кардәшләребез турында уйланыйк. Чын мөселман күршесендә мохтаҗлык хөкем сөргән вакытта өендә бәйрәм

итеп утыра алмый. Бүген әле вакыт бар: җомгадан кайтышлый ук кибетләргә кереп, бүләкләр алыйк, балаларыбыз белән бергә күршеләребез буенча йөреп чыгыйк. Алар да гает көнен өстәлләрендә тәмле ризыклар белән каршы алсыннар.

Инде шушы гамәлләрне башкаргач, Рамазанның барлык «тәмнәрен» татыгач, гаеткә әзерлек башлана. Ураза гаете көненең сөннәтләренең берсе – төнге гыйбадәтләр. Галимнәребез төннең күп өлешен намазда, догада үткәрергә тәкъдим итә. Кайберләре берәр сәгать булса да догалар кылып чыгарга кирәк диләр. Бу бәйрәмнең төнендә гыйбадәт кылу йөрәкләрне җанландыра. Исегезгә төшерәм, мөселман календаре буенча башта 1 нче шәүвәлнең киче җитәчәк, аннан соң гына иртәдән монда җыелачакбыз. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Аллаһыдан әҗер өмет итеп ике бәйрәмнең (Ураза һәм Корбан гаетләре) төнен гыйбадәттә үткәргән кешенең йөрәге башка кешеләрнең йөрәкләре һәлак булган көнне дә үлмәячәк». Монда «йөрәк үлмәячәк» дигәнне галимнәребез Аллаһы ул кешегә Ислам динендә һидаять бирәчәк, Ислам динендә килеш вафат булырга ирек бирәчәк дип аңлаталар.

Инде гает көненең үз сөннәтләре, әдәпләре бар. Гает намазына киткәнче, госел алу киңәш ителә. Шулай ук исле майлар, хушбуйлар куллану һәм иң матур, яңа киемнәрне кию күркәм була. Хатын-кызлар бу сөннәтләрне намазга бару өчен түгел, ә өйдә бәйрәм рухы, күтәренке кәеф булдыру өчен үтәргә тиеш. Мәчеткә барган очракта, мөслимәләр хушбуйлар кулланмас. Хәзрәти Гомәр радыяллаһу ганһенең базардан яңа гына алынган өр-яңа матур чапанны Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә алып килеп: «Бу киемдә Гаетне һәм делегацияләрне каршы ал», – дип бүләк итүе хәбәр ителә.

Гает намазына чыгып киткәнче берничә хөрмә җимеше (яки башка берәр татлы ризык) ашау – сөннәт. Бу рәвешле без уразаның тәмамлануын белдерәбез. Хәзрәти Әнәс радыяллаһу ганһе болай дип әйтә: «Ураза гаете көнендә Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм өеннән берничә

хөрмә җимеше ашамыйча чыкмый иде. Һәм ул гадәттә хөрмәне так санда ашый иде».

Гает намазына барганда ир-атларга күбрәк тәкбир яки зикерләр әйтү сөннәт санала. Тәкбир сүзләре: «Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр! Ләә иләһә илләллаһ, вә-ллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, вә лилләһи-лхәмд». Шулай ук барыр һәм кайтыр юлны алдан уйлык, чөнки хәзрәти Җәбир радыяллаһу ганһе: «Бәйрәм көнендә Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм намаздан (намазга барган юл белән түгел) гадәттә икенче юл белән кайта иде», – дип әйткән. Шулай ук үзебез генә түгел, ир-ат балаларны да, алар намазда тыныч утырыр яки намаз кылырдай яшьләренә җиткәч, гает намазына алып килергә кирәк. Шул рәвешле алар кечкенәдән аның әһәмиятен белеп үсәр.

Хөрмәтле мөселман кардәшләр! Ураза гаете намазы вәҗиб хөкемендә. Аны уку тиешле гамәл. Шуңа күрә вакытында килик. Беренче рәтләргә утырырга тырышыйк. Матур итеп вәгазьләр тыңлагач, намаз укырбыз, гарәпчә Ураза гаете хотбәсен сөйләп, тәкбирләр әйтербез. Әмма безнең фикһ китапларында булган бер хөкемне искә төшерәсем килә: Әбү Хәнифә мәзһәбе буенча гает намазына кадәр һәм аннан соң да өстәмә нәфел намазлар укылмас. Бу вакытта гает намазы гына укылыр. Шул намазыбызның тәртибен искә төшерик. Ул калган намазлардан өстәмә вәҗиб тәкбирләр белән аерылып тора. Без бары тик шушы намазларда гына намаз эчендә кулларыбызны күтәреп, өстәмә тәкбирләр әйтәбез. Игътибарлы булыгыз: намаз вакытында моны онытмагыз, чөнки калган намазларда без кулларыбызны бары тик тәкбир тәхрим вакытында, беренче фарыз тәкбирдә генә күтәрәбез. Бу намазда «Сәнә» догасы укылгач, өч мәртәбә тәкбир әйтәбез, һәр тәкбирдә кулларыбызны күтәрәбез. Икенче рәкәгатьтә өч тәкбирне рөкугъка китәр алдыннан әйтәбез. Бу очракта да кулларыбызны колак очына кадәр күтәрәбез һәм дүртенче тәкбир белән рөкугъка китәбез. Калган өлеше гадәти намаз кебек.

Шунысын да аңларга кирәк: болар барысы да иртә белән башкарыла торган гамәлләр. Безнең әле алда тулы бер көн бар. Менә шушы көнне

бәйрәм итеп үткәрү кирәк тә инде: без бер-беребезгә изге теләкләребезне җиткерәбез. Ураза гаетенә сәхабәләр әйтә торган махсус котлау сүзләре билгеле: «Тәкаббәл Аллаһ миннә вә минкүм!» Аның тәрҗемәсе: «Аллаһы Тәгалә бездән дә, сездән дә кабул итсен». Ягъни сәхабәләр бер-берсенә Рамазанда тоткан уразаларының һәм кылган барча изгелекләренең кабул булуын теләгәннәр. Шул рәвешле бу сүзләр бер үк вакытта котлау да, дога да булып тора. Шулай ук гает көнне сөекле Пәйгамбәребезне искә төшереп, аңа күп итеп салаватлар әйтик.

Дәү әниләребездән һәркайсыбыз «гает коймагы», «гаеттә таба исе чыгарырга кирәк» кебек сүзләрне ишеткәндер, мөгаен. Коймак пешерү мәҗбүри булмаса да, гает уңаеннан бәйрәм табыны әзерләп, туганнарыбыз, дусларыбызны кунакка чакыру күркәм гадәт булып тора. Бу көннең бәйрәм рухы дөньяви булган барлык бәйрәмнәрнең рухларыннан югарырак булырга тиеш. Гади итеп кенә әйткәндә, ике көннән безнең бу җирлек гөрләп торырга тиеш, Аллаһы бирсә.

Газиз дин кардәшләрем, бүген ахшам керү белән 29 нчы Рамазан башлана. Бу изге айның соңгы так көне. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам мең айдан да хәерлерәк булган Кадер кичәсен Рамазанның так көннәрендә эзләргә кушты. Шуңа күрә бүген дә тәравих намазларына килергә тырышыйк. Өйгә кайткач та намазлар укыйк, догада булыйк. Рамазан – ул Коръән ае дип сөйләдек. Кадер кичәсендә эшләнгән һәр эшнең дәрәҗәсе күз алдына китереп булмаслык югары. Шуңа күрә бүген дә Коръән укыйк, садакалар бирик, икенче елга да Рамазанга ирешим дип догалар кылыйк.

Риваятьтә хәбәр ителгәнчә, Ураза гаете җиткәч, Аллаһы Тәгалә җир йөзенә Үзенең фәрештәләрен җибәрер. Алар үзләренең көчле тавышы белән мөрәҗәгать итәрләр, һәм аларны җеннәрдән һәм кешеләрдән кала бөтен мәхлуклар ишетер: «Әй Мөхәммәд өммәте, юмарт булган Раббыгыз каршына чыгыгыз, Ул сезне Үзенең юмартлыгы белән бүләкләр һәм зур гөнаһларыгызны гафу итәр». Ә мөселманнар мәчеткә килгәч, Аллаһы Тәгалә

фәрештәләрдән: «Эшчегә эшен тәмамлагач нәрсә бирелергә тиеш?» – дип сорар. Алар: «Аңа хезмәте өчен тулысынча хакын бирү тиешле», – дип җавап бирер. Шунда Аллаһы Тәгалә әйтер: «Алайса шаһит булыгыз, аларның әҗере һәм хакы – Минем мәгъфирәтем (гөнаһларын гафу итүем) һәм ризалыгым!»

Шуңа күрә, хөрмәтле дин кардәшләрем, ике көннән барыгызны да нурлы мәчетләребездә гает намазына көтеп калабыз.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*ТР Диния нәзарәтенең Дәгъват бүлеге*

# Ураза гаете хотбәсенең гарәпчә укылышы

خطبة عيد رمضان

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ

اَللَّهُ أَكْبَرُ اَللَّهُ أَكْبَرُ لَا إِلَهَ إِلَّا اَللَّهُ وَاَللَّهُ أَكْبَرُ اَللَّهُ أَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ ۞ سُبْحَانَ مَنْ نَوَّرَ قُلُوبَ الْعَارِفِينَ بِنُورِ الْمَعْرِفَةِ وَالْإِيمَانِ وَشَرَحَ صُدُورَ الصَّادِقِينَ بِشَرْحِ الْهِدَايَةِ وَالْعِرْفَانِ وَأَكْرَمَ عِبَادَهُ الْمُؤْمِنِينَ بِصِيَامِ شَهْرِ رَمَضَانَ ۞ اَللَّهُ أَكْبَرُ اَللَّهُ أَكْبَرُ لَا إِلَهَ إِلَّا اَللَّهُ وَاَللَّهُ أَكْبَرُ اَللَّهُ أَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ ۞ سُبْحَانَ مَنْ فَتَحَ عَلَى الصَّائِمِينَ أَبْوَابَ الرَّحْمَةِ وَالْغُفْرَانِ وَزَيَّنَ قُلُوبَ الْمُحِبِّينَ بِتِلاَوَةِ الْقُرْآنِ وَغَلَّقَ عَلَى الصَّائِمِينَ أَبْوَابَ النِّيرَانِ فِي شَهْرِ رَمَضَانَ ۞ وَعَدَ لِلصَّائِمِينَ دُخُولَ بَابٍ مِنْ أَبْوَابِ الْجِنَانِ كَمَا أَخْبَرَنَا نَبِيُّنَا نَبِيُّ آخِرِ الزَّمَانِ: إِنَّ لِلْجَنَّةِ بَابًا يُقَالُ لَهُ الرَّيَّانُ لاَ يَدْخُلُهُ إِلَّا الصَّائِمُونَ فِي شَهْرِ رَمَضَانَ ، شَهْرُ رَمَضَانَ الَّذِي أُنْزِلَ فِيهِ الْقُرْآنُ هُدًى لِّلنَّاسِ وَبَيِّنَاتٍ مِّنَ الْهُدَىٰ وَالْفُرْقَانِ ۞ اَللَّهُ أَكْبَرُ اَللَّهُ أَكْبَرُ لَا إِلَهَ إِلَّا اَللَّهُ وَاَللَّهُ أَكْبَرُ اَللَّهُ أَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ ۞ وَأَشْهَدُ أَنْ لَا إِلَهَ إِلَّا اللهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ ذُوالْعَفْوِ وَالْغُفْرَانِ وَأَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ شَهَادَةً نَاطِقَةً بِالْحُجَّةِ وَالْبُرْهَانِ صَلَّى اللَّهُ تَعَالَى عَلَيْهِ وَعَلَى آلِهِ وَأَصْحَابِهِ صَلاَةً مُوصِلَةً إِلَى دَارِ الْجِنَانِ خُصُوصًا مِنْهُمْ عَلَى أَبِي بَكْرٍ الصِّدِّيقِ وَ عُمَرَ الْفَارُوقِ وَ عُثْمَانَ ذِي النُّورَيْنِ وَ عَلِيٍّ الْمُرْتَضَى الأَئِمَّةِ رِضْوَانَ اللهِ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ ۞

أَمَّا بَعْدُ: أَيُّهَا النَّاسُ، أُوصِيكُمْ عِبَادَ اللهِ وَنَفْسِي أَوَّلاً بِتَقْوَى اللهِ ۞ أَعُوذُ بِاللهِ مِنَ

الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ، بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ ۞ إِنَّ اللَّهَ مَعَ الَّذِينَ اتَّقَوا وَّالَّذِينَ هُم مُّحْسِنُونَ ۞ بَارَكَ اللهُ لَنَا وَلَكُمْ فِي الْقُرآنِ الْعَظِيمِ وَنَفَعَنَا وَإِيَّاكُمْ بِالْآيَاتِ وَالذِّكْرِ الْحَكِيمِ إِنَّهُ هُوَ الْغَفُورُ الرَّحِيمُ الْجَوَادُ الْكَرِيمُ الْعَلِيُّ الْعَظِيمُ السَّمِيعُ الدُّعَاءِ

## خطبة ثانية

إِنَّ الْحَمْدَ لِلَّهِ نَحْمَدُهُ وَنَسْتَعِينُهُ وَنَسْتَغْفِرُهُ وَنُؤْمِنُ بِهِ وَنَتَوَكَّلُ عَلَيْهِ وَنَعُوذَ بِاللَّهِ مِنْ شُرُورِ أَنْفُسِنَا وَمِنْ سَيِّئَاتِ أَعْمَالِنَا مَنْ يَهْدِهِ اللهُ فَلاَ مُضِلَّ لَهُ وَمَنْ يُضْلِلْهُ فَلاَ هَادِيَ لَهُ وَأَشْهَدُ أَنْ لاَ إِلَهَ إِلَّا اللهُ وَحْدَهُ لَا شَرِيكَ لَهُ وَأَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ ۞ إِنَّ اللَّهَ وَمَلَائِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيمًا اَللَّهُمَّ صَلِّ وَسَلِّمْ عَلَيْهِ عَلَى جَمِيعِ الْأَنْبِيَاءِ وَالْمُرْسَلِينَ وَعَلَى مَلاَئِكَتِكَ الْمُقَرَّبِينَ وَعَلَى عِبَادِكَ الصَّالِحِينَ وَعَلَى أَهْلِ طَاعَتِكَ أَجْمَعِينَ مِنْ أَهْلِ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرَضِينَ ۞ اَللَّهُمَّ اغْفِرْ لِلْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَالْمُسْلِمَاتِ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَالْأَمْوَاتِ وَارْحَمْنَا مَعَهُمْ وَاحْشُرْنَا مَعَهُمْ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَاحِمِينَ ۞

# Ураза гаете хотбәсенең кириллицага транслитерациясе

## Беренче хотбә

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахим

Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, ләә иләәһә илләллаһу вәллааһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, вә лилләәһил-хәмде. Сүбхәәнә мән нәввәра кулүүбәл-гаарифиинә би нуурил-мәгърифәти вәл-иимәән, вә шәрахә судүүрас-саадикыйнә би шәрхил-һидәәйәти вәл-гыйрфәән, вә әкрамә гыйбәәдәһүл-мү’миниинә би сыйәәми шәһри рамәдаан. Аллаһу әкбәрү, Аллаһу әкбәр, ләә иләәһә илләллаһу вәллааһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, вә лилләәһил-хәмд. Сүбхәәнә мән фәтәхә галәс-саа’имиинә әбүәәбәр-рахмәти вәл-гуфраан, вә зәййәнә кулүүбәл мүхиббәйни битиләәвәтил Куръәни, вә галләка галәс-саа’имиинә әбүәәбән-нииraани фи шәһри рамәдаан. Вәгадә лис-саа’имиинә дүхуулә бәәбин мин әбүәәбил-җинәәни кәмәә әхъбәранәә нәбиййүнәә нәбиййү әәхириз-зәмәән: иннә лил-җәннәти бәәбән йүкаалү ләһүр-раййәән. Ләә йәдхулүүһү илләс-саа’имүүнә фии шәһри рамәдаан. Шәһрү рамәдаанәлләҙии үнзилә фииһил-Куръәәнү һүдәл-линнәәси вә бәййинәәтин минәл һүдәә вәл-фүркаан, Аллаһу әкбәрү, Аллаһу әкбәр, ләә иләәһә илләллаһу вәллааһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, вә лилләәһил-хәмд. Вә әшһәдү әлләә иләәһә илләллаһу вәхдәһуу ләә шәриикә ләһуу ҙүл-гафьүи вәл-гуфраан, вә әшһәдү әннә Мүхәммәдән габдүһуу вә расүүлүһуу. Шәһәәдәтән нәәтыйкатән билхүҗҗәти вәл бүрһәәни. Салләллааһу Тәгаалә галәйһи вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи саләәтән-мүүсыйләтән иләә дәәрил-җинәән. Хусуусан минһүм галәә Әби Бәкринис-Сыйддикый вә Гумәрал-Фәәрукый вә Гуҫмәәнәз-ҙиннүрайни вә Галиййинил-Мүртәдал ә-иммәти, ридъвәәналлааһи галәйһим әҗмәгыийнә.

Әммә бәгъде: әййүһәннәәс, үсыйкүм гыйбәәдәллааһи вә нәфсии әүвәлән-битәкъүәллааһ. Әгууҙу билләәһи минәш шәйтаанир-раҗиим,

бисмилләәһир-рахмәәнир-рахим. Иннәллааһә мәгалләẓиинәт-тәкау вәлләẓиинә һүм мүхсинүүн. Бәәракәллааһү ләнәә вә ләкүм фил-куръәәнил-гаẓыйим, вә нәфәганәә вә иййәәкүм бил-әәйәәти үәẓẓикрил-хәкиим, иннәһуу һүәл-гафуурур-рахиимүл-җәүәәдүл-кәриимүл-галиййүл-гаẓыйиму сәмиигуд-дүгаа'.

## Икенче хотбә

Иннәл-хәмдә лилләәһи нәхмәдүһуу вә нәстәгыйнүһу вә нәстәгъфируһу вә ну'минү биһии вә нәтәүәккәлү галәйһи вә нәгуузү билләәһи мин шүруури әнфүсинәә вә мин сәййиәәти әгъмәәлинәә мән йәһдииһилләәһү фәләә мүдыйллә ләһүү вә мән йүдълилһү фәләә һәәдиә ләһ. Вә әшһәдү ән ләә иләәһә илләллаһу вәхдәһуу ләә шәриикә ләһ, вә әшһәдү әннә Мүхәммәдән габдүһуу вә расүүлүһ. Иннәллааһә вә мәләә-икәтүһү йүсаллүүнә галәннәбиййи. Йәә әййүһәл-ләẓиинә әәмәнүү саллү галәйһи вә сәллимүү тәслиимәә. Аллаһүммә салли вә сәллим галәйһи вә галәә җәмигыйль-әнбийәә'и вәл-мүрсәлиин, вә галәә мәләә'икәтикәл-мүкаррабиин. Вә галәә гыйбәәдикәс-саалихыйн, вә галәә әһли таагатикә әҗмәгыйн, мин әһлис-сәмәүәәти үәл-арадыйн. Аллаһуммә-гъфир лилмү'миниинә вәл-мү'минәәт, вәл-мүслимиинә, вәл-мүслимәәт, әл-әхъйәәи минһүм вәл-әмъүәәт, вәрхәмнәә мәгаһүм. Үәхшүрнәә мәгаһүм бирахмәтикә йәә әрхәәмәр-раахимиин.

# Ураза гаете хотбәсенең татарчага тәрҗемәсе

## Беренче хотбә

Мәрхәмәтле, шәфкатьле Аллаһы Тәгалә исеме белән.

Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыга гына мактау. Аллаһы Тәгаләгә якынаючыларның (гарифләрнең) күңелләрен (калебләрен) мәгъфирәт (ярлыкау) һәм иман нуры белән нурландырган, тугрыларның (садыйкларның) күңелләрен һидаять һәм белем белән ачкан, мөэмин колларына Рамазан ае уразасын бүләк иткән Зат барча кимчелекләрдән дә пакьтер. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Барча мактаулар Аллаһыга булсын. Рамазан аенда ураза тотучыларга рәхмәт һәм мәгъфирәт (гөнаһларны гафу итү) ишекләрен ачкан һәм ут ишекләрен бикләгән Зат барча кимчелекләрдән дә пакьтер. Ул (Аллаһы Тәгалә) ураза тотучыларга җәннәт ишекләренең берсе аша керүне вәгъдә иткәндер. Бу турыда безгә Пәйгамбәребез, ахырзаман пәйгамбәре хәбәр иткән: «Чынбарлыкта, җәннәтнең бер ишеге бардыр, аңа «Раййән» диелә. Ул ишектән Рамазан аенда ураза тотучылардан башка беркем дә кермәс». Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә: «Рамазан ае кешеләргә туры юл күрсәтә, ялганнан хакыйкатьне аера торган дәлилләр белән Коръән иңдерелә башлаган айдыр». Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Барча мактаулар Аллаһыга булсын. Аллаһыдан башка илаһ юк, Ул берәү генә, Аның тиңдәше юк, Ул гафу Итүче һәм мәгъфирәт Иясе (гөнаһларны каплаучы) икәнлегенә гуаһлык бирәм. Шулай ук, Мөхәммәд — Аның колы һәм расүле икәнлегенә гуаһлык бирәм. Аңа, аның гаиләсенә, сәхабәләренә Аллаһы Тәгаләдән булган җәннәт йортларына илтә торган салават ирешсен. Әй кешеләр! Аллаһы Тәгаләнең коллары, сезгә һәм үземә дә тәкъвалы булырга васыять итәм.

Ташлар белән кыйналып, Аллаһының рәхмәтеннән сөрелгән шәйтаннан Аллаһы Тәгаләгә сыгынам. Рәхимле, шәфкатьле Аллаһы исеме белән. Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә: «Чынбарлыкта, Аллаһы Тәгалә тәкъвалылар һәм игелек кылучылар белән бергә». Аллаһы Тәгалә безгә һәм сезгә бөек Коръән аша бәрәкәт бирсен. Барыбызга да аятьләр һәм хикмәтле зикер аша файда китерсен. Чынбарлыкта, Ул (Аллаһы Тәгалә) гафу Итүче, Рәхимле, юмартлык Иясе, олуглык Иясе, бөек Зат һәм догаларны Ишетүче, кабул Итүче.

## Икенче хотбә

Чынбарлыкта, барча мактау Аллаһы Тәгаләгә, без Аны мактыйбыз, Аннан ярдәм сорыйбыз, Аннан гөнаһларыбызны гафу итүен сорыйбыз, Аңа иман китерәбез, Аңа таянабыз. Аллаһы Тәгаләгә үзебезнең начарлыкларыбыздан, гамәлләребезнең бозыклыкларыннан сыгынабыз. Кемгә Аллаһы Тәгалә һидаять бирсә — аны адаштыручы булмас, ә кемне адаштырса — аны туры юлга күндерүче булмас. Аллаһы Тәгаләдән башка илаһ юк, Ул берәү генә, Аның тиңдәше юк икәнлегенә гуаһлык бирәм. Шулай ук, Мөхәммәд — Аның колы һәм хак илчесе икәнлегенә гуаһлык бирәм. Аллаһым, бөтен пәйгамбәрләргә, илчеләргә, Үзеңә якынайтылган фәрештәләреңә, Үзеңнең изгелек кылучы колларыңа һәм Сиңа итагать итүче әһелләрнең һәммәсенә — күк әһелләреннән һәм җир әһелләреннән булганнарының барчасына салават һәм сәлам ирештер. Аллаһым, мөэминнәрне вә мөэминәләрне, мөселманнарны вә мөслимәләрне, алар арасыннан исән вә вафат булганнарын мәгъфирәтең белән гафу ит. Алар белән берлектә безгә рәхимле бул һәм безне Үз рәхмәтең илә алар белән бергә булырга насыйп ит. Йә рәхимлеләрнең иң Рәхимлесе.

*30 нчы март вәгазе,*

*шәүвәл аеның 1 нче көне, һиҗри исәп буенча 1446 ел*

# Ураза гаете вәгазе

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Бөек бәйрәм – Ураза гаете – килеп җитте. Раббыбыз Сөбеханәһу вә Тәгалә Рамазан аенда кылган һәрбер изге гамәлләребезне кабул кылсын, тоткан уразаларыбызны кабул кылсын, биргән фитр садакаларын, уразаларын тота алмаган кардәшләребезнең фидияләрен, ифтар ашларыбызны, тәравих намазларыбызны, зәкятләребезне – һәрбер изгелекләребезне кабул кылсын. Гает намазында һәрберебезгә гөнаһларыбыздан арынырга насыйп кылсын иде!

Шушы ураза мәдрәсәсе, ураза мәктәбе тәмамлана, һәм бүген без сезнең белән диплом алабыз дип хис итик үзебезне. Ләкин шушы диплом безгә бирелерме икән, җәмәгать әл-мөслимин? Раббыбыз Сөбеханәһу вә Тәгалә белеп һәм белми кылган хата-гөнаһларыбызны гафу итәрме-юкмы, тоткан уразаларны кабул итәрме-юкмы – шул хакта да онытмыйк. Раббыбыз Сөбеханәһу вә Тәгалә кабул кылсын иде. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм вакытында сәхабәләр: «Без уразаны тоткач, ярты ел буе: «Йә, Раббым, уразамны кабул кыл!» – дип, икенче яртыеллыкта: «Киләсе уразаны күрергә насыйп кыл!» – дип дога кыла идек», – дип сөйләгәннәр.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, менә без мөселманнар: «Лә иләһә илләллаһ Мүхәммәд расүлуллаһ», – дип шәһадәт әйтәбез. Менә, мәсәлән, мин – Рөстәм, кемдер – Мансур, кемдер – Камил һ. б. Раббыбыз Аллаһы белән нинди

мөгамәләдә без, Раббыбыз Сөбеханәһу вә Тәгалә безнең тормышта нинди урынны ала? Күпме вакытны без Раббыбыз Аллаһыга тапшырабыз? – шул турыда уйлыйбызмы-юкмы? Берәр эш кылганда, Раббыбызның безне күреп торуы хакында онытмыйбызмы, җәмәгать? Кайда булсак та, нишләсәк тә, Аллаһы Тәгалә безне бөтен җирдә күрә. Моны онытмыйбызмы, җәмәгать? Өйдә без нинди, урамда без нинди, эштә без нинди, мәчеттә без нинди – Аллаһы Газзә вә Җәллә бөтенесен күрә. Һәм һәрберебез, вакыты килгәч, Раббыбыз Аллаһы каршына басып, җавап бирербез. Бу турыда онытмыйк, җәмәгать.

Аллаһының рәхмәте белән «Лә иләһә илләллаһ Мөхәммәд расүлуллаһ» дип шәһадәт әйтәбез. Күз алдыбызга китерик, менә без гаиләбез белән өйдә утырабыз. Һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм безнең өебезгә керә. Сөекле Пәйгамбәр безнең өйгә керә! Нәрсә әйтер икән Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм? Безнең киемнәргә карасa, безнең шкафларга, аяк киемнәренә, безнең кухняларга караса, суыткычларны ачып караса, өстәлләрдә булган ризыкларны күрсә, нәрсә әйтер иде сөекле Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм? Безнең йомшак диван-урыннарыбызны күрсә, нәрсә әйтер иде сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм? Бу турыда уйлыйбызмы, юкмы? Күзләребезне ничек яшерергә, ничек Расүлебезгә карамаска, ояттан җир астына кереп китәргә әзер булыр идекме? Кайбер өйләрдә, шкафларын ачсаң, эчендә матур җирдә харам әйберләр дә тора. Нәрсә әйтер идек Расүлебезгә? «Лә иләһә илләллаһ Мөхәммәд расүлуллаһ» дип әйтәбез бит без. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Намаз вакыты керде, әйдә әле намазлыкларны җәйик», – дисә, өйләребездә намазлыклар бармы ул? Өебезнең кайсы ягында кыйбла – шуны беләбезме ул? Намазлыкны җәеп баскач, ничек намаз укырга кирәклеген беләбезме ул?

Бөтен мәчетләрдә дә хәзер дәресләр бара. «Килегез, намазга өйрәтербез, уразага өйрәтербез, килегез», – дип безне чакыралар. Ә без, җәмәгать, Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янында басып намаз укый алыр идекме? «Фатиха»сын беләбезме, рөкүгъ-сәҗдәләрне беләбезме? Җәмәгать,

вакыт килде, хәзер укырга, өйрәнергә вакыт. Менә без сезнең белән бергә гает намазына җыелдык. Күпмебез намазның ничек укыласын белә, ә күпмесе белми икән, җәмәгать әл-мөслимин? Без мөселман бит.

Ураза вакытында кайберәүләр: «Хәзрәт, мин бит эшлим, хәзрәт, мин бит кабинетта утырам, хәзрәт, хәзрәт...» – дип, ураза тотмауның сәбәпләрен санап китәр. Җәмәгать, уразаны хәзрәтләр дә, мөфтиләр дә түгел, аны Аллаһы Тәгалә безгә фарыз иткән. Аллаһы безне бөтен җирдә дә күрә, ә кемдер хәтта Рамазан аенда да уразаны тотмаган. Сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әгәр дә кем уразаны күреп, ураза вакытында яшәп һәм гаеткә килгәндә Аллаһының рәхмәтен һәм мәгъфирәтен алмый икән, ул зур хәсрәттә булыр», – дип әйткән.

Төрлебез төрле байлыкта яшибез: ятимнәр дә, мохтаҗлар да бар, туганнарыбыз арасында үзе генә, ялгыз калган туганнарыбыз да бар. Уразада без һәрберсенә ярдәм итәргә тырыша идек. Мендәр астындамы, банкадамы бераз акча җыелып, нисабка җитә икән, ятим-мескеннәргә 40 тан бер өлешен зәкят итеп, садака итеп бирергә тиешбез. Аны үтәдекме, аны үтибезме? Бер кеше зәкят турында сорагач, күләме шулкадәр дигәч, калькуляторны алып санады да: «Хәзрәт, бу күп була бит», – ди. Юк, җәмәгать, күп булмый, чөнки ул безнеке түгел, Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә безнең аша мескен-ятимнәрнең өлешен бирә, без шушыны мескен-ятимнәргә бирергә тиеш. Үзебездә калдырсак, харам була, гөнаһ була. Аллаһы Тәгалә шулардан сакласын иде.

Озакламый Корбан бәйрәме дә килеп җитәр. Корбан бәйрәме – ул хаҗ, җәмәгать әл-мөслимин. Сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәм Раббыбыз Аллаһы Тәгалә без гомердә бер тапкыр булса да хаҗга барырга тиешбез дип җиткерде. Менә хәзер без тулы мәчетләрдә утырабыз, гаеттә утырабыз, әле хаҗда булмаган кешеләр – хаҗга җыенабызмы? Мөмкинлегебез бар икән, җәмәгать әл-мөслимин, бармау – гөнаһ. «Хәзрәт, быел мөмкинлек бар, ләкин икенче елга барырмын», – диләр кайберәүләр. Икенче елга без исән булырбызмы, юкмы – аны Аллаһыдан башка беркем

белми. Шуңа күрә без, җәмәгать әл-мөслимин, Аллаһы форсат биргән икән, кесәдә акчаларыбыз бар икән, хаҗга җитә икән, хаҗга барыйк, бармау – гөнаһ. Аның турында онытмагыз.

Без «Лә иләһә илләллаһ Мүхәммәд расүлуллаһ» дип шәһадәт китердек, әлхәмдүлилләһи Раббил-гааләмин, без бөтен җирдә мөселман. Әйдәгез әле, тагы гаиләләребезгә кайтыйк. Гаиләләребездә без нинди, балаларыбызга нинди тәрбия бирәбез? Хатыныбызмы хөрмәт итәбезме? Безнең хатыныбыз – сөекле әти-әнисенең яраткан кызы, ә без аның белән ничек сөйләшәбез, без аның күз яшьләрен чыгарабызмы? Без аны кайгыртабызмы, аңа бүләкләр бирәбезме? Шушы гает намазында никадәр ир-ат утыра, ахыргы тапкыр хатыныбызга кайчан чәчәк бүләк иткән идек? Әйдәгез, шушы бәйрәмдә хатыныбызга бүләкләр алыйк.

Еш кына сорыйлар: «Нигә хәзерге кызларыбыз гарәпләр шикелле киенә?» Әйдәгез хатыннарыбызга милли булган күлмәкләрне, милли булган жилетларны, милли булган яулыкларны бүләк итик бәйрәмнәрдә. Әлбәттә, аларның бәясе бар, кыйммәт тора ул, ләкин күпмегә акча җитә, җыйыйк та, бер кечкенә кием булса да бүләк итик.

Без, татар халкы, җәмәгать, телебезне онытмаска, гореф-гадәтләребезне онытмаска тиеш. Милли киемнәрне онытмаска тиешбез, шул хакта уйланыйк. Хәзер мәчеттә төрле милләт вәкилләре утыра, һәрбер милләт үз теленнән, үз гореф-гадәтләреннән, үз эшләреннән оялмасын иде. Чөнки һәрбер милләтне Раббыбыз Сөбеханәһу вә Тәгалә яраткан.

Туганнарны да искә алыйк, җәмәгать. Сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең хәдис-шәрифләрендә болай дип әйткән: «Кем бу дөньяда хәерле һәм озын тормышлар тели, шул туганлык җепләрен өзмәсен». Әйе, хәзрәт, без өзмибез, өзмибез, менә ватсаптан котладым, телеграмнан котладым инде, диләр. Җәмәгать, ата-аналарыбызны искә алыйк: телефоннар да булмаган, телеграфларга барып, телеграммаларын сугып, вокзалларда туңып, автобусларына утырып, күпме җәяү барып, туганлык җепләрен сакла-

ганнар, өзмәгәннәр. Бездә хәзер һәрбер кешедә – машина, һәрбер кесәдә – телефон, ә вакытыбыз юк, смс җибәребез дә, шуның белән «мин туганлык җепләрен өзмим» дибез.

Сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән бер сәхабә сорый: «Йә Расүлуллаһ, әгәр дә туганнар минем белән аралашырга теләмәсә?» Сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Син аралашырга тиеш, һәм бу туганлык җепләрен саклау булыр». Дөньяда төрле хәлләр булырга мөмкин, ләкин нәрсә генә булса да, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйткәнчә, иң хәерлесе шул ки, кем беренче килеп, сәлам биреп, гафу үтенеп, дуслашырга омтыла. Иң хәерле кеше ул булыр.

Җәмәгать, туганлык җепләрен, ике туган, өч туган, алты, җиде туганны да без белергә тиеш. Җиде әби-бабайларыбызны да, җиде туганнарны да онытырга ярамый. Бер-беребез белән аралашыйк, туган булып яшик.

Җәмәгать, халкыбыз мәкале «Күрше хакы – Аллаһы хакы» дип әйтә. Әйе, төрле күршеләр бар, яхшы күрше дә, начар күрше дә, ләкин, җәмәгать әл-мөслимин, алар – күршеләр. Сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә Җәбраил галәйһиссәлам килеп, күрше хакы турында бик күп сөйләгән, хәтта Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтә: «Мин аларны варисларга да кертергә кирәк булыр дип уйладым», – ди. Юк, күршеләр вариска кермәде, ләкин аларның дәрәҗәсе шундый зур. Нинди генә милләттән булмасын – урыс, чуваш, мари, татар, кыргыз, үзбәк, таҗик – ул безнең күрше, Аллаһы каршында безнең күршебез. Хәтерлисезме, әти-әниләребез берәр тәмле әйбер пешерсә, «бар әле күршегә керт» дип җибәрә иде. Без кертә идек, ә кире кайтканда ул тәлинкәләр беркайчан да буш кайтмый иде. Ә без исә хәзер күршенең исемен дә белмибез. Күршенең исемен дә белмибез! Үзебезчә, дин белән акланып, ул бит башка милләт, нишләп мин аның белән исәнләшергә тиеш, дибез. Тиеш! Мөселманча исәнләшмисең икән, русча исәнләш, аларның телен өйрәнеп, аларча исәнләш. Бел, ул – синең күршең, ул – Аллаһы каршында синең күрше!

Җәмәгать, дусларыбыз да бар. Халкыбыз «Дустың кем булса, син шул буласың» ди. Безнең дусларыбыз Аллаһы дуслары булсын. Безнең дусларыбыз намуслы, изге гамәлле, мәчет әһеле булырга тиеш, җәмәгать. Кемдер әле эчүне дә ташламаган, кемдер сүгенүне дә ташламаган, кемдер сигарет-папирус та ташламаган, ләкин Аллаһы күрә, онытмый. Һәрберезгә шушы гөнаһлардан пакьләнергә язсын, дусларыбыз Аллаһы дуслары булса иде, мәчет әһелләре булса иде. Өйләребезгә изге кешеләр генә кереп, өстәлләребездән намазлы, уразалы, тәкъва кешеләр генә ашаса иде. Шуның өчен тырышыйк, җәмәгать әл-мөслимин.

Хөрмәтле дин кардәшләрем! Рамазан аенда кылган гыйбадәтләребезнең тәмен, кыйммәтен ел дәвамында саклап калырга тырышыйк. Моның өчен бу айда ничек тырышкан булсак, киләсе айларда да фарыз һәм өстәмә гыйбадәтләр кылып торыйк. Шәүвәл ае башланды. Бу айның алты көнендә ураза тоту бик тә саваплы булып тора. Хәдистә әйтелгәнчә: «Рамазан ае дәвамында ураза тотып, шуңа өстәп шәүвәлнең алты көнендә ураза тоткан кеше ел дәвамында ураза тотучыга тиң». Инде Рамазан уразаларын тотып чыкканбыз икән, тагын алты көн ураза тотарга тырышыйк, җәмәгать. Аны алты көн рәттән тотарга да, көнаралаш уразада булып та алты көнгә тутырырга мөмкин.

Бәйрәмнәребез мөбарәк бусын! Раббыбыз Сөбеханәһу вә Тәгалә һәрбер гаиләгә бәхет-бәрәкәт бирсен, һәр гаиләне Раббыбыз Аллаһы күз тиюдән, зәхмәттән, дошманнардан, сихерчеләрдән, җеннәрдән, пәриләрдән, тавышлардан даими рәвештә сакласын. Балаларыбызга сау-сәламәт булып, намуслы булып, иманлы булып, тәүфыйклы, һидаятьле, озын гомерле булып яшәргә насыйп итсен! Раббыбыз Сөбеханәһу вә Тәгалә оныкларыбызга, оныкларыбызның оныкларына, бөтен нәселләребезгә һидаятьтә, гыйбадәттә, изгелектә булырга насыйп итсен! Бәйрәмнәр белән!

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Рөстәм хәзрәт Хәйруллин,*

*Казанның «Гаилә» мәчете имам-хатыйбы*

*4 нче апрель вәгазе,*

*шәүвәл аеның 6 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1446 ел*

# Үлемнән соң безне нәрсә көтә?

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Адәм баласы бу дөньяга кунакка гына килгән. Кайсыдыр кешенең бу дөньядагы гомере озын булып, кайсыдыр кешенеке кыска булачак. Ләкин шушы кыска яки озын юлыбызның ахыры бар – ул үлем. Коръәни Кәримнең «Әр-Рахмән» сүрәсендә болай диелгән:

كُلُّ مَنْ عَلَيْهَا فَانٍ ﴿٢٦﴾

**«Аның өстендә булган** [һәм туфракта яшәгән] **һәркем – фани».**

«Әр-Рахмән / Мәрхәмәтле», 55:26

Адәм баласы җир йөзенә иң күркәм кыяфәттә җибәрелгән. Ул туу-га, аңа хөрмәт йөзеннән азан әйтелә, вафат булгач, намаз укылып җиргә иңдерелә. Чөнки кеше – Аллаһы Тәгалә барлыкка китергән мәхлукларның иң хөрмәтлесе.

Шушы иң күркәм кыяфәттә җибәрелгән адәм баласын үлемнән соң нәрсә көтә соң? Үлем килү белән кеше өчен Кыямәт җитә дисәк тә була. Кешенең гамәл дәфтәрләре ябыла. Эшләре туктала.

Кылган гамәлләребезнең безгә ни китерәсен без Коръән аятьләреннән, Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәдисләреннән укып беләбез. Бу дөньяда кылган һәр гамәлебез, эшебез, сүзебез белән без

ахирәт тормышына нигез салабыз. «Ни чәчсәң, шуны урырсың», – дигән мәкаль дә монда урынлы булыр. Бер хәдистә болай дип әйтелгән: «Өч әйбер мәрхүмне кабергә озата барыр: аның гаиләсе, мал-мөлкәте һәм гамәлләре. Ләкин аларның икесе кире кайтачак, берсе генә калачак. Аның гаилә әгъзалары һәм милке кире кайтачак, ә гамәлләре үзе белән Аллаһы хозурына күчәчәк»[1].

Үлемнең хакыйкать һәм чынбарлык икәнлеген, Аллаһы Тәгаләнең үзгәрми торган бөек кануны булуын һәрберебез аңлыйдыр. Динсез, гөнаһлы кешеләрне кабер газаплары, җәһәннәм газаплары көтүе билгеле. Ә иманлы, тәкъва кешеләрнең кабере дә җәннәт бакчаларыннан бер бакча булыр.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәдисләреннән билгеле булганча, үлгән кеше күмелеп, аны озатучылар таралгач, шушы мәет янына Мөнкир һәм Нәкир исемле ике фәрештә килер (бу сорау бирүче фәрештәләр). Алар мәеткә түбәндәге сорауларны бирерләр:

– Раббың кем?

– Динең кайсы дин?

– Пәйгамбәрең кем?

Иманлы кеше: «Раббым – Аллаһы Тәгалә, динем – Ислам, пәйгамбәрем – Мөхәммәд галәйһиссәлам», – дип җавап бирер. Сорау алучы фәрештәләр шулай ук: «Син Мөхәммәд галәйһиссәләм турында нәрсә беләсең һәм нәрсә уйлыйсың?» – дип әйтерләр. Иманлы кеше болай дип җавап кайтарыр: «Мин шәһадәт китерәмен ки, ул – Аллаһының колы һәм илчесе».

Әмма имансыз яки монафикъ булган мәет: «Мин аны белмим», – дип җавап бирер.

Соңыннан Мөнкир һәм Нәкир сорауларына дөрес җавап бирүче мөэминнең җанын Аллаһы Тәгалә Кыямәт көненә кадәр тынычландырыр. Әгәр мәет тәкъва кешеләрдән булса, кабер аны: «Йә Аллаһының колы! Җир йөзендә яшәгәндә син минем өчен Аллаһы яраткан бәндәләрнең берсе идең.

[1] Имам әл-Бохари.

Хәзер исә мин сиңа нәрсә әзерләгәнемне кара!» – дип, күркәм мөгамәлә белән каршы алыр. Бу кеше өчен кабер иркен, киң һәм ямьле булачак.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм сәхабәләренә: «Кеше үлү белән аның дүрт нәрсәсе алыныр», – дигәч, сәхабәләр: «Болар нәрсәләр соң?» – дип сораганнар. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам болай дигән: «Иң әүвәле – Газраил галәйһиссәлам кешенең җанын алыр. Икенчесе – малы варисларга (балаларына) калыр. Өченчесе – ите кортларга калыр. Дүртенчесе – сөяге җиргә калыр». Шул вакыт сәхабәләр: «Йә Расүлуллаһ! Ә кешегә нәрсә кала соң?» – дип сораганнар. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Укыган булса, гамәле кала», – дип җавап биргән. Димәк, укымаган, гамәл кылмаган булса, кешегә һичнәрсә калмый икән, Аллаһы Үзе сакласын.

«Әли Гыйммран» сүрәсенең 185 нче аятендә болай диелә:

كُلُّ نَفْسٍ ذَائِقَةُ الْمَوْتِ ۗ وَإِنَّمَا تُوَفَّوْنَ أُجُورَكُمْ يَوْمَ الْقِيَامَةِ ۖ فَمَن زُحْزِحَ عَنِ النَّارِ وَأُدْخِلَ الْجَنَّةَ فَقَدْ فَازَ ۗ وَمَا الْحَيَاةُ الدُّنْيَا إِلَّا مَتَاعُ الْغُرُورِ ﴿١٨٥﴾

**«Һәрбер җан үлемне татыячак.** [Инкяр итүчеләр үлемнән соң җәзасыз калмаячак]**. Әҗерләрегез сезгә** [каберләрегездән кубарылганнан соң] **Кыямәт көнендә генә тулысынча биреләчәк.** [Шулвакыт] **Кем дә кем уттан ераклаштырыла һәм җәннәткә кертелә, һичшиксез, ул котылган булыр. Дөнья тормышы** [һәм аның ләззәт, ялтыравыклары] **исә – алданып** [шул ләззәтләрдән] **файдалана торган нәрсә».**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:185

Без яратып яши торган бу дөньябыз – фанидыр, ягъни бетә торган, ахыры була торган, ә ахирәт тормышы – бакыйдыр, ягъни мәңгелектер.

Кеше үлү белән юкка чыкмый, ә икенче төр тормышка гына күчә. Без мәңгелек ахирәт тормышының барлыгына ышанып, аңа әзерлекне бу дөньяда алып барырга тиешбез. Ахирәттә кирәк булачак азык – ул безнең

яхшы гамәлләребез, зикерләребез, садакаларыбыз. Кияр киемебез – ул укыган Коръәни Кәримебез, чөнки аны күп укыган мөселман кабереннән кубарылып торганда, Коръән аңа таҗ киертер һәм киyarенә кием бирер. Биргән садакаларыбыз – Мәхшәр көнендә безне эсседән саклый торган болыт булыр. Тоткан уразаларыбыз безнең өчен җәннәттә «Әр-Раян» капкаларын ачар...

Имам Фәкыйһ рахмәтуллаһи риваятьләрдә әйтәдер: «Әгәр бер кеше ахирәт газапларыннан котылырга теләсә, дүрт төрле нәрсәне үтәргә вә дүрт төрле нәрсәдән тыелырга тырышсын. Үтәргә тиешле булганнары: намазны күп уку һәм калдырмаска тырышу, зикер-тәсбихләрне күп әйтү, Коръән уку, садака бирү. Тыелырга тиешле булганнары: ялган һәм гайбәт сөйләмәү, хыянәт итмәү, сүз йөртмәү, тәненә бәвел (сидек) тидерүдән саклану».

Шушы хәерле гамәлләребезне күбрәк кылып, Коръәннең «Мөхәммәд» сүрәсенең 15 нче аятендә тасвирланган җәннәттә очрашулар насыйп булса иде!

مَّثَلُ الْجَنَّةِ الَّتِي وُعِدَ الْمُتَّقُونَ ۖ فِيهَا أَنْهَارٌ مِّن مَّاءٍ غَيْرِ آسِنٍ وَأَنْهَارٌ مِّن لَّبَنٍ لَّمْ يَتَغَيَّرْ طَعْمُهُ وَأَنْهَارٌ مِّنْ خَمْرٍ لَّذَّةٍ لِّلشَّارِبِينَ وَأَنْهَارٌ مِّنْ عَسَلٍ مُّصَفًّى ۖ وَلَهُمْ فِيهَا مِن كُلِّ الثَّمَرَاتِ وَمَغْفِرَةٌ مِّن رَّبِّهِمْ ۖ كَمَنْ هُوَ خَالِدٌ فِي النَّارِ وَسُقُوا مَاءً حَمِيمًا فَقَطَّعَ أَمْعَاءَهُمْ ﴿١٥﴾

«[Әмерләрне тотып, тыелганнардан тыелучы] **Тәкъвалык ияләренә вәгъдә ителгән җәннәтнең сыйфаты** [шушы] **ки, анда тәме һәм исе үзгәрмәгән су елгалары, тәме үзгәрмәгән сөт елгалары һәм** [дөнья шәраблары кебек] **эчүчеләр өчен** [башны авырттырмаган һәм исертеп бик күп афәтләргә сәбәп бирмәгән] **ләззәтле шәраб елгалары, һәм** [балавыз һәм төрле чит нәрсәләрдән] **арындырылган бал елгалары бар. Алар өчен анда җимешләрнең һәр төре бар. Янә** [гөнаһларын ишетеп, оялудан ләззәтләре бозылмасын өчен] **Раббыларыннан**

**мәгъфирәт** [бар]**.** [Шушындый җәннәттә мәңге калачак кеше] **Ут эчендә мәңге калачак һәм эчәк-бавырларны өзгәли торган кайнар су эчерелгән** [инкяр итүче] **кеше кебекме соң?»**

«Мөхәммәд», 47:15

Үлемнең кайчан киләчәген белмәвебез сәбәпле, бер яктан карaганда, без бәхетле дә. Икенче яктан караганда, безнең бүген килгән җомга намазыбыз бәлки соңгысыдыр, бәлки якыннарыбыз белән дә соңгы тапкыр күрешкәнбездер. Һәрберебезгә үзенә сорау биреп, уйланып карарга кирәк: бүген Аллаһы Тәгалә миңа үлем фәрештәсен җибәргән булса, мин бу дөньяны калдырып китәргә әзерме? Үзем белән нинди гамәлләрем китә? Һәр адәм баласы, дөнья эшләреннән туктап, вакыт-вакыт үз тормышына бәя биреп, анализ ясап алса, бу бик куркәм булыр иде. Бу дөньядан әзерлексез китүдән Аллаһы Тәгалә безнең һәрберезне сакласын.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Айморат хәзрәт Хаҗиев,*

*Казанның «Әл-Мәрҗани» мәчете имамы*

# «Нәрсә? Кайда? Кайчан?»

# СЕНТЯБРЬ – ДЕКАБРЬ

## Казанда XIII Якупов укулары узды

Рабигыль-әүвәл аеның 16 нчы көнендә (19 нчы сентябрьдә) «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә «XIII Якупов укулары» узды. Җыен Татарстан мөфтияте, Россия ислам институты һәм «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе тарафыннан оештырылды.

Конференция танылган татар мәгърифәтчесе, галим һәм дин эшлеклесе, ислам яңарышы чорында «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең беренче директоры Вәлиулла хәзрәт Якуповның (1963–2012) бай рухи-дини һәм интеллектуаль мирасын саклау һәм өйрәнү максатыннан үткәрелә. Конференциядә катнашучыларны Татарстан Мөфтие, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе директоры Камил хәзрәт Сәмигуллин исеменнән аның урынбасары Равил хәзрәт Зөфәров сәламләде һәм Вәлиулла хәзрәт алып барган киң кырлы эшчәнлекнең мөһимлеген билгеләп үтте.

Мәгълүм булганча, Вәлиулла хәзрәт җитәкчелегендә «Иман» нәшрияты эшли, ул меңләгән тираж белән үз заманы өчен кирәк булган мөселман әдәбиятын һәм вакытлы матбугатны бастырып чыгара. Вәлиулла хәзрәт беренче булып барлык дини уку йортлары өчен стандартлар эшли һәм шуның белән бергә республикадагы дини уку йортларының алга таба эшчәнлеген тәэмин итә. Ул бер үк вакытта оста оештыручы да, педагог та, мәгариф системасы өчен уку әсбапларын нәшер итүче дә, киләчәкне күзаллап, уку-укыту процессын оештыручы да була.

## Нәзарәт Газзә Секторына тагын 30 тонна гуманитар йөк җибәрде

ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды Газзә Секторында оккупантлар чолганышында калган халык өчен чираттагы гуманитар йөк җибәрде. РФ Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының ТР мөселманнары Диния нәзарәте өчен махсус бирелгән очкычына «Жуковский» аэропортында гомуми авырлыгы 30 тонна булган хәләл тушенка төялде. Азык-төлек Россиянең төрле почмакларында яшәүче битараф булмаган кешеләрдән килгән акча хисабына сатып алынды. ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең хәйрия фонды вәкилләре азык-төлекне Мисырның «Әл-Ариш» аэродромында Мисырның Кызыл Ярымай җәмгыятенә тапшырды. Алар аны Газзә халкына тапшырачак.

Бу – ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды тарафыннан Фәләстыйндә яшәүче дин кардәшләр өчен өченче тапкыр җибәрелгән гуманитар йөк. Моннан алдарак, 2024 елның 28 августында РФ мөселманнары Диния нәзарәте белән берлектә бер йөк озатылган иде. Ә элегрәк, 2023 елның ноябрь башында 20 тонна күләмендә йөкне җибәрү һәм алып барып җиткерү эшләре оештырылды. Гомумән алганда, Татарстанның Диния нәзарәтеннән Газзәдә гомер итүче гади халык өчен барлыгы 60 тонна гуманитар йөк тапшырылды.

## Казанда совет заманында сөннәтче бабайларның хезмәтенә зур бәя бирүгә багышланган түгәрәк өстәл узды

Рабигыль-әүвәл аеның 22 нче көнендә (25 нче сентябрьдә) Казанда Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсәсендә «Сөннәтче, бабачы – гореф-гадәтләрне, динебездә чисталыкны саклаучы» дигән фәнни-гамәли конференция узды. Түгәрәк өстәл Россиядә Гаилә елы һәм Татарстан

мөфтияте игълан иткән Гаилә һәм хәләл яшәү рәвеше елы кысаларында үткәрелде. Фикер алышу вакытында традицияләр дәвамчанлыгы, дин һәм милләт яшәешендә күркәм гореф-гадәтләрнең аерылгысыз булуы, сөннәткә утыртуның мөһимлеге, сөннәтче бабайларның исемнәрен мәңгеләштерү белән бәйле мәсьәләләр күтәрелде.

Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, утырышта чыгыш ясап, сөннәтче сүзенә зуррак мәгънә салу зарурлыгын билгеләп үтте. Ул сөннәтче дип ир балаларны сөннәткә утыртучыларны гына түгел, ә динебезне, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Сөннәтен саклаучы аксакалларны атарга тәкъдим итте. Камил хәзрәт асылыбызга, төп рухи нигезләребезгә кайту һәм саклану өчен бүгенге көндә милләтебезгә сөннәтче бабайлар кирәклеген аңлатып үтте. Аның фикеренчә, Рәсүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең нәсыйхәтләрен яшь кеше тулысынча аңлап та җиткермәскә мөмкин, ә аксакаллар, динебезне һәм Пәйгамбәребезнең Сөннәтен яратучы бабайлар зирәклеге белән аерылып тора.

## Казанда мөселман яшьләре «MuslimQuiz» акыл көрәшенең дүртенче сезонын башлады

Рабигыль аеның 23 нче көнендә (26 сентябрьдә) Диния Нәзарәтендә мөселман яшьләре өчен «MuslimQuiz» акыл уеннарының яңа сезоны ачылды. Бу сезонның беренче уенында 21 такым, шул исәптән 4 яңа команда катнашты. 2023–2024 ел сезонында «MuslimQuiz»ның 6 очрашуы (5 төп уен һәм финал) узачак. Очрашу нәтиҗәләре буенча иң күп балл җыйган команда кыйммәтле бүләк алачак.

## Ютазы мөхтәсибәтендә Казыйлар шурасының күчмә утырышы булды

Рабигыль-әүвәл аеның 27 нче көнендә (30 сентябрь) Ютазы районының Урыссу бистәсендә ТР мөселманнары Диния нәзарәте Казыйлар шурасының чираттагы утырышы булды. Чарада Татарстанның барлык казыят башлыклары, шулай ук республиканың көньяк-көнчыгыш төбәгендәге (Баулы, Бөгелмә, Лениногорск, Азнакай, Ютазы районнары) барлык имам-мөхтәсибләр һәм имам-хатыйблар катнашты. Утырышта халыктан килгән мөрәҗәгатьләр һәм Татарстаннан мобилизацияләнгән мөселманнар өчен гуманитар ярдәм җыю мәсьәләләре каралды. Казыят башлыклары шулай ук сугышчыларга җеназа уздыру тәртипләре белән бәйле мәсьәләләрне аңлатты. Аннан Нәзарәт казыятларының урыннардагы эшчәнлеге турында чыгышлар тыңланды.

## Октябрь аенда Татарстанда мәчетләр каршында Ислам нигезләре һәм дини тәрбия буенча курслар башланды

Октябрь аенда Татарстанда мәчетләр каршында Ислам нигезләре һәм дини тәрбия буенча курслар башланды. Түләүсез дәресләр белем алырга теләүчеләр өчен республиканың 600 ләп мәчетендә һәм мәгърифәт үзәгендә оештырылды. Аларда 1200 гә якын мөгаллим белем бирә. Моннан тыш, Татарстан мөфтияте – «Ислам. Беренче адымнар», Россия ислам институты «Без – татарлар!» курсларын оештыра. Medrese.tatar мәгариф платформасында татар һәм рус телләрендә «Онлайн-медресе» дип аталган түләүсез мобиль кушымта да эшли.

## Казанда мөслимәләр өчен «Яшь килен» курслары эшләде

Октябрь–ноябрь айларында Казанда мөселман яшьләре арасында зур популярлык казанган «Яшь килен» проектының яңа унберенче сезоны узды. Россиядә Гаилә елы һәм Нәзарәт тарафыннан игълан ителгән Гаилә һәм хәләл яшәү рәвеше елы кысаларындагы курслар Аллаһы Тәгалә кануннары буенча бәхетле гаилә корырга һәм гаилә учагын саклап калырга теләүчеләр (16 яшьтән алып һәм өлкәнрәк булган, кияүдә булмаган, ярәшелгән мөслимәләр һәм кызларын кияүгә бирергә җыенган әниләр) өчен оештырылды. «Яшь килен» проекты мөселман яшьләре арасында гаилә кыйммәтләрен ныгыту максатыннан гамәлгә ашырыла һәм татар-мөселман гореф-гадәтләре күзлегеннән чыгып, никах белән бәйле төрле мәсьәләләргә багышлана. Бу юлы курслар 30 дан артык мөслимәне җәлеп итте.

## Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин эш сәфәре белән Ютазы районында булды

Рабигыль-ахыр аеның 2 нче көнендә (5 октябрьдә) Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин эш сәфәре белән Ютазы районында булды. Биредә Мөфти катнашында «Фәнис» мәдрәсәсендә тәхфиз (Коръән ятлау) укучылары өчен яңа уку сыйныфлары һәм Ютазы районының Бәйрәкә авылында «Габделәхәт» мәчете ачылды.

Камил хәзрәт Татарстанның көньяк-көнчыгыш өлеше – Баулы, Бөгелмә, Лениногорск, Азнакай һәм Ютазы районнары – мөхтәсибләре белән дә очрашты. Район башлыгы, Мөфти, Ютазы районы имам-мөхтәсибе һәм Урыссуның «Фәнис» мәдрәсәсе җитәкчесе Марат хәзрәт Мәрданшин мөхтәсибәт белән җирле хакимиятнең үзара хезмәттәшлеге, районда мәхәлләләр эшчәнлеге һәм башка мәсьәләләр, шул исәптән Татарстаннан мобилизацияләнгән солдатларга ярдәм күрсәтү хакында сөйләште.

Мөфти «Фәнис» мәдрәсәсе шәкертләре белән дә очрашып, үгет-нәсыйхәтен җиткерде.

Камил хәзрәт Сәмигуллин «Габделәхәт» мәчете ачылышындагы вәгазендә мәчетләрнең мөселманнар тормышындагы әһәмияте һәм фазыйләтләре турында сөйләде. Мәчет төзелешендә катнашучыларга рәхмәт хатлары тапшырды. Аннан соң Мөфти җитәкчелегендә өйлә намазын укылды.

Ике катлы мәчет 120 кешегә исәпләнгән: беренче катта ир-атлар өчен зур намаз залы урын алган, хатын-кызлар намазны икенче катның балконында укый ала. Цоколь катында ике уку сыйныфы, хезмәткәрләр бүлмәсе, ашханә бар – биредә исем кушу һәм никах мәҗлесләрен, Рамазан аенда ифтарлар үткәрергә мөмкин. Мәчетнең әйләнә-тирәсе төзекләндерелгән – тротуар җәелгән, газон чәчелгән. Мәчеткә машина белән килүчеләр өчен уңайлы парковка булдырылган. Балалар өчен мәйданчык һәм заманча спорт комплексы бар.

«Габделәхәт» мәчетенең имам-хатыйбы итеп Рөстәм хәзрәт Вахитов билгеләнде.

## РИИда ислам финанслары буенча курслар эшләде һәм түгәрәк өстәл оештырылды

Октябрь башында Россия ислам институтында ислам финанслары өлкәсендәге белгечләр һәм мөгаллимнәр өчен «Россиянең традицион рухи-әхлакый кыйммәтләрен саклау һәм ныгыту буенча теория һәм практика» программасы буенча курслар кысаларында «Хәзерге Россиядә партнерлык финанслары: теория һәм практика» модуле узды. Белем арттыру курслары Ислам мәдәниятенә, фәненә һәм мәгарифенә ярдәм фонды теләктәшлегендә оештырылды.

Әлеге курсларда AAOIFIның (ислам финанс учреждениеләре өчен бухгалтерлык хисабы һәм аудит оешмасы) Россия һәм чит илләрдәге әйдәп

баручы шәригать экспертлары, шулай ук ислам финанслары өлкәсендәге белгечләр лекцияләр укыды. Алар арасында AAOIFIның сертификацияләнгән шәригать экспертлары – ислам фәннәре докторы, Нәзарәтнең шәригать мәсьәләләре буенча бүлек белгече Идрис хәзрәт Киемов; Казан казые, Нәзарәтнең шәригать мәсьәләләре буенча бүлек башлыгы Булат хәзрәт Мөбарәков; Нәзарәтнең Голамәләр шурасы әгъзасы, Ислам икътисады һәм финанслары үсеше үзәге рәисе Булат Мөлеков; ислам фәннәре докторы, Россия ислам финанслары һәм икътисады үзәге директоры, Нәзарәтнең Голамәләр шурасы гыйльми сәркатибе Рөстәм хәзрәт Нургалиев һ.б. бар.

Курсларда «РФдә ислам финансларын стандартлаштыру», «Сертификацияләү һәм аудит», «Ислам финанс продуктлары», «Белгечләр әзерләү» һәм «РФдә ислам финанслары экосистемасын булдыру» темалары каралды.

Белем арттыру курсларының ахыргы көнендә Россия ислам институтында «Хәзерге Россиядә партнерлык финанслары: теория һәм практика» дип аталган түгәрәк өстәл узды. Анда Россиянең әйдәп баручы экспертлары, шулай ук ислам финанс продуктлары белән шөгыльләнүче банклар һәм компанияләр вәкилләре Россиядә партнерлык финансларын үстерү мәсьәләләре буенча фикер алышты.

## Нәзарәт делегациясе Луганскида шефлыктагы госпитальдәге яралыларга – медикаментлар, ә хәрби часть солдатларына Татарстан мөселманнарыннан гуманитар ярдәм тапшырды

ТР мөселманнары Диния нәзарәте делегациясе Луганск халык республикасына сигезенче тапкыр гуманитар миссия белән барып кайтты. ТР мөселманнары Диния нәзарәте хезмәткәрләре шефлыкка алынган госпитальдәге яралыларга медикаментлар тапшырды һәм сугыш хәрәкәтләре зонасындагы солдатларга гуманитар йөк илтте.

Махсус одеяллар, антенналар, парракорд баулар, планшетлар; хәләл азык-төлек (консервалар, ярмалар, токмачлар, шикәр, казылык), медицина инструментлары һәм материаллар (шприцлар, бинтлар, шиннар, скальпельләр, системалар, перчаткалар, жгутлар һ.б.) мобилизацияләнгән солдатларга тапшырылды. Гуманитар йөк, солдатларның теләкләрен исәпкә алып, ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды тарафыннан җыелган акчага тупланды.

## Актаныш мөхтәсибәтендә яңа мәчет ачылды

Рабигыль-ахыр аеның 9 нчы көнендә (12 октябрьдә) Актаныш районы Яңа Җияш авылында «Рафикъ» мәчете ачылды. Аллаһы йорты «Чишмә» хуҗалыгы җитәкчесе Рафикъ Сәхәбетдинов истәлегенә төзелгән.

30–40 кеше сыйдырышлы «Рафикъ» мәчетенә су кертелгән, электр энергиясе белән тәэмин итү системасына тоташтырылган, намаз уку бүлмәләрендәге идәннәр җылытылган. Барлык уңайлыклары булган тәһарәтханә бар.

Бүгенге көндә Актаныш мөхтәсибәтендә 57 мәчет эшли.

## Казанда Рәис һәм Мөфти катнашында төзекләндерүдән соң тарихи «Ак мәчет» (Яңа бистә мәчете) ачылды

Рабигыль-ахыр аеның 13 нче көнендә (16 октябрьдә) Казанда төзекләндерүдән соң тарихи «Ак мәчет» (Яңа бистә мәчете) тантаналы рәвештә ачылды. Әлеге мәчет республика дәрәҗәсендәге мәдәни мирас бинасы булып санала. Ачылышта Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, «Татэнергосбыт» акционерлык җәмгыяте директоры Рифнур Сөләйманов, Татарстан Мәдәни мирас объектларын саклау буенча комитет рәисе Иван Гущин, Казан мэры Илсур Метшин, дини һәм

иҗтимагый оешмалар вәкилләре, «Мөхәммәдия» һәм Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә шәкертләре, хәйриячеләр, мәхәллә халкы катнашты. Кунаклар башкарылган эшләр белән танышып чыкты һәм тәхият әл-мәсҗид намазын укыды.

БЕЛЕШМӘ

«Ак мәчет» Казан шәһәрендә эшләми торган бердәндер тарихи мәчет иде. 1928 елда мәчет ябылганнан соң, бинасы башка максатлар өчен җайлаштырылган. 2002 елда дин тотучыларга кире кайтарылган. 2023–2024 елларда Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов башлангычы белән хәйрия акчалары хисабына төзекләндерү эшләре башкарылган. Мәчетнең тарихи «йөзе» кире кайтарылган, нигезе һәм диварлары ныгытылган, баскычлар урнаштырылган, агач тәрәзә уемнары ясалган, мәчет электр һәм газ челтәрләренә тоташтырылган, манара торгызылып, ярымай куелган, коймалар корылган. Хәзерге вакытта мәчет бинасының мәйданы – 542 квадрат метр. Ул ике катлы, икенче катта – ирләр өчен өч намаз залы, ә беренче катта аерым ишек белән хатын-кызлар өчен намаз залы урнашкан. Тәһарәтханә, ашау бүлмәсе аерым бинада урнаштырылган.

## Мамадыш мөхтәсибәтендә яңа мәчет ачылды

Рабигыль-ахыр аеның 20 нче көнендә (23 октябрь) Мамадыш районындагы «Мамадыш» совхозының 2 нче ферма бистәсендә халык арасында «Яшел тау» дип йөртелгән җирлектә яңа мәчет ачылды. Утыз кеше сыйдырышлы бер катлы мәчеттә Ислам нигезләрен өйрәтү өчен барлык шартлар бар, мәчет электр белән тәэмин итү һәм җылыту системаларына тоташтырылган. Имам булып Фәнис хәзрәт Миңнеханов тора.

Хәзерге вакытта Мамадыш мөхтәсибәтендә 61 мәчет эшли.

## Апанай мәчете 255 еллык юбилеен билгеләп үтте

Рабигыль-ахыр аенның 23 нче көнендә (26 октябрь) Казанда Апанай мәчетенең 255 еллыгына багышланган тантаналы чара узды. Юбилей тантаналары кысаларында «Апанай мәчете имамнарының дин һәм милләт өчен күрсәткән хезмәтләре: тарих һәм хәзерге заман» дип аталган фәнни-гамәли конференция узды, анда мәчет һәм мәдрәсәнең үткәне һәм бүгенгесе, шулай ук мөһим тарихи мирасы турында докладлар тәкъдим ителде. Конференциядә катнашучыларга Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин исеменнән аның урынбасары, Мәрҗани мәчете имам-хатыйбы Равил хәзрәт Зөфәров мөрәҗәгать итте.

Юбилей тантаналары кысаларында Апанай мәчетенә нигез салынуга 255 ел тулуга багышланган «Апанай мәчете: дин һәм милләт хезмәте» китабы тәкъдим ителде. Апанай мәдрәсәсе бинасында Казанның мөселман китапханәсе дә ачылды. Биредә «Иман» нәшриятында басылган 1000 нән артык китап, шулай ук заманча мөселман әдәбияты, «Дин вә мәгыйшәт», «Умма», «Мөселманнар» кебек мөселман газеталары тәкъдим ителгән.

## Мөфти һәм ТР Милли музее Генераль директоры татар дини мирасын цифрлаштыру буенча бергәләп эшләү хакында килеште

Рабигыль-ахыр аенның 27 нче көнендә (30 октябрьдә) ТР Милли музеенда Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин музейның генераль директоры Алисә Вяткина белән очрашты. Әңгәмә бай татар-мөселман мирасын саклау һәм популярлаштыру буенча уртак эш алып баруга багышланды. Җитәкчеләр ТР Милли музее фондындагы уникаль китапларны цифрлаштыруга, аны бар дөнья мөселманнарына җиткерү һәм күп гасырлар дәвамында саклау мәсьәләләренә аерым игътибар бирде. Хәзерге вакытта бу эш «Хозур» нәшрият йорты тарафыннан алып барыла: 2013 елда биредә

Камил хәзрәт боерыгы белән «Даруль-кутуб» электрон китапханәсе булдырылды. Китапханә үсештә: бүгенге көндә аның фондында 1600 дән артык китап бар (бу 2000 нән артык том дигән сүз). Камил хәзрәт һәм Алисә Вяткина бу юнәлештә хезмәттәшлек мөмкинлекләре һәм юллары хакында фикер алышты.

## Казанда мөселман уку йортлары мөгаллимнәренең XIII Бөтенроссия форумы узды

30–31 октябрьдә Казанда мөселман уку йортлары мөгаллимнәренең «Россия мөселманнарының гражданлык үзенчәлеге нигезе буларак традицион рухи-әхлакый кыйммәтләр» дип исемләнгән XIII Бөтенроссия форумы узды. Форумның беренче эш көнендә мәчет каршындагы курслар укытучылары үзләренең эш тәҗрибәсе белән бүлеште. Икенче көнендә исә мәдрәсәләр, Россиянең, якын һәм ерак чит илләрнең югары уку йортлары укытучылары яхшы үрнәкләр белән уртаклашты.

Россия ислам институты тарафыннан Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте белән берлектә Ислам мәдәниятенә, фәненә һәм мәгарифенә ярдәм фонды теләктәшлегендә үткәрелә торган чара быел 500 дән артык мөгаллимне, башлангыч, урта һәм югары мөселман уку йортлары җитәкчеләрен, халыкара ислам мәгарифе үзәкләре вәкилләрен җыйды. Пленар утырышта Татарстан Мөфтие, шәригать фәннәре докторы Камил хәзрәт Сәмигуллин чыгыш ясап, ислам уку йортларында илебезнең мөселман дини мирасын өйрәнү һәм популярлаштыруның мөһимлеген билгеләп үтте.

Чарада Татарстанда мөселман мәгарифен үстерүгә өлеш керткән өчен дини белем бирү оешмалары директорлары, республика дәүләт хакимияте органнары хезмәткәрләре, дин һәм җәмәгать эшлеклеләре, хәйриячеләр бүләкләнде.

## Мәрҗани мәчетендә Татарстан мәдрәсәләре шәкертләре арасында Коръән бәйгесе үтте

Җөмәдәл-әүвәл аеның 3 нче көнендә (5 ноябрьдә) Мәрҗани мәчетендә Татарстанның мөселман уку йортлары шәкертләре арасында Республикакүләм Коръән укучылар бәйгесе узды. Аны Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте, Россия ислам институты, Казан ислам университеты, Госман бине Гаффан исемендәге Коръән хафизлар әзерләү үзәге оештырды.

Бәйге Татарстан мөселман уку йортларында укучылар арасында Коръәннең 29 нчы һәм 30 нчы җүзләрен яттан белү һәм Коръән ятлау үзәкләрендә укучылар арасында 28 нче, 29 нчы һәм 30 нчы җүзләрне яттан белү номинацияләрендә үткәрелде.

## Нәзарәтнең «Зәкят» хәйрия фонды гражданлык җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен ТР Рәисе премиясенә лаек булды

Җөмәдәл-әүвәлнең 3 нче көнендә (5 ноябрь) Казан Кремлендә Татарстан Республикасы Рәисенең 2024 елда Татарстан Республикасында гражданлык җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен премияләрен тапшырдылар. Премиягә ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды да лаек булды. Бүләкне Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов кулыннан фондның генераль директоры Булат Мәрданов алды.

Рөстәм Миңнеханов, республика премиясе лауреатларын тәкъдим итеп, «Зәкят» хәйрия фондының Татарстанда озак эшләүче фондларның берсе булуын, аның бүгенге көендә махсус хәрби операция сугышчыларына һәм Фәләстыйндәге тыныч халыкка гуманитар ярдәм җыю һәм тапшыру буенча зур эш башкаруын билгеләп үтте.

## Нәзарәт кубогына татарча көрәш һәм кул көрәше буенча XV Бөтенроссия турниры узды

Җөмәдәл-әүвәл аеның 7 нче көнендә (9 ноябрьдә) Яр Чаллы шәһәрендә М.И.Бибишев исемендәге «Витязь» спорт мәктәбендә Татарстан мөфтияте кубогына татарча көрәш һәм кул көрәше буенча XV Бөтенроссия турниры узды. Ярышларны Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте һәм Яр Чаллы мөхтәсибәте оештырды. Ел саен үткәрелә торган спорт ярышлары мөселманнар арасында татар көрәшен һәм кул көрәшен популярлаштыру, мөселман яшьләрен берләштерү, сәламәт яшәү рәвешен саклап калу өчен шартлар тудыру максатыннан үткәрелә.

Турнирда Татарстанның, Башкортстанның һәм Чувашиянең 20 районыннан 60 спортчы катнашты. Ярышлар яхшы әзерлек белән, имгәнүләрсез узды, көрәшчеләр тамашачыларны искиткеч алымнары белән таң калдырды. Һәр үлчәүдә җиңүчеләр игълан ителде, алар акчалата призлар, иганәчеләрдән бүләкләр, медальләр һәм дипломнар белән бүләкләнде.

Хаҗга юлламага Яр Чаллыдан 38 яшьлек армрестлер Фәнис Нурхәммәтов лаек булды, ул 85 килограммнан артык авырлык категориясендә җиңү яулады. ТР мөселманнары Диния нәзарәте кубогына Яр Чаллы командасы лаек булды.

## Татарстанда 968 тонна гошер садакасы җыелды һәм мохтаҗларга өләшенде

ТР Диния Нәзарәте башлангычы белән тормышка ашырылган гошер садакасын җыю һәм халыкның мохтаҗ катламнарын азык-төлек белән тәэмин итү кампаниясе тәмамланды. Кампания нәтиҗәләре буенча, Татарстан Республикасында барлыгы 968 тонна гошер садакасы җыелды. Мөхтәсибәтләр арасында беренче өчлекне Сарман (86,4 т), Арча һәм Балык Бистәсе (75 шәр тонна), Балтач (73,9 т) районнары алып тора. Шулай ук Әлки

районы (60 т), Әтнә районы (55 т), Кукмара районы (50 т), Чирмешән районы (45 т), Саба районы (43 т), Чүпрәле районы (32,3 тонна), Теләче районы (37 т) зур активлык күрсәтте.

Татарстан мөселманнары мохтаҗларга ярдәм итү йөзеннән республика мәчетләренә яшелчә (бәрәңге, чөгендер, кәбестә, кишер, кабак, ташкабак, суган һ.б.), җиләк-җимеш кайнатмалары, тозлаган кыяр-помидорлар, бал алып килде. Искәрмәләр дә булды: мәсәлән, Сарман районында мөселман эшкуарлары гошерне – бөртекле культуралардан, ә Лаеш мөхтәсибәтендә токмачтан һәм көнбагыш маеннан чыгарды. Кампания кысаларында җыелган азык-төлек хәйрия оешмаларына, социаль учреждениеләргә (районнардагы картлар йортлары, балалар йортлары, интернат-мәктәпләр, мөхтәсибәтләр һәм мәчетләр каршындагы социаль ашханәләр), мөселман уку йортларына, шулай ук турыдан-туры мохтаҗ гаиләләргә җибәрелде. Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды Казанның 530 аз керемле гаиләсен азык-төлек белән тәэмин итте.

## Казанда ислам уку йортлары студентлары арасында BRICS илләре катнашындагы XVII Халыкара олимпиада җиңүчеләрен бүләкләделәр

Җөмәдәл-әүвәл аеның 12 нче көнендә (14 ноябрь) Казанда ТР Милли китапханәсендә ислам уку йортлары студентлары арасында BRICS илләре катнашындагы ислам фәннәре һәм гарәп теле буенча XVII Халыкара олимпиада җиңүчеләрен рәсми бүләкләү тантанасы узды. Олимпиада 13 ноябрьдә Казанда Россия ислам институтында үтте.

Халыкара олимпиаданы Россия ислам институты Мөхәммәд бине Зәйед исемендәге гуманитар фәннәр университеты һәм Ислам мәдәниятенә, фәненә һәм мәгарифенә теләктәшлек фонды белән берлектә оештырды. Олимпиадада Россия, Әзербәйҗан, Казахстан, Таҗикстан, Кыргызстан, Үзбәкстанның әйдәп баручы ислам югары уку йортлары студентларыннан

тыш, беренче тапкыр BRICSка кергән һәм партнер булган илләр – Иран, Һиндстан һәм Төркия вәкилләре катнашты.

Олимпиадада җиңүчеләр «Дин нигезләре», «Ислам хокукы» номинациясе (хәнәфи мәзһәбе), «Ислам хокукы» номинациясе (шәфигый мәзһәбе) һәм «Гарәп теле» номинацияләрендә бүләкләнде. Казан ислам университеты шәкерте Руслан Ямилов «Ислам хокукы» номинациясе (хәнәфи мәзһәбе) беренче урын яулады. Моннан тыш, Олимпиадада катнашучыларга – РИИ һәм КИУ ректоры Рәфикъ Мөхәммәтшин, шулай ук Казан мэры Илсур Метшин исеменнән махсус бүләкләр тапшырылды.

## Мөфти җитәкчелегендә хәзрәтләр «десанты» гуманитар миссия белән Донецк һәм Луганск Республикаларына һәм солдатлар янына барып кайтты

18 ноябрьдә ТР мөселманнары Диния нәзарәте делегациясе махсус хәрби операция зонасына 9 нчы тапкыр гуманитар миссия белән сәфәрдән кайтты. Бу юлы Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкчелегендә аның урынбасарлары, мөхтәсибләр, Казан һәм район мәчетләре имамнары, хезмәткәрләр, журналистлар – барлыгы 20 кеше барды.

Донецк шәһәрендә «Тышкы куркынычлар алдында Россиядә Ислам» темасына дини конференция һәм Луганск шәһәрендә шул ук исемдәге түгәрәк өстәл узды. Монда Россия мөселманнарын берләштерү мәсьәләләре, исламофобия һәм дини экстремизм идеяләрен, җәмгыятьтә ызгыш-талаш тудыручы җимергеч мәгълүмат тарату проблемалары турында фикер алыштылар. Хәзрәтләр түземсезлек идеяләренә каршы тору һәм хакыйкый Ислам кыйммәтләрен алга этәрүдә уртак мәгърифәтчелек эшчәнлеге алып бару турында карарлар кабул итте. Конференцияләр Ислам мәдәниятенә, фәненә һәм мәгарифенә теләктәшлек фонды ярдәме белән узды.

Нәзарәт делегациясе шефлыкка алынган хәрби подразделениегә һәм ике госпитальгә солдатларга күчтәнәчләр илтте. Аларга хәләл тушенка, дини китаплар, ноутбуклар, элемтә чаралары, җылыткычлар, тиз әзерләнә торган ашлар, баш киемнәре һәм эчке киемнәр, тәм-томнар, гигиена чаралары, йокы капчыклары, йөк машиналары өчен көпчәкләр тапшырылды. Йөкнең авырлыгы 1,5 тоннага җитте. Ул республиканың барлык почмакларындагы мөхтәсибәтләр тырышлыгы белән җыелды.

## Лаеш мөхтәсибәтендә капиталь төзекләндерүдән соң мәчет ачылды

Лаеш районы Пәрәү авылында капиталь төзекләндерүдән соң тантаналы рәвештә мәчет ачылды. Пәрәү авылындагы 1995 елда ачылган ике катлы мәчет бинасы 300 кешегә исәпләнгән. 2024 елның маенда Лаеш районы якташлык җәмгыятенең актив әгъзаларының берсе, Пәрәү авылында туып үскән Руслан Евдокимов җитәкчелегендә мәчетнең идәннәре алыштырылган һәм җылытылган, яңа келәмнәр сатып алынып салынган, җылыту торбалары һәм төп гыйбадәт залына узучы баскыч яңартылган, имам бүлмәсе, уку сыйныфы һәм ифтар залы җиһазландырылган, уңайлы гардероб булдырылган, заманча ишек куелган. Мәчет янындагы территория төзекләндерелгән: биредә балалар мәйданчыгы һәм футбол уйнау урыны урнашкан.

## Мөфти Камил хәзрәт махсус хәрби операция зонасында хезмәт итүче имамнар белән очрашты

Җөмәдәл-әүвәл аеның 17 нче көнендә (19 ноябрь) Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин ТР мөселманнары Диния нәзарәтендә «Тимер» һәм «Батыр» батальоннары имамнары Илдар Шәмсетдинов һәм Мөхәммәд Хәйрулаев белән очрашты. Алар Мөфти белән махсус хәрби операция зонасында имамлык тәҗрибәсе белән уртаклашты, сугышчыларның ихтыяр көчен

ныгыту юллары турында сөйләде. Үзләре хезмәт иткән батальон өчен кирәк булган гуманитар йөккә кагылышлы тәкъдимнәрен әйтте. Камил хәзрәт, батальоннарның фронт китапханәсен баету өчен, ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хозур» нәшрият йортыннан китаплар һәм догалыклар бүләк итте.

## Сентябрь–декабрь айларында Нәзарәт 3 яңа ислам финанс продуктын хуплады

Сентябрь–декабрь айларында Нәзарәт 3 яңа ислам финанс продуктын хуплады. Тәкъдим ителгән документларны өйрәнеп, әлеге продуктларны ислам хокукы кануннары нигезендә рөхсәт ителгән дип тапты. Шулай итеп, хәләл финанс хезмәтләре базарында шушы яңа продуктлар барлыкка килде: Т-Банк Татарстан Мөфтиятенең хуплавы белән федераль ислам картасы чыгарды; Ак Барс Банкы эшмәкәрләр өчен мурабаха ислам продуктын эшләтеп җибәрде; ЗЕНИТ банкының «Зарплатная карта привилегий», «ЗЕНИТ карта» продуктлары кысаларында ислам дебет картасы хупланды. Т-Банкның ислам картасы – Россиядә Ислам кануннары буенча федераль масштабтагы беренче банк продукты, аны бөтен ил күләмендә гамәлгә ашыру көтелә. ТР мөселманнары Диния нәзарәте мөселманнар һәм финанс оешмалары арасында, шулай ук Россия финанс регуляторында ислам финанс продуктларын гамәлгә кертү өлкәсендә ышаныч казанды.

## Татарстанда Мөхлисә Бубиның 155 еллыгын билгеләп үттеләр

Җөмәдәл-әүвәл аеның 25 нче көнендә (27 ноябрьдә) Әгерҗе мөхтәсибәтенең Иж-Буби авылында Россиядә беренче хатын-кызлар мәдрәсәсенә нигез салучы һәм күренекле хатын-кыз казыя Мөхлисә Бубиның тууына 155 ел тулуга багышланган фәнни конференция узды. Бу чара Татарстан

мөфтиятенең актив ярдәме белән Әгерҗе мөхтәсибәте, Бөтендөнья татар конгрессы, ТР Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты, Иж-Буби авылы тарихы музее, «Бубилар мирасын торгызу» иҗтимагый оешмасы тарафыннан оештырылды, һәм Мөхлисә Буби мирасын, авыл мәдрәсәсе тарихын һәм аның Идел-Урал төбәгендәге тарихи әһәмиятен өйрәнүгә багышланды. Галимнәр XIX-XX гасырлар чигендә мөселман хатын-кызларының җәмгыятьтәге активлыгы һәм аларның Россия мөселман өммәте үсешенә керткән өлеше белән бәйле мөһим темалар турында фикер алышты.

Конференциядә Мөхлисә Буби юбилее хөрмәтенә бертуган абыйсы Гобәйдулла Бубиның «Хозур» нәшриятендә басылган «Фәнни уку. Физика» китабы тәкъдим ителде. Әлеге хезмәт – инкыйлабка кадәр дөнья күргән физика буенча ярдәмлекнең хәзерге татар теленә күчерелгән басмасы.

## Казанның Мәрҗани мәчетендә «Абыстайлар дөньясы: үткәне һәм бүгенге көне» дип аталган түгәрәк өстәл узды

Җөмәдәл-әүвәл аеның 27 нче көнендә (29 ноябрьдә) Казанның Мәрҗани мәчетендә «Абыстайлар дөньясы: үткәне һәм бүгенгесе» дип аталган түгәрәк өстәл узды. Чараны Нәзарәтнең Хатын-кызлар белән эшләү бүлеге һәм Татарстан Мөслимәләр берлеге оештырды. Түгәрәк өстәл Ислам динен саклау һәм үстерүгә зур өлеш керткән мәшһүр мөслимәләрнең якты истәлегенә багышланды. Аерым алганда, чарада катнашучылар педагог, җәмәгать эшлеклесе һәм педагог Маһруй Үтәмешеваны (дин галиме, Россия мөселманнарының Үзәк диния нәзарәте мөфтие Галимҗан Барудиның хәләл җефете), беренче хатын-кызлар мәдрәсәсенә нигез салучы һәм күренекле хатын-кыз казыя Мөхлисә Бубины, татар мөгаллимәсе, мәгърифәтче, язучы Маһруй Мозаффарияне, хәйрияче, җәмәгать эшлеклесе, Казанда татар кызлары өчен үз акчасына дөньяви мәктәп ачкан һәм аны җитәкләгән Фатыйма Аитованы

һәм башкаларны искә алдылар. Хәзерге вакытта абыстайларның бу мәшһүр затлар үрнәгендә ни рәвешле эшчәнлек алып баруы турында сөйләштеләр.

Чарага Татарстанның 10 нан артык мөхтәсибәтеннән мөслимәләр берлеге җитәкчеләре, шулай ук Казан мәчетләрендәге баш абыстайлар – барлыгы 150 мөслимә килде. Алар арасында Ульян өлкәсеннән, Чуашстан һәм Марий Эл республикаларыннан кунак булып килгән абыстайлар да бар иде. Абыстайлар барысы да мәчетләрдә мөгаллимә булып хезмәт итә, актив эш алып бара, социаль проектлар, шул исәптән махсус хәрби операциядә катнашучы солдатларга гуманитар ярдәм җыюны оештыра.

«Ислам. Беренче адымнар» мәктәбенең 14 нче чыгарылышында 150 кеше намазга басты

Җөмәдәл-әүвәл аеның 29 нчы көнендә (1 декабрьдә) Казанда Нәзарәтнең иң мөһим проектларыннан берсе – намаз укырга өйрәтү һәм Ислам нигезләре белән таныштыру буенча «Ислам. Беренче адымнар» дип исемләнгән кыска вакытлы курслар – тәмамланды. Шәкертләр сира, гакыйдә фәннәре һәм тәһарәт, намаз, ураза, хаҗ гамәлләре буенча гыйлемнәрне колачлаган курсны үзләштерелде. «Ислам. Беренче адымнар» проектының 14 нче курсын 150 кеше тәмамлады. Ундүрт сезон дәвамында әлеге курсларда 1550 гә якын кеше белем алды һәм намазга басты.

# Тарих

# Дөнья тарихында мөселман университетлары

Коръән аятьләре дин кардәшләребезне һәрвакыт гыйлемгә, эзләнүгә омтылырга этәргән. Бүгенге университетлар системасына да нигезне мөселманнар салган. Мөселман дөньясында гыйлем бирү мәчетләрдә башланган. Гарәпчә мәчет «җәмигъ» булса, университет сүзе – «җәмига». Шул рәвешле, гарәп телендә гыйбадәт кылу һәм гыйлем алу урыннары тамырдаш сүзләр белән берләштерелгән.

## Әз-Зәйтүнә университеты

Иң борынгы мөселман университеты дигәндә, уйга беренче булып Тунистагы Әз-Зәйтүнә университеты киләдер, мөгаен. Бу мәшһүр уку йортына 737 елда нигез салына. Озак вакыт ул мәчет каршындагы мәдрәсә рәвешендә эшләп килгән. Мәчетнең китапханәсе гаять бай булган: аңа грамматика, мантыйк, фәнни этика, космология, арифметика, геометрия һ. б. фәннәр буенча китаплар кергән. Димәк, дини гыйлем белән беррәттән, монда бик күп фәннәр укытылган. Әз-Зәйтүнә университеты бүгенге көнгә кадәр эшли.

## Әл-Каравийн университеты

859 елда Фатыйма әл-Фиһри исемле яшь мөслимә Марокконың Фәс шәһәрендә мәчет һәм мәдрәсә салдыра. Ул бүгенге көнгә кадәр эшләп килгән Әл-Каравийн университеты буларак дөньяга танылa. Фатыйма әл-Фиһри бай сәүдәгәр кызы була, бик яхшы белем ала һәм әтисеннән калган бай мирасны уку йорты булдыруга сарыф итә. Төзелеш эшләре башланган көннән алып, гыйбадәт һәм уку бинасы

әзер булганчы, Фатыйма һәр көн ураза тоткан. Шунысы да игътибарга лаек: Фатыйманың апасы Мәрьям шулай ук мирасын әл-Әндәлуста мәчет салдыруга тоткан.

Әл-Каравийн университетында Коръән, дин гыйлеме, хокук, риторика, арифметика, география, медицина, Ислам тарихы, химия кебек фәннәр укытылган. Уку йорты астрономик җиһазларга бай булган.

## Әл-Әзһәр университеты

Шулай ук иң борынгы һәм мөселман дөньясында иң мәшһүр университетларның берсе булып Каһирәдәге Әл-Әзһәр университеты тора. 970 елда ул Әл-Әзһәр мәчете каршындагы мәдрәсә буларак эшли башлый, ә 988 елда уку йортының укыту планы төзелеп, анда остазлар һәм шәкертләрне җыялар. Университетка Әл-Әзһәр атамасы Мөхәммәд галәйһиссәламнең кызы Фатыйма әз-Зәһра исеменә нисбәтле бирелә. Уку йортында чит илләрдән килүче шәкертләр дә бик күп булганлыктан, алар өчен махсус йортлар төзелгән, бу бүгенге тулай торакларга туры килә. Сәләтле шәкертләргә стипендия бирелгән. Ә университет сәләтле шәкертләргә чыннан да бай булган. Шуларның берсе – мәшһүр галим, математик, механик, физик, астроном Әлхәсән бине әл-Һәйсәм. Аны «оптика гыйлеменең атасы» дип атыйлар. Университетның бөек мөгаллимнәре арасыннан тарихчы, фәлсәфәче Ибне Хальдунны атарга мөмкин. Ул Әз-Зәйтүнә университетында белем алган.

## Санкоре университеты

989 елда Африканың Мали дәүләтендә Тимбукту шәһәрендә казый тарафыннан Санкоре мәчете салына. Соңрак мәчетнең һәм аның каршындагы уку йортының иганәчесе булып бер бай мөслимә ханым тора. Ул әлеге университетны зур дәрәҗәләргә күтәрә ала. 12 нче гасыр ахырында монда

25 мең шәкерт белем алган. Чагыштыру өчен, КФУда бүгенге көндә 50 меңгә якын студент укый.

Санкоре университетында да дини гыйлемнән тыш хокук, әдәбият, хирургия, астрономия, математика, физика, химия, география, тарих фәннәре укытылган. Шулай ук шәкертләр балык тоту, балтачылык, тегү кебек кәсепләргә өйрәнгәннәр. Бүгенге көн докторантурасына туры килгән югары баскычта 10 елга якын укыганнар. Аны уңышлы тәмамлаучылар галим булarак танылган. Бу баскычта шәкертләр «рисәлә» язган, бүген без аны диссертация дип атар идек. Бүгенге көнгәчә бу уку йортында язылган яки укытуда кулланылган йөзләгән мең кулъязма хезмәтләр саклланган.

## Белем алу үзенчәлекләре

Тарихчылар билгеләвенчә, мөселман университетларында уку җиңел булмаган. Бигрәк тә медицина бүлекләрендә имтиханнар катлаулы һәм күп булган. Имтиханнарын уңышлы тапшыра алмаган шәкертләр кешеләрне дәвалау белән шөгыльләнә алмаган.

Хокукны өйрәнергә теләүче шәкертләргә исә ике баскыч үтәргә кирәк булган. Беренче баскычта шактый күп шәкерт хокук нигезләрен өйрәнә алса, югары баскычка фәнни җитәкче иң сәләтле укучыларны гына сайлап алган. Икенче баскычта уку бик озак дәвам иткән, хәтта 20 елга кадәр сузыла алган. Укуны уңышлы тәмамлап, эшли башларга теләүчеләр иҗазәт – рөхсәт, лицензия – алырга тиеш булган.

Бүгенге университетлар белән борынгы мөселман уку йортларын чагыштырсак, бик күп охшашлыклар табарбыз: кабул итү һәм укуны тәмамлаганнан соң бирелә торган имтиханнар, укуны тәмамлау турында таныклыклар – иҗазәтләр, фәнни түгәрәкләр, бай китапханәләр һәм фәнни җиһазлар булуы, стипендияләр, чит ил студентларын кабул итү һ. б.

## Мөселманнарның күк җисемнәрен өйрәнүе

Күк җисемнәрен өйрәнү һәрвакытта да әһәмиятле фән булып торган. Мөселманнарга көн саен биш фарыз намазның вакытын билгеләргә, җирнең төрле ноктасыннан кыйбла юнәлешен таба белергә кирәк булган. Шуңа күрә астрономия фәне мөселманнарны бик кызыксындырган.

Астрономия гыйлеменә нигезне мөселманнар салмый, әмма алар, бу өлкәдәге борынгы хезмәтләрне тәрҗемә кылып, өйрәнеп, үз ачышлары белән фәнне үстерүгә, обсерваторияләр төзүгә һәм катлаулы җиһазлар булдыруга искиткеч зур өлеш керткән.

Мәшһүр мөселман астрономнары бихисап. Шуларның берсе – әл-Бируни (973–1050). Ул Җир шарының үз күчәрендә әйләнүен әйтә, Җир әйләнәсенең озынлыгын санап чыгара һәм җирнең теләсә кайсы ноктасыннан Мәккәгә юнәлешне табарга ярдәм итә торган фәнни ысуллар чыгара.

Җиһазлардан борынгы чорда квадрантлар, армилляр сфералар, астролябияләр, күк җисемнәренең глобуслары һ. б. кулланылган. Астролябия бик кирәкле астрономик җиһаз булып, шулай ук намаз вакытларын билгеләү өчен дә кулланылган. Сүз уңаеннан, ТР Милли музеенда мәгърифәтчебез К. Насыйриның астрономия глобусын күрергә мөмкин.

IX гасыр башында Багдад хәлифәсе әл-Мәэмүн мөселманнар һәм кешелек тарихында беренче обсерваторияне төзергә әмер биргән. Бу эш бик зур чыгымнар таләп иткән. Шулай ук әл-Мәэмүн обсерваториядә кирәкле булган зур җиһазларны булдыруны, анда эшләүче галимнәрне тәэмин итүне үз өстенә алган.

Беренче обсерваторияләр Багдад һәм Димәшкъ шәһәрләрендә салынган. Аларда эшләүче галимнәрнең төп бурычы булып астрономик таблицалар төзү торган. Әлеге җәдвәллар планеталарның торышын, айның фазаларын, ай тотылу вакытларын күрсәткән. Әл-Мәэмүннең обсерваторияләре кояш һәм ай җәдвәлларын төзү, йолдызлар һәм планеталарны күзәтү белән шөгыльләнгән.

Соңрак мөселман дөньясының башка төбәкләрендә дә обсерваторияләр булдырылган. Мәсәлән, Мәрага, Сәмәрканд, Исфахан, Тәбриз шәһәрләрендә мәшһүр обсерваторияләр булуы билгеле. Аларда ясалган ачышлар, җиһазлар бар дөньяга таралган.

*«Дин вә мәгыйшәт» газетасыннан*

رمضان

«Ий иман китерүчеләр!
Сездән алда килеп киткәннәргә [фарыз булып] язылган кебек, сезгә дә [Рамазан аендагы] ураза [фарыз буларак] язылды. Бәлки, [ачлык ярдәме белән гөнаһлардан сакланып] тәкъвалык ияләреннән булырсыз!»

«ӘЛ-БӘКАРА / СЫЕР», 2:183